PRESSA.RU

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№1 (313) – ГЫЙНВАР 2018

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан нәшер ителә

2017: бары тик фактлар гына

90 яшьлек чемпион

Әдәби премиягә лаеклылар табылды

ТУГАН ЯГЫ – КАРЛЫ БИШЕК

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Бүлек мөхәррирләре:
Ольга Туманская, Олеся Бондаревская,
Руфия Фазылова
Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Ксения Сёмина, Фаяз Хуҗин
Фотографлар: Александр Ефремов, Ната Смирнова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин,
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж: 3500 данә,
шул исәптән татар телендә – 1000.

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми. «Промо» һәм «Медиа» рубрикалары материаллары реклама-коммерция нигезендә басыла.

Журнал «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә **басылды**: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № Е-110

Басарга кул куелды: 26.01.18

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com
Коммерция директоры урынбасары:
Җәмилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru
Коммерция бүлеге белгече:
Екатерина Благодарова,
eblagodarova@inbox.ru, тел. (843) 222-09-76
Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

ЭШ ЭШЛӘНГӘН. АЛГА ТАБА ДА ЭШЛИБЕЗ, ДИМӘК

Кайчак кемнәрдер уйлап тапкан һәм планлаштырган очы-кырые юк прожектлардан күбесенең беркайчан да чынга ашмаячагын, ягъни картада пәйда булмаячагын һәм, кеше күзенә чалынып, балкымаячагын уйлыйсың да тел шартлатасың. Юкса нәрсәдер төзиләр дә шикелле, кемдер ул төзелешләрдә мәш килә, тагын кемнәрдер кемнәр беләндер киңәшә-сөйләшә, кемнеңдер инвестицияләре каядыр ага, килешүләргә кул куела, бер-берсенә файдалы яклар кул кысыша... Әнә шулай кечкенә генә кирпечләрдән пазллар җыела тора... Ә инде ел азагында, пазлларның барысы да үз урынына урнаша, һәм күзгә соклангыч манзара ачыла. Бик матур манзара. Кайда карама – анда төзелгән, монда – төзекләндерелгән, ә тегендә – торгызылган. Планнар үтәлгән, проектлар тапшырылган, программалар тормышка ашырылган. Эш эшләнгән. Димәк, алга таба да эшлисе бар – 2018 елга инде яңа планнар, яңа программалар корылган. Беренче карашка, әкияткә охшап тора, билгеле. Икенче карашка да. Әмма әкиятләр сөйләнеп тора, ә эшләр – эшләнеп. Димәк, киләчәктә дә эшләнәчәк. Безнең Татарстан өчен әкиятләрне чынга ашыру – гадәти хәл ләбаса.

СЕЗНЕҢ РЕДАКЦИЯГЕЗ

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фарит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«Татмедиа» АҖ
Нәшер итүче:
«Татмедиа» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе:
900 сум 00 тиен

«ТАТАРСТАН»НЫҢ КАРТИНАЛАР ГАЛЕРЕЯСЫ®

ГЫЙНВАР. КАЗАН

А. Леухин, И. Нестеренко. Казан губернасы, XVIII гасыр (ТР Милли музеендагы тарихи экспозициясенең сәнгати проектына эскиз/ 2003 ел).

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

4. Төбәкләргә кемнән үрнәк алырга кирәк. Дәүләт башлыгыннан киңәш

16. Тукта, мизгел! Объективта – Яңа ел бәйрәме мизгелләре

24. Беренче заттан. Министрлар – җиңүләр, уңышсызлыклар һәм иртәгәгә бурычлар турында

32. Укучы иң яхшылар өчен тавыш бирә. Ел лауреатлары: «Татарстан» журналы версиясе

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

38. Татар ашлары. Итле бәрәңге тәкәсе: тагын бер милли ризык

42. Туган ягы – карлы бишек. Гомәр Бәширов эзләре буйлап

51. Гаҗәеп кешеләр арабызда. Пенсиягә чыккач – дөнья чемпионы!

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

56. Китап киштәсе. «Без бары дөньяны яхшыртырга теләдек...»

60. Талантлар эзлибез. һәм табабыз. «Татарстан» журналының Әдәби премиясе»нә кемнәр лаек булды

66. Тарих сәхифәләре. Һуннар короле – Аттила

70. Татар авыллары. Мулла Иле ничек яши

76. Уңганнар төбәге. Чирмешәнлеләрне нинди сыйфатлар аерып тора

86. Суганлы авыл. Ул кайда урнашкан

88. Туган як риваятьләре. Утташ чаты галәмәтләре

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: www.protatarstan.ru

PRESSA.RU

Фото: Карина Гизатуллина. Реклама

FURIA*

премиальные меха & трендовые модели

* Фурия.

Казань, ул. Н. Ершова, 1а
Торговый дом: Корстон, 1 этаж
тел.: (966) 250 03 83

furia_kazan www.furiamex.ru

СОБОЛЬ • КУНИЦА • РЫСЬ • ШИНШИЛЛА • НОРКА • ПУШНИНА

PRESSA.RU

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

22.12

Александр Сидякин, Татарстаннан РФ Дәүләт Думасы депутаты, «Бердәм Россия» генераль советы әгъзасы, – Мәскәүдә партиянең XVII съезды кысаларында оештырылган «Үз йортыңда хуҗа булу» дискуссия мәйданчыгында:

– 2018 елда шәһәр мохитен яхшырту өчен безнең республика бер миллиард сумга якын акча алачак. Ил күләмендә әлеге максатларга ел саен бюджеттан 25 миллиард сум акча бүленә – бу 20 мең ишегалды дигән сүз. Татарстанда һәр муниципаль берәмлектә уңайландырылган җәмәгать урыннары – кеше күп була торган урыннар бар. Хәзер без бу эшне конвейерга куячакбыз, мондый урыннар күп булырга тиеш. Мин кешеләр моны күрми-бәяләми калмаслар дип уйлыйм.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

31.12

Рөстәм Миңнеханов, ТР Президенты, – Татарстан халкына Яңа ел мөрәҗәгатендә:

– 2017 ел безнең республика өчен шактый нәтиҗәле булды. Нефть химиясе һәм машина төзелешендә тормышка ашырыла торган перспектив проектлар, киң күләмле модернизация икътисадый үсешне һәм барлык социаль программаларның үтәлешен тәэмин итте. Татарстанлыларның дүрт миллионга якыны үзләренең торак шартларын яхшыртты. Яхшы уңыш авыл хезмәтчәннәреннән республикабызга хезмәт бүләге булды. Рус төзелеш сәнгатенең гүзәл ядкарьләре – Свияжскиның Успение соборы һәм монастыре ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелде. Республиканың барлык уңышларында анда яшәүче һәр кешенең хезмәт өлеше бар, моның өчен сезнең барыгызга да ихлас рәхмәтемне белдерәм.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

16.12



Николай Дроздов, галим-зоолог, телевидение алып баручысы, МГУ профессоры, – Казан гимназиясендә, патриотизм һәм табигатькә мәхәббәт турындагы лекциясе вакытында:

– Татарстанның чын патриотында – җиңүче-барс холкы. Республика гербында нәкъ шул җәнлек сурәтләнгән бит.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Путин **КАЙСЫ** төбәкләргә соклана

Фотопрофессионаллар **НИЧЕК** эшли

Министрлар чишкән бурычлар **НИНДИ**

Укучы **КЕМ** өчен тавыш бирә

ТАТАРСТАНДА **ЯШИСЕҢ – «ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ!**

Газета-журналларга язылу кампаниясе тәмамланды. Безнең элекке дусларыбыз, киләсе яртыеллыкка да язылып, «Татарстан» журналы белән дуслыгын дәвам итә. Әлегә безнең белән булмаганнарга тиз арада безнең «Татарстан» коллективына кушылырга тәкъдим итәбез! Язылуны теләсә кайсы айдан башларга мөмкин.

БУА РАЙОНЫ

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА НИ ӨЧЕН ЯЗЫЛАМ

Марат Җаббаров, Буа муниципаль районы башлыгы:
– Бүген массакүләм мәгълүмат чараларының роле гаять зур һәм мөһим. «Татарстан» журналы күп еллар дәвамында республикабызда иң абруйлы мәгълүмат чыганагы булып кала бирә. Сез укучыларның мәхәббәтен яуладыгыз, хөрмәтенә ирештегез. Җәмгыятьне объектив, тирән һәм оператив мәгълүмат белән тәэмин итеп, беркайчан да үзегезнең социаль миссиягез – халыкка заманыбызның иң кискен һәм көнүзәк сорауларына җавап табарга ярдәм итү турында онытмыйсыз. Журнал социаль мөһим проектларны, куанычлы вакыйгаларны, заманыбызның казанышларын һәм авырлыкларын чагылдыра белүе белән укучы өчен кызыклы.
Сезгә иҗат илһамы, яңа идеяләр һәм хыялларыгызның уңышлы тормышка ашуын телим!

ЮГАРЫ ОСЛАН РАЙОНЫ

«ТАТАРСТАН» – ҺӘРВАКЫТ СЫЙФАТЛЫ, АКТУАЛЬ МАТЕРИАЛЛАР ДИГӘН СҮЗ

Марат Зыятдинов, Югары Ослан муниципаль районы башлыгы:
– «Татарстан» журналының төп өстенлекләренең берсе – һәрвакыт сыйфатлы, актуаль материалларның булуы. Республикада төрле тармакларның үсеше, аның кызыклы һәм талантлы кешеләре турында рәхәтләнеп укыйсың. Районнарга һәм аның кешеләренә багышланган мәкаләләрне уку бигрәк тә күңелле. Шуңа күрә журналны халык та яратып укый.

САРМАН РАЙОНЫ

«ТАТАРСТАН» УКЫРЛЫК МӘКАЛӘЛӘР КҮП БУЛГАН ЖУРНАЛ УЛ

Фәрит Хөснуллин, Сарман муниципаль районы башлыгы:
– Барлык оператив мәгълүматны бүген интернеттан алу мөмкинлеге булуы белән бәхәсләшеп торырга кирәкмидер. Әмма кәгазь басмалар – укучылар белән бөтенләй башка, күңел дәрәҗәсендә аралашу мөмкинлеге ул. Моның шулай булуын «Татарстан» журналының һәр саны раслап тора. Республикада барган үзгәрешләрне басма журналистлары гомумроссия икътисадында, мәдәниятендә, иҗтимагый тормышында барган үзгәрешләр контекстында күрсәтә. «Татарстан»да төрле яшьтәгеләр өчен кызыклы булган материаллар басылуы да күркәм күренеш. Редакция коллективына укучыларының күп булуын телим!

П 2381 – ТАТАР ТЕЛЕНДӘ **П 2378** – РУС ТЕЛЕНДӘ

Реклама 16+

ТАТАРСТАН 2017 ЕЛДА: БАРЫ ТИК ФАКТЛАР ГЫНА

«Күрәсезме, Татарстан ничек үсә, аңа карап сокланам мин, ул бит лидер», – кайчандыр Россия Президенты Владимир Путин әйткән әлеге сүзләр канатлыга әйләнде дияргә була. Гәрчә әлеге сүзләрдән соң дүрт ел вакыт үтсә дә, алар үзләренең актуальлеген югалтмады. Татарстан, элеккеге кебек үк, лидер төбәк, аңа сокланып кына калмыйлар, аңардан шактый нәрсәгә өйрәнәләр. Һәм тагын – Татарстан үзе дә укып-өйрәнеп туя алмый һәм үз алдына яңа бурычлар куя, тагын да катлаулыракларын. Туктау – артка калу дигәнне аңлата бит.

Абруйлы институтлар тарафыннан төзелгән төрле рейтинглар да республиканың ирешелгәннәрдә тукталып калмавын дәлилли. 2017 елда дөнья күргән, редакция фикеренчә иң күрсәтмәле шундый өч рейтингны «Татарстан» үзенең укучыларына да тәкъдим итә.

PRESSA.RU

РОССИЯ ТӨБӘКЛӘРЕ РЕЙТИНГЫ:

1
МӘСКӘҮ
76,54
балл

Россия башкаласының яшәү өчен иң уңайлы урын булуы беркемне дә гаҗәпкә калдырмыйдыр: биредәге потенциал Россиянең башка төбәкләре белән чагыштырып булмаслык югары. Бу нәтиҗәләрдән дә күренә. Мәсәлән, хезмәт хакының куллнучыларга күрсәтелә торган хезмәтләргә һәм товарларга нисбәте буенча Мәскәү – элеккечә үк лидер. Заманча уку йортлары саны буенча да. Әмма Россия башкаласының да кимчелекле ягы бар. Үзендә яшәүче бер кешегә туры килгән квадрат метрлар буенча Мәскәү 78 нче урында гына тора. Булган торак исә бик югары сыйфатлы. Торакны төзекләндерү һәм капиталь ремонтлау буенча Мәскәү икенче һәм өченче урыннарда бара.

2
САНКТ-ПЕТЕРБУРГ
76,49
балл

Иң мөһим күрсәткечләрдән берсе (хезмәт хакының чыгымнарга нисбәте) буенча Невадагы шәһәр башкаладан гына калыша. Керемнәре яшәү минимумыннан кимрәк, халык саны исә биредә Мәскәүдәгедән азрак. Бу күрсәткеч буенча Төньяк башкала Татарстаннан гына калыша – икенче урында. Питерның тагын бер казанышы – барлык төбәкләр арасында биредә эшсезлек дәрәҗәсе иң түбән булу. Санкт-Петербургта тузган торак иң азы һәм Россиядә иң төзек фатирлар. Дөрес, җан башына туры килгән квадрат метрлар саны буенча күрсәткеч бик начар (58 нче урын).

3
МӘСКӘҮ ӨЛКӘСЕ
68,55
балл

Мәскәү өлкәсенең төп казанышларыннан берсе – гражданнарның торак белән тәэмин ителеше. Биредә җан башына бүлеп санаганда иң күп квадрат метр туры килә. Миграцион үсеш буенча өлкәнең хәтта Мәскәүне дә артта калдыруы гаҗәп түгел. Мәскәү өлкәсендә эшсезлек дәрәҗәсе дә илдә иң түбәннәрдән (дүртенче урын).

4
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
63,12
балл

Тормыш сыйфаты рейтингында Мәскәү, Санкт-Петербург һәм Мәскәү өлкәсеннән генә калышып, Татарстан тагын бер тапкыр үзенең әйдәп баручы төбәк булуын раслады. Республиканың илдәге иң четерекле өлкәләрдән берсендәге уңышлары өчен иң күп балл җыюы аеруча мөһим. Татарстанда мохтаҗлар иң аз – биредә кереме яшәү минимумыннан кимрәк булган халык саны күрсәткече Россиядә иң түбән булып чыккан. Башка казанышлардан – системалы рәвештә физик культура белән шөгыльләнүчеләр саны буенча төбәкләрнең беренче өчлегендәге урыны. 2017 елда Россия шәһәрләренең тормыш сыйфаты рейтингында ТР башкаласының беренче урынга чыгуы – тагын бер мөһим казаныш.

ТОРМЫШ СЫЙФАТЫ*

5

КРАСНОДАР КРАЕ

61,97
балл

Көньяк кояшы һәм ике диңгез бу төбәккә байтак өстенлекләр бирә. Шунлыктан, Севастополь шәһәре, Кырым Республикасы һәм Ставрополь крае белән беррәттән, Краснодар краеның да һава торышының уңайлылыгы буенча алда баруы беркемне дә гаҗәпләндерми. Төбәкнең тагын бер казанышы – яхшы юллар. Аларның сыйфаты буенча Краснодар крае Россия төбәкләре арасында өченче урында бара.



6

БЕЛГОРОД ӨЛКӘСЕ

61,82
балл

Җан башына бүлеп исәпләгәндә, иң күп спорт корылмалары Белгород өлкәсенә туры килә. Спорт белән шөгыльләнүче хезмәт куючылар, студент һәм укучылар саны буенча төбәк өченче һәм дүртенче урыннарда бара.

7

ВОРОНЕЖ ӨЛКӘСЕ

58,87
балл

Воронеж өлкәсе бер елда рейтингта бер баскычка – сигезенче урыннан җиденчегә күтәрелгән. Күрсәткечләрнең күпчелеге буенча район – «алтын урталыкта».

***Тормыш сыйфаты җәһәтеннән Россия Федерациясенең иң шәп төбәкләре рейтингын «Яңалыклар» РМА» төзи.**

Рейтингны төзегәндә 72 күрсәткеч исәпкә алына, алар, агентлык белдерүенчә, «төбәктә яшәүче халыкның икътисадый үсеш дәрәҗәсеннән һәм керемнәреннән алып, халыкның төрле хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителеше һәм климат шартларына кадәр барлык аспектларын» сыйфатлый.

Башка сүзләр белән әйткәндә, безнең кузаллауда «тормыш сыйфаты» төшенчәсенә кергән бөтен нәрсә исәпкә алына: белем һәм лаеклы эш урыны алу мөмкинлеге, хезмәт хакы күләме һәм медицина хезмәте күрсәтү сыйфаты, торак шартлары, экология, ял итү сыйфаты (кино, театрлар, спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар) һ.б.

Мәгълүмат чыганаклары – «Росстат», РФ Сәламәтлек саклау, Финанс министрлыклары, РФ ҮБ, шулай ук төбәк хакимияте органнары сайтлары. Исәпкә алына торган һәр күрсәткеч өчен төбәккә билгеле бер күләмдә балл бирелә. Барлыгы иң күп балл җыйганнары тормыш сыйфаты иң яхшы булган төбәкләр булып чыга.

PRESSA.RU

РОССИЯ ШӘҺӘРЛӘРЕ РЕЙТИНГЫ:



1

КАЗАН

97%

Татарстан башкаласы, соңгы берничә ел буена беренчелекне бирмәгән Төмәнне кысрыклап, Россия шәһәрләренең 2017 елгы рейтингында тормыш сыйфаты буенча беренче урынга чыккан. Казанлыларның 97 проценты үз шәһәрен яшәү өчен уңайлыга саный, бер елда әлеге күрсәткеч 2 процентка арткан. Татарстан башкаласының төзеклек дәрәҗәсе шәһәр халкының 92 процентын, мәдәният учреждениеләре саны һәм аларның эш дәрәҗәсе 93 процентын канәгатьләндерә. Бу күрсәткеч буенча Казан Екатеринбургтан гына калыша. Респондентларның 91 проценты белем бирү дәрәҗәсеннән канәгать. Нәтиҗәләр сөендерә, ә киләчәк әле тагын да өметлерәк. Мәсәлән, сәламәтлек саклау өлкәсендәге вазгыятьтән әлегә шәһәр халкының яртысыннан кимрәге генә канәгать.

2

ТӨМӘН

96%

Сораштырылган төмәнлеләрнең 96 проценты үз шәһәрен яшәү өчен бик уңайлыга саный. Шәһәр халкы каладагы юллар торышына (респондентларның 94 проценты аларны яхшы, дип бәяли), җирле хакимиятнең шәһәрне төзекләндерүгә кертемнәренә (халыкның 79 проценты моннан канәгать) югары бәя биргән. Табигый ки, Төмән халкы туган шәһәрләренең төзеклек дәрәҗәсеннән дә канәгать: респондентларның 93 проценты аны бик югары бәяли.

3

ЯР ЧАЛЛЫ

95%

Сораштырылганнарның 95 проценты Чаллыдагы тормыш сыйфатыннан канәгать. Автокала халкы (респондентларның 90 проценты) туган шәһәрләренең төзеклек дәрәҗәсен бик югары бәяли. Шәһәр халкының торак-коммуналь хезмәтләр эшен югары бәяләве дә Чаллыга яшәү өчен иң уңайлы шәһәрләр өчлегенә керү мөмкинлеген биргән – бердә сораштырылганнарның 72 проценты ТКХ эшеннән канәгать. Бу – рейтингта катнашкан шәһәрләр арасында иң югары күрсәткеч. Сораштыруда катнашкан чаллылыларның 76 проценты үз йортларының халәтеннән канәгать – әлеге күрсәткеч Грозныйда гына югарырак.

4

ГРОЗНЫЙ

92%

Чечен Республикасы башкаласында яшәүче респондентларның 92 проценты да үз тормышыннан канәгать. Грозныйда яшәүчеләр үз йортларының халәтен рейтингка кергән барлык башка шәһәрләр халкыннан югарырак бәяли. Грозныйның төзеклек дәрәҗәсе сораштырылганнарның – 97 процентын, автомобиль юллары торышы 98 процентын канәгатьләндерә. Моннан тыш, Россиянең бүтән бер генә шәһәрендә дә ЮХИДИ хезмәткәрләре эшен биредәге кебек (95 процент) югары бәяләмиләр. Респондентларның 65 проценты үзен шәһәр хакимиятенә йогынты ясый ала, дип саный, бу күрсәткеч буенча грозныйлыларга тиңнәр юк.

ТОРМЫШ СЫЙФАТЫ*

5

ОРЕНБУРГ

91%

5

ТОМСК

91%

11

МӘСКӘҮ

Оренбургта да, Томскида да туган шәһәрләрендә яшәү шартлары сораштырылганнарның 91 процентын канәгатьләндерә. Томскиның «фишкасы» – аның университетлары, респондентларның 96 проценты яхшы белемне башкалаларда түгел, ә нәкъ менә үз шәһәрләрендә алып була, дип саный. Бу – рейтингка кергән шәһәрләр арасында иң югары күрсәткеч.

***Россия шәһәрләренең тормыш сыйфаты буенча рейтингын ел саен «Росгосстрах» компаниясенең Стратегик тикшеренүләр үзәге төзи.**

Тикшеренүнең кыйммәте шунда ки, илнең зур шәһәрләрендә яшәү уңайлылыгын аларның үзләренең халкы бәяли. Үз калаларының тормыш өчен уңайлы булуы белән килешүче респондентлар өлеше иң күп булган шәһәрләр рейтингта беренче урынга чыга. Бу вакытта берничә төп критерий исәпкә алына: ТКХ торышы, белем бирү һәм медицина хезмәте күрсәтү сыйфаты, транспорт инфраструктурасы, шәһәр хакимиятендәге фаразланган коррупция дәрәҗәсе һ.б.

Татарстан – РФнең рейтингның топ-дистәсенә берьюлы ике шәһәре эләккән бердәнбер төбәге.

PRESSA.RU

РФ СУБЪЕКТЛАРЫНДА ИНВЕСТИЦИОН

1
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Татарстан Россия Федерациясе субъектларында инвестицион климат торышы милли рейтингында икенче ел рәттән беренче урынга чыга. РФнең өч ел буена топ-15 рейтингына кергән сигез төбәгеннән берсе.



2
ЧУВАШИЯ РЕСПУБЛИКАСЫ

Татарстан күршесендәге төбәк бер ел эчендә рейтингның алтынчы позициясеннән икенче урынга күтәрелгән. РФнең өч ел буена топ-15 рейтингына кергән сигез төбәгеннән берсе.



3
МӘСКӘҮ

Россия башкаласы, 2016 елгы унынчы позициясеннән кискен ыргылыш ясап, рейтингның өченче урынына күтәрелгән. Мәскәү – инвестицион климат сизелерлек яхшырган 19 төбәктән берсе.



4
ТУЛА ӨЛКӘСЕ

Өлкә рейтингтагы былтыргы дүртенче урынын һәм Россиядәге инвестицион җәлеп итүчәнлеге тотрыклы үскән 16 төбәк арасындагы урынын саклап калган.



5
КАЛУГА ӨЛКӘСЕ

Күп төбәкләр өчен бишенче урын уңышлы саналыр иде, әмма калугалылар өчен түгел. Былтыргы өченче урыннан соң быелгы нәтиҗә – кечкенә булса да, барыбер артка бер адым.

РФ субъектларында инвестицион климат торышы Милли рейтингы топ-20 2017 елның җәендә Петербург халыкара икътисадый форумы мәйданчыгында тәкъдим ителде.

КЛИМАТ ТОРЫШЫ МИЛЛИ РЕЙТИНГЫ

РФ субъектларында инвестицион климат торышы Милли рейтингын Стратегик инициативалар агентлыгы әйдәп баручы эш берләшмәләре белән берлектә төзи һәм ул төбәк хакимиятләренең уңайлы бизнес мохите формалаштыру буенча эшенең нәтиҗәлелеген бәяли.

2017 елда ул беренче тапкыр барлык төбәкләрне дә колачлады һәм инвестклиматның сыйфатын динамикада бәяләү мөмкинлеге бирде (2016 елда тикшеренү шулай ук РФнең барлык субъектларында үткәрелде, әмма Ненец һәм Чукотка автоном округлары, Кырым Республикасы һәм Севастополь рейтингтан тыш бәяләнде). Рейтинг күрсәткечләре системасы инвестицион климат халәтен бәяләүгә юнәлтелгән иң яхшы Россия һәм дөнья тәҗрибәсен исәпкә алып эшләнгән.

Рейтинг 45 күрсәткечтән гыйбарәт, алар дүрт юнәлеш тәшкил иткән 17 факторга төркемләшә: Регуляторлык мохите, Бизнес институтлары, Инфраструктура һәм ресурслар, Кече эшкуарлыкка ярдәм итү. Аерым алганда, төбәктә бизнес өчен төрле дәүләт хезмәтләре күрсәтү нәтиҗәлелеге күрсәткечләре бәяләнә (хезмәт күрсәтү вакыты, процедуралар саны һәм эшкуарларның типлаштырылган административ процедуралардан канәгатьлеге (мәсәлән, юридик затларны теркәү, төзелешкә рөхсәт бирү, лицензияләр бирү, күчемсез милеккә мөлкәт хокукын теркәү, электр челтәрләренә тоташтыру).



6

ТӨМӘН ӨЛКӘСЕ

Инвестицион климат торышы рейтингында төбәк, былтыргы белән чагыштырганда, бер баскычка аскарак төшкән. Шулай булса да, Төмән өлкәсе – РФнең өч ел буена топ-15 рейтингына кергән сигез төбәгеннән берсе.



7

КРАСНОДАР КРАЕ

Төбәк РФнең озак вакытлы динамикада (2015–2017 еллар) тотрыклы үсеш күрсәткән 16 субъекты арасына керә. Әмма бер адым алга киткән ул төбәк арасына кермәгән – җиденче позициядә калган.



8

ВОРОНЕЖ ӨЛКӘСЕ

Инвестицион климат халәте рейтингында бер ел эчендә үзенең элекке урынын 15 позициягә яхшыртып, иң яхшылар дистәсенә ыргылып барып кергән төбәк. Воронеж өлкәсе егерме әйдәп баручы төбәк арасында интеграль күрсәткеч буенча иң яхшы динамика күрсәткән.

9

МӘСКӘҮ ӨЛКӘСЕ

Төбәкнең бер ел эчендәге алгарышы таң калдыра. Рейтингтагы 21 урыннан ул тугызынчы урынга күтәрелгән. Мәскәү өлкәсе – Россиянең интеграль рейтингка иң күп балл өстәгән биш төбәгеннән берсе.

Россия Президенты ярдәмчесе Андрей Белоусов:
«Безнең игътибарны нәтиҗә күрсәткән, башкаларны өйрәтерлек төбәкләргә юнәлтәсебез килде. Бүген илне алга әйдәүчеләргә һәм бизнесны үстерү буенча яхшы нәтиҗә күрсәтүчеләргә карау мөһим».

PRESSA.RU

Mercedes-Benz йөк машиналарының Евро-5 двигательле яңа буыны

ЯР ЧАЛЛЫДА **ЯСАЛГАН**

2017 ел Россия йөк машиналары базары өчен уңышлы булды. Тулы массасы алты тоннадан авыррак булган техниканы сату бер ярым тапкырга диярлек артты, чит ил маркалы йөк машиналарына ихтыяҗ исә тагын да активрак үсте.

ЯҢА МОДЕЛЬЛӘР ПРЕМЬЕРАСЫ

Узган елның сентябрендә «ДАЙМЛЕР КАМАЗ РУС» ҖЧҖ Мәскәүдәге «Комтранс» күргәзмәсендә яңа продуктлар – Евро-5 двигательле Actros, Arocs[1] йөк машиналарын, яңартылган Unimog һәм Atego[2], шулай ук Россия базары өчен урта тоннажлы Mitsubishi Fuso Canter TF[3] йөк машиналарын тәкъдим итте. Компания җитәкчелеге әйтүенчә, яңа буын Actros машинасы Mercedes-Benz маркасын Европа йөк машиналары маркалары арасында беренче урынга чыгарырга булышырга тиеш. Ә Canter моделенең яңа буыны 2017 елда җитештерү күләме кабат үсә башлаган Mitsubishi Fuso йөк машиналары белән кызыксынуны тагын да арттырыр, дип өметләнәләр. Йөк машиналарының әлеге ике моделен, шулай ук төзелеш сегменты өчен яңа Arocs машинасын Яр Чаллыдагы конвейерда быел ук җыя башлаячаклар. Хәзер компания дилерлар челтәрен һәм клиентларны яңа продуктларга актив әзерләү, аларга тулы сервис хезмәте күрсәтүне оештыру белән мәшгуль. Базарның яңа машиналарны ничек кабул итәчәген вакыт күрсәтәчәк, әмма автомобиль җитештерүчеләр уңай нәтиҗәләргә генә өметләнә.

Әлегә исә Яр Чаллыдагы мәйданчыкта моннан алдагы буын йөк машиналарын җыялар, һәм аларны җитештерү күләме, ихтыяҗга бәйле рәвештә, тотрыклы арта бара.

ЫШАНЫЧЛЫ ЙӨК МАШИНАЛАРЫ

Автомобильнең сыйфаты турында сүз барганда, һичшиксез, иң беренче булып өч нурлы йолдызлы атаклы марка күз алдына килә.

Илнур Каюмов, «ДАЙМЛЕР КАМАЗ РУС» ҖЧҖ җитештерү буенча директоры:

– Daimler компаниясе йөк машиналары сегментының шигаре – «Ышанычлы йөк машиналары» – автомобильләрнең кайда җитештерелүенә карамастан, Германиядәме, Һиндстандамы, Төркия яки Россиядәме, үзенең вазыйфасын үти. Сыйфат һәр җирдә бер үк төсле – иң югары дәрәҗәдә. Һәм ул заманча технологияләр, сыйфатны контрольдә тотуның күп зоналы системасы һәм бик катгый аудит системасы белән генә тәэмин ителми, иң мөһиме – компания персонал сайлау һәм өйрәтүгә дә бик таләпчән. Компания җитәкчелеге 2017 елның августыннан өч сменалы эшкә күчү турында карар кабул итте. Шуңа бәйле рәвештә, штатны арттыру да таләп ителде. Моның өчен без меңгә якын кеше белән сөйләштек! Әгәр без кешене эшкә алабыз икән, аны ныклап өйрәтә башлыйбыз. Компания үзе укыту методикаларын һәм курсларын эшләде, без остазлык мәктәбен дә нәтиҗәле файдаланабыз. «ДАЙМЛЕР КАМАЗ РУС» компаниясенең гади эшчеләре дә сызымнарны укый белүләре белән мактана ала, техник документациягә яхшы аңлый. Өч сменалы эшнең беренче айлары предприятиебезнең ихтыяҗ базары сынавын яхшы үтүен күрсәтте. Алай гына да түгел, тагын да активрак үсәргә кирәк әле. Һәм без алга барабыз – 2018 елның гыйнварыннан җитештерүнең тулы куәтенә чыгабыз. Бүген мин ыша-

Реклама

Фото: Александр Ефремов

Компания турында

2010 елда автомобиль җитештерүнең ике гиганты – Германиянең «Даймлер АГ» концерны һәм «КАМАЗ» ГАҖ стратегик хезмәттәшлек турында килешү имзалаган һәм уртак предприятие төзелгән, ул 2016 елдан «ДАЙМЛЕР КАМАЗ РУС» дип атала. Бүген компания базарга коммерция техникасының өч брендын – Mercedes-Benz, Fuso һәм Setra[4] – тәкъдим итә. Яр Чаллыда эре узеллы җыю ысулы белән стандарт һәм шәхси комплектацияләрдә йөк автомобильләре җитештерү компания эшчәнлегендәге төп юнәлешләрнең берсе булып тора. 7 елдан артыграк вакыт эчендә «КИП «Мастер» технопаркы мәйданчыгында урнашкан предприятие капкасыннан меңләгән тираж белән Actros, Axor[5], Atego йөк машиналары, шулай ук Россия тимер юллары өчен җыелган күпфункцияле Unimog локомобильләре чыккан. Заводның гомуми мәйданы 33 мең квадрат метрны тәшкил итә. Анда ике җыю линиясе, буяу участогы, әзер продукцияне кабул итү һәм саклау зонасы, офис биналары, укыту үзәге һәм комплектлар комплектлаштыру детальләре склады урнашкан.

[1] Актрос, Арокс, [2] Унимог һәм Атего, [3] Мицубиси Фусо Кантер ТФ, [4] Сетра, [5] Аксор

нып әйтә алам: безнең коллектив – иң яхшылардан берсе, һәм бу һич кенә дә мактану түгел.

Предприятие ISO/TS 16949:2009 стандартлары таләпләренә яраклылыкка сертификатлаштыру үтте. Быел яңа IATF 16949:2016 стандартына күчәргә планлаштырабыз.

Без һәрвакыт үсештә һәм теләсә нинди үзгәрешләргә уңай карыйбыз. Әйтик, 2017 елда компания Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең сыйфат өчен премиясен алу бәйгесендә катнашты. Бу безнең өчен бөтенләй яңа нәрсә иде. Сертификатлаштыру органнары белән эшләргә күнеккән без үзе, аларның бөтен таләпләрен беләбез. Биредә исә башка караш, башка кешеләр, аудиторлар иде. Бик кызыклы, безнең тәҗрибә өчен файдалы процесс булып чыкты. Дипломант булуы барыбыз өчен дә бик әһәмиятле һәм күңелле вакыйгага әйләнде. Тик, дөресен әйткәндә, уңышка ирешәчәгебездә шикләнмәгән дә идек! Чөнки безнең компания һәрвакыт клиентларның канәгатьлек дәрәҗәсен арттыруны кайгырта.

ИНВЕСТИЦИЯЛӘР

2018 елда «ДАЙМЛЕР КАМАЗ РУС» ҖЧҖ коллективы алдында катлаулы бурыч тора – биредә җыела торган йөк машиналары модельләрен тулысынча яңарту. Моннан тыш, Яр Чаллыда 2016 елның мартында төзелә башлаган яңа заводта якын арада кабиналар җыюга керешәләр. Андагы җитештерүнең проект куәте елына 55 мең кабина булырга тиеш. Җитештерү эретеп ябыштыруны һәм буяуны да үз эченә ала. Завод үз продукциясен КАМАЗның төп конвейеры һәм Россиядәге Mercedes-Benz заводы өчен җитештерәчәк. Яңа предприятиене сафка бастыру 2019 елга билгеләнгән. Шул рәвешле технологик кооперация республикабызга өр-яңа технологияләр генә китереп калмый, бәлки эш урыннарының һәм компания хезмәткәрләренең муллыгы артуын да тәэмин итә.

2015 елда «ФУЗО КАМАЗ Тракс Рус» ҖЧҖ белән «МБ Тракс Восток» ҖЧҖ кушу проекты уңышлы тормышка ашырыла, ул административ идарәне һәм җитештерү процессларын оптимальләштерү мөмкинлеген бирә.

Яңа модельне чыгара башлаганда мәйданчыкта чит илдәге партнер-компанияләрдән тренерлар катнаша. Тәүге тапкыр җыю бары тик алар катнашында һәм алар өйрәтүендә генә башкарыла. 2018 елда завод каршында бурыч тора – аз тоннажлы Mitsubishi Fuso автомобильләренең яңа модельләрен чыгаруга тулаем күчү.

Механикалаштырылган җыю эшләре слесарьлары бригадиры Николай Буйлин хатыны Анастасия һәм улы Никита белән. Кечкенә булса да, династия дияргә мөмкин, компаниядә мондый гаиләләр шактый. Әйтүләренчә, белгечләрне заводка лаеклы хезмәт хакы гына түгел, уңайлы эш шартлары һәм социаль яктан якланган булу да җәлеп итә.

PRESSA.RU

БӘЙРӘМ *каникуллары*

ПРОФЕССИОНАЛЛАР ЭШЛИ

Соңгы вакытларда гыйнвар ае елның иң матур айларыннан берсе санала башлады. Һәрхәлдә, Татарстанда бу шулай. Бигрәк тә табигать кануннары буенча урамда караңгы булырга тиеш вакытта. Караңгы төнне чыршы утлары җемелдәве, гирлянда-фонарьлар һәм башка бәйрәм уңае белән урнаштырылган иллюминацияләрнең балкышы яктырта. Халык урамда ял итә, балалар гөр килә, социаль челтәрләрне Казанны чагылдырган кадрлар бизи – гыйнвар аенда башкалабызны күрергә килүче кунаклар шулкадәр күп икән. Шулай да канәгать елмаюлы селфилар һәм һәвәскәр «чи-и-из!»лар һөнәри кадрлар каршында югалып калалар кебек.

Фото: Рөстәм Миңнеханов, Ната Смирнова

Бу кышкы көннәрдә үз объективларына һәр мизгелне «тотарга» сәләтле ике оста фотограф – Татарстан Президенты һәм «Татарстан» журналы фотохәбәрчесе профессионалларча эшли. Бүген без аларның эшләрен «Татарстан» журналында «Бәйрәм каникуллары» фотопроекты аша сезгә дә күрсәтергә булдык.



PRESSA.RU


ТЕРРАСА
LOUNGE BAR
РЕСТОРАН
РЕСТОРАН
РЕСТОРАН


Фото
rusminikhanov
Kazan, Tatarstan
Нравится marina.konovalova2018 и еще 955
rusminikhanov Хәерле иртә Татарстаным!
Посмотреть все комментарии (11)


Instagram
rusminnikhanov
Нравится: 8 392
rusminnikhanov #ПаркиТатарстана
Посмотреть все комментарии (53)

PRESSA.RU


Фото
rusminikhanov
Tatarstan
Нравится: 866
rusminikhanov Хәерле кич, ни хәлләр дусларым?
Посмотреть все комментарии (18)
ПОКАЗАТЬ ПЕРЕВОД


Публикация
rusminnikhanov
Нравится: 10 034
rusminnikhanov #ПаркиТатарстана


Instagram
rusminnikhanov
Нравится: 8 392
rusminnikhanov #ПаркиТатарстана
Посмотреть все комментарии (53)


Фото
rusminikhanov
Kremlin de Kazán
Нравится: 770
rusminikhanov Новогодняя сказка у Казанского Кремля!
Посмотреть комментарии

PRESSA.RU

Реклама 16+

ТУКТАУ – ДИМӘК, **АРТКА КАЛУ**

Беренче затлардан алынган мәгълүматтан да төгәлрәге бармы икән? Шул турыда истә тотып, «Татарстан» журналы 2017 елны озатканда республикабыз министрлыклары һәм ведомстволары җитәкчеләренә мөрәҗәгать итте – сорауларыбызга кыска һәм төгәл җавап бирүләрен һәм узып киткән елдагы иң күркәм җиңүләрне һәм уңышсызлыкларны, беррәттән 2018 елда алынырга тиешле биеклекләрне дә атауларын үтенде. Министрларның җавапларына бәя бирү – сезнең хозурда.

«Татарстан» журналы сораулары:

1

Бары тик бер күренешкә генә таянып, 2017 елда министрлык алып барган эшчәнлек турында сөйләү мөмкинлегегез бар, ди. Кайсын искә алырсыз?

2

Министрлык чишкән иң җитди бурыч нинди булды?

3

Узган елда нәрсәләрне эшләп булмады? Ни өчен?

4

2018 елда нинди бурыч һичшиксез хәл ителергә тиеш?



Эдуард Вафин,
Татарстан Республикасы буенча Россия Пенсия фонды бүлекчәсе идарәчесе:

1

– Бик дулкынландыргыч мизгел иде ул. Башкарылган эшкә йомгак ясар һәм киләчәккә бурычларны билгеләр өчен, Россия Пенсия фонды идарәсенең киңәйтелгән утырышына бөтен илдән килгән хезмәттәшләребез җыелган иде. Әлеге очрашу ахырында ел саен үткәрелә торган иң яхшы территориаль орган конкурсына нәтиҗә ясалды. Көтмәгәндә ни ишетәм: безнең бүлекчәбез «Россия Федерациясе Пенсия фондының 2016 елгы лидеры» исеменә лаек булган төп лауреат дип танылды! Ул чакта нинди хисләр кичердемме? Республикам һәм командам өчен сүз белән аңлатып бетерә алмаслык горурлык.

РПФ безгә бик күп зур проектларны ышанып тапшыра. Без ел саен Россиянең 20ләп «пилот» проектында катнашып, аларны уңышлы тормышка ашырабыз. 2017 елда Иннополис базасында Россиядәге иң зур яңа буын – IT-системаларының берсе эшләтеп җибәрелде. Әлеге автоматлаштырылган мәгълүмати система (АИС ПФР-2) шәхси хисап, ана капиталы мәгълүмат базасын, халыкка социаль ярдәм күрсәтүнең һәм пенсионерларның федераль базасын туплый. Бу – бик зур масштаблы проект, һәм аны нәкъ менә безгә ышанып тапшырдылар! Әйе, без бер урында таптанмыйбыз, камилләшәбез, заман белән бергә атлыйбыз.

2

– Без хәл итә торган барлык мәсьәләләр дә үтә җитди дип саныйм. Үзегез уйлап карагыз, 1 миллион 135 мең чамасы татарстанлыга һич тоткарлыксыз рәвештә пенсия, төрле социаль ярдәм билгеләү һәм түләп бару – җитди бурычмы? Әлбәттә, шулай!

Менә икенче мисал. Хәзер Пенсия фондының барлык хезмәтләре дә диярлек электрон рәвештә тәкъдим ителә, ә сүз 50дән артык сервис турында бара! Әйе, кеше диванда яткан килеш кенә үзенә пенсия билгеләү турында гариза тапшыра ала, индивидуаль шәхси хисабыннан өземтә соратырга, пенсия китерү ысулын үзгәртергә, эш бирүченең аның өчен иминият кертемнәрен түлиме-юкмы икәнен тикшерергә һәм башка бик күп эшләр башкарырга мөмкин. Республикабызда барлык хезмәтләрнең 80 проценттан артыгы электрон рәвештә башкарыла. Бу, һичшиксез, уңыш.

Соңгы мисаллардан. 2017 елда РПФның мобиль кушымтасы эшләнде һәм тәкъдим ителде. Әлеге программа ярдәмендә без хезмәт күрсәтүләрне халыкка тагын да якынайттык һәм уңайлыландырдык. Бу кушымтадан файдаланмый калмагыз, пенсия фондындагы хисабыгызның торышы турында мәгълүматны иң оператив рәвештә алып торырга мөмкинлек бирә ул.

3

– Бер хәйләсез, яшермичә әйтә алам: планлаштырган һәр нәрсәне без уңышлы тормышка ашырдык.

4

– Якындагы елларга төп бурычыбыз – алдынгы урыннарны саклап калу. Һәм бу очракта төп өч нигезне онытмаска кирәк. Болар – идарә, технологияләр һәм кеше ресурслары. Хәер, без онытмыйбыз да. Әйтик, 1 гыйнвардан, берничә территориаль органыбызны үзгәртеп, Яр Чаллыда һәм Әлмәттә ике районара идарә булдырдык.

Технологияләр турында. 2018 елда Инвалидларның федераль реестрын (ФРИ) һәм Социаль тәэмин итү буенча бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (ЕГИССО) гамәлгә кертү эшен дәвам итәчәкбез. Әлеге федераль «пилот» проектларны тормышка ашыручылар исемлегенә барлыгы сигез төбәк, шул исәптән безнең республика да элакте. Проектларны эшләтеп җибәрү социаль ташламаларның бөтен комплексын күз алдында тотарга мөмкинлек бирә, димәк, социаль чыгымнарның нәтиҗәлелеген, гражданнарның со-

Фотолар: РФ Пенсия фондының ТР буенча Төбәк бүлекчәсе матбугат хезмәтеннән алынды

циаль ярдәм алу турында хәбәрдарлык дәрәҗәсен арттырырга юл ача.

Өченче нигез турында. Без РПФ клиент хезмәтләренә бәя бирү һәм контрольдә тотуны, коррупциягә каршы көрәшне күздә тоткан уникаль система керттек. Хәзер клиент хезмәтенең һәр кабинасында язмаларны билгеле бер вакыт аралыгында саклый торган, микрофон көйләнгән камералар һәм күрсәтелгән хезмәтне аерым бәяләү мөмкинлеге бирә торган җайланмалар куелды. Ил пенсия фонды органнарының берсендә дә әлегә болар юк. Безгә исә ул гражданнардан кергән нигезсез шикаятьләр санын киметергә һәм, әлбәттә, бүлекчәбезнең гомуми абруен күтәрергә булышачак. Яңа система ришвәтчелекне кисәтүгә ярдәм итеп кенә калмыйча, низаглы хәлләргә, видеоязманы карый-карый, түгәрәк өстәл артында бергәләп тиз арада чишелеш табу мөмкинлеге бирәчәк.

“ – Якындагы елларга төп бурычыбыз – алдынгы урыннарны саклап калу. Һәм бу очракта төп өч нигезне онытмаска кирәк. Болар – идарә, технологияләр һәм кеше ресурслары.

PRESSA.RU

Владимир Леонов,
Татарстан Республикасының яшьләр эшләре һәм спорт министры:

1

– 2017 ел башында без Red Bull Air Race вәкилләрен кабул иттек. Самолетларның каян күккә күтәреләчәген сөйләштек. Аэродром урынына... Kazan Ring автодромы трассасын кулланырга тәкъдим ясадык. «Ничек инде?» – дип аптырашта калды ярышны оештыручылар. Без аларны автодромга алып барып, бөтен нәрсәне күрсәттек: менә шулай итеп оештырачакбыз, борылыш траекториясе кыскарачак, техникага йөкләнеш азрак төшәчәк, чыгымнар да мөмкин кадәр түбәнәячәк, дип аңлаттык. Шундый җентекле эштән соң, алар безне хөрмәт итә башлады. Тамашачылар спорт җиңүләрен күрсен өчен, без әүвәл оештыру эшендә, имидж казану өлкәсендә үз җиңүләребезне яуларга тиешбез. Без 2017 елның төп вакыйгасы – Конфедерацияләр кубогы уеннарына да шул рухта әзерләндек. FIFA комиссиясе белән эшебез турнирдан күпкә алданрак башланды. Казанга сәфәрләренең берсендә Су спорт төрләре буенча дөнья чемпионаты ярышларын ничек оештыруыбызны күрсәттек. Безнең материаллар аларны таң калдырды. «Казан бу су чемпионатын уздырган икән, футбол чемпионатын берсүзсез үткәрә алачак», – диде шулчакта кунакларның берсе.

2

– Бу бер ел өчен генә куелган мәсьәлә түгел, дияр идем, хәзер инде аның республикабыз тарафыннан тиешенчә башкарылуы турында һич шикләнмичә белдерә алабыз. Оештыручыларны чакыра торган як булудан туктап, Татарстан үзендә нәрсә уздыруны сайлау мөмкинлегенә ия кабул итүче төбәккә әйләнде. Мәсәлән, Конфедерацияләр кубогы матчлары уздырылырга тиешле шәһәрләр исемлеге берничә тапкыр үзгәртелде, әмма Казан бу исемлектә һәрчак кала килде. Шәһәребез бик зур игътибар үзәгендә булды, чөнки бездә иң яхшылар – Россия, Мексика, Германия җыелма командалары уйнады... Шуннан да уңышлырак уен челтәрен күз алдына да китерү кыен. Матчларны оештыру ягыннан Казан иң алдынгы шәһәрләрнең берсе дип танылды. Моннан тыш, Россиядә беренче булып Red Bull Air Race узышлары этабын уздыруыбыз да спорт җәмәгатьчелеген тәэсирләндерде. Санкт-Петербург белән дә, Сочи белән дә сөйләшүләр алып барылган, әмма ярышны оештыручылар нәкъ менә безне сайлады. Шул ук вакытта узышлар өчен республика бюджетыннан бер тиен дә алынмады: барлык чыгымнарны Red Bull ширкәте һәм «Татспиртпром» күтәрде. Бу узышлар күп яктан игътибарга лаек яңалык булды. Хәтта Россиянең һава транспортына кагылышлы кануннары өчен дә. Берничә дистә елда беренче тапкыр аңа үзгәреш кертелде һәм 50 метрдан түбәнрәк очышларга рөхсәт бирелде. Казан өстендәге виражлар сурәтләнгән фотографияләр, Бөекбританиянең иң зур газеталарыннан берсе булган The Daily Telegraph (Дэйли Телеграф) әйтүенчә, берничә тапкыр «көн картинасы» дип танылган. Red Bull Air Race белән килешү тагын ике елга озайтылган һәм 25 августта, Будапешт, Абу-Даби, Порту, Сан-Диего һәм башка шәһәрләр белән тиңдәш булып, Казан әлеге мавыктыргыч тамашаны янә уздырачак.

3

– Аерым бер нәрсәләрне эшли алмадык дип, анык кына әйтә алмыйм. Ләкин бер утыруда гына хәл ителми торган катлаулы, күләмле мәсьәләләр бар. Татарстан профессиональ спорт белән берлектә гаммәви спортны да актив үстерә. Ел саен берничә дистә яңа спорт корылмалары барлыкка килә (2018 елда аларның саны йөздән артачак). Шунлыктан республика профессиональ тренерларга бик зур кытлык кичерә. Спорт академиясе бу юнәлештә актив эш алып бара, инде өч чыгарылыш әзерләде. Безнең бурыч – белгечләрнең барысы да монда калсын, эшкә урнашсын өчен, шартлар тудыру. Әлеге юнәлештә Татарстан Президенты да зур булышлык күрсәтә. Алдыбызда торган тагын бер мәсьәлә – Пхёнчханда узачак Олимпия уеннары. Гыйнвар ахырына кадәр Халыкара Олимпия комитеты Россия лицензияләренә кертелгән спортчыларның исемлеген расларга тиеш. Ул ничек эшләнәчәк – билгесез, чөнки Россия Олимпия комитетының ХОКта әгъза буларак эшчәнлеге вакытлыча туктатылды. Шул ук вакытта Пхёнчханда чыгыш ясарлык кандидатлар арасында Татарстаннан да берничә спортчы бар, атап әйткәндә, чаңгычылар Анна Нечаевская һәм Андрей Ларьков, фигуралы шуучы Евгения Тарасова, сноубордчылар Влад Хадарин, Валерий Колегов, Милена Быкова, шулай ук Россия җыелма командасына чакырылырга мөмкин «Ак Барс» хоккейчылары... Безнең спортчыларыбыз, башка яшь атлетлар Олимпиадага бару мөмкинлеге алса һәм анда чыгыш ясаса, бу инде уңыш дигән сүз. Без бит Россия җыелма командасы өчен, ул нинди составта булса да, җан атачакбыз.

4

– Без футбол буенча дөнья чемпионаты матчларын һичшиксез иң югары дәрәҗәдә үткәрәчәкбез. Җирәбә нәтиҗәсендә алты матчны кабул итү хокукы алдык, һәм безгә кабат иң яхшы командалар килә. Телетрансляцияләр күләме Олимпия уеннарыныкыннан калышмас, дип күзаллана. Казан зур бәйрәмнәр, ярышлар оештыру эше белән идарә итә белә, бездә бөтен кирәкле инфраструктура бар, министрлыклар һәм ведомстволар алдан билгеләнгән план нигезендә үзара җайланган эш алып бара. Бу мәсьәләне уңышлы хәл итү өчен бөтен форсат – кулыбызда. Татарстан, югарыда искә алынганча, күп мәсьәләне берьюлы башкарырга сәләтле, без берничә проектны бергә чынга ашырабыз. Көз көне республикада беренче тапкыр Йөзү буенча дөнья кубогы этабын уздырачакбыз, моңарчы ул Мәскәүдә үткәрелә иде. Без бу юнәлештә максатчан эш алып бардык һәм теләгебезгә ирештек. Республика белән Халыкара йөзү федерациясе арасында Кубок этабының 2018–2022 елларда Казанда үткәрелүе турында килешү имзаланды. 2022 елда Кыска сулыкта йөзү буенча дөнья чемпионатын кабул итәчәкбез. WADA оешмасының Россиядә дөньякүләм ярышларны уздырмаска кушкан күрсәтмәсенә карамастан, FINA турнирның бездә үткәрелүе турындагы бертавыштан кабул итте. Бик зур булмаса да, төп чемпионатларның берсе ул. Бу – безнең өчен җиңү, FINA тарафыннан күрсәтелгән ышанычны югары дәрәҗәдә акларга планлаштырабыз. Татарстандагыча итеп әйтсәк, тынычланырга, эшсез торырга ярамый.

Фото: Ната Смирнова

PRESSA.RU

Сергей Иванов,
Татарстан Республикасының Туризм буенча дәүләт комитеты рәисе:

1

– Без быел беренче тапкыр халыкара статус алган «Бөек Болгар – 2017» Урта гасырлар сугышы фестивален‑ә әзерләнә идек. Якын һәм ерак чит илләрдән гаять кызыклы командалар килергә җыенган иде. Һәм һич көтмәгәндә, фестивальгә күпмедер вакыт кала, чит ил кунакларының бер өлешендә Россиягә керү визасы юклыгы ачыкланды. Европада һәм башка илләрдә визасыз гына сәяхәт итәргә күнеккәннәр, Россиягә сәфәр кылганда виза кирәклеге аларны берара каушатып калдырды. Өстәвенә, вакыт ягының соңгы чиккә килеп җитүе дә хәлне катлауландыра иде. Без бу мәсьәләне хәл итү өчен бар тырышлыкны эшкә җиктек. Мөгаен, оештыру һәм коммуникация ягыннан иң кыены шунда булгандыр да. Нәтиҗәдә, барысына да өлгердек, Көнчыгыш Европа һәм Якын Көнчыгыштан килергә теләк белдергәннәрнең һәркайсы фестивальдә катнаша алды. Шулкадәр тырышлык салуыбыз беребезгә дә үкенечле түгел иде. Әлеге фестивальдә 47 мең кеше булып китте, Россиянең 35 төбәгеннән кунаклар килде. Бу әле катнашучы командаларны санамаганда. Фестиваль кысаларында беренче тапкыр Тарихи урта гасырлар сугышы халыкара ассоциациясе (HMBIA) кул астында Европаның клуб чемпионаты узды. Хәзер «Бөек Болгар» – Россиядә мондый фестивальләрнең иң массакүләм рәвеш алганнарыннан берсе. Минем өчен ул узган елның иң төп туристлык вакыйгасы. Без үзебезнең Бөек Болгар белән бәйле төп максатыбызга – аны Россиядә һәм дөньяда тарихи реконструкцияләр уздырыла торган иң билгеле урынга әверелдерү юнәлешендә бик зур адым ясадык. Без командалар санын арттырырга, аларның статусын күтәрергә һ.б.ны планлаштырабыз. Бу территориянең потенциалын җыен кунакларыннан килгән бихисап уңай бәяләмәләр раслый. Аларны фестивальнең тарихи эчтәлеге генә түгел, ә иң беренче чиратта, Болгарның тарихилыгы, андагы тиңдәшсез, гаҗәеп атмосфера тәэсирләндергән.

2

– Мин моны Свияжск утраушәһәренә круиз навигациясен ачу булды, дип әйтер идем. Без Идел буйлап югарыга таба да, түбәнгә таба да елга сәяхәтләре оештыра торган барлык туристлык ширкәтләре белән сөйләшүләр уздырдык. Һәм менә быелтыр су төбен тирәнәйтү эшләре тәгәлләнгәч, дистә еллардан соң беренче тапкыр, Свияжск пристанена өч һәм дүрт палубалы круиз пароходлары туктый башлады. Бу сөенечле хәл зур, минемчә, республика туристлык тармагының киләчәге өчен бик мөһим башка вакыйга белән бергә туры килде. Беренче чиратта, «Яңарыш» фондының системалы, җентекле эш алып баруы бәрабәренә, Свияжскидагы Успение монастыре ЮНЕСКО объекты статусы алды.

3

– «Бөек Идел юлы» проектын базарда алдынгылар рәтенә чыгару. Ләкин чынлыкта андый максат куелмады да: бу проект көз көне «пилот» режимдарак эшләтеп җибәрелгән иде. Әлеге проект Иделнең урта агымындагы төбәкләр аша өч-дүрт көнлек маршрутлардан гыйбарәт. Шуларның теләсә кайсын сайлап, турист бер сәфәрдә берничә шәһәрдә булып чыгу, төрле милләтләрнең гореф-гадәтләре белән танышу, төрледән-төрле табигый объектларны күрү мөмкинлеге ала. 2017 елда без, кешеләргә мөмкин кадәр уңайлырак һәм кызыграк булсын өчен, нәрсәләрне яхшыртырга, эшкәртергә кирәк икәнен карадык. 2018 елга планда – проектны актив сатыла торган брендка әйләндерергә, тагын да баетып, аңа тәмам камилләшкән рәвеш бирергә. Россия һәм чит ил туристларында бу бренд хакында Мәскәү, Санкт-Петербург, «Алтын боҗра» кебек үк мөстәкыйль туристлык дестинациясе буларак күзаллау барлыкка килсен. Халыкара туристлык базарында исә «Идел юлы» Россия картасындагы мөстәкыйль туристлык продукты рәвешендә каралсын. Моның өчен безгә республика кунакларының Татарстанда 3 түгел, ә ким дигәндә, 4–5 көнгә калуын максат итеп эшләргә кирәк. Ягъни күптән һәм яхшы билгеле туристлык объектлары булган төбәкләр белән бер үк мәсьәләләрне хәл итү сорала.

4

– Без туристлар санын арттыруны дәвам итәчәкбез. Актив үсештәге Европа дәүләтләре һәм шәһәрләре үрнәгендә – ким дигәндә, 7%ка. Бу безнең иң беренчел бурычыбыз. Монда төп мәсьәлә әчке турист өчен дә, читтән килә торганы өчен дә һәрвакыт үсештә булган көндәшлектә өстен чыгудан гыйбарәт. Туристлык продуктлары арасында көн саен ниндидер яңа тәкъдимнәр пәйда була, һәм без потенциаль аудиториясе булган коммуникацияләрнең, ширкәтләрнең кызыксыну өлкәсендә калырга омтылабыз. Бу исә Татарстанга Россиядәге иң популяр туристлык юнәлешләренең беренче өчлегендә тотрыклы рәвештә урын алырга, дөньяда танылырга булышлык күрсәтә. 2018 елда футбол буенча дөнья чемпионаты матчлары ярдәме белән без бу яктан бик зур өстенлеккә ия булачакбыз. Уеннар дөньяның бөтен илләрендә күрсәтеләчәк, тамашачылар саны миллиардлар белән хисапланачак. Күз алдына китереп карагыз әле, «Казан» сүзе эфирда ничә тапкыр яңгыраячак. Бездәге гореф-гадәтләр, истәлекле урыннар турында бәян иткән, «мохиткә чумып» әзерләнгән күпсанлы репортажлар күтәчәгенә ышанам. Бу – туристлар өчен искиткеч зур реклама булачак, һәм максат итеп куйган базарларыбызда сөйләшүләрне нәтиҗәлерәк алып барырга булышачак. «Без һәр буын өчен ачык!»

Фото: Ната Смирнова

PRESSA.RU

БЕЗНЕҢ ЭРА ҖИТӘКЧЕСЕ

2018 елда РФ дәүләт хакимияте органнарында проектлы идарә инструментларын кертә башлаячаклар. Татарстанда моңа әзерлек эшләре алдан ук алып барылды инде. Республиканың Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы пилот мәйданчыгына әйләнде, аның хезмәткәрләре Казан федераль университетындагы Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбендә «Оешмадагы проектлар һәм процесслар белән нәтиҗәле идарә итү» программасы буенча укытылды.

Автор:
Ксения Сёмина

Федераль йөкләмәләр белән тигезлекне саклап бара алу мәктәпнең, мәгариф тармагындагы дөньякүләм тенденцияләргә йөз тотып, кайчагында аларны алданрак та ачыклап, заманнан алгарак китеп эшләвен күрсәтә. «Алиса в Зазеркалье» әсәреннән яхшы таныш булган «урында тору өчен генә бар куәткә йөгерергә кирәк, ә каядыр барып җиту өчен кимендә ике тапкыр тизрәк йөгерү зарур» дигән гыйбарә бирєдә яшерен шигарьгә әйләнгәндер кебек тоела. Әлеге белем узышын даими тизләтү нигә кирәк соң?

ҮЗГӘР, ЙӘ КИТ

Әле 2009 елда ук Microsoft, Cisco һәм Intel компанияләре хәзерге белем бирү системалары икътисадый трендлардан артта кала һәм укучыларга уңышка ирешү өчен кирәкле, шул исәптән бизнеста һәм җәмгыятьтә мәгълүмати технологияләрнең роле үзгәрүгә яраклашырлык белем бирми, дигән нәтиҗәгә килгән. Әлеге корпорацияләрнең инициативасы белән Мельбурн университеты профессоры Патрик Гриффин бик зур халыкара Assessment and Teaching of 21st Century Skills (ATC 21S, XXI гасыр күнекмәләренә өйрәтү һәм бәяләү) гыйльми проектына нигез салган. ATC 21S буенча эш дәвам итә: бүген проектта теге яки бу дәрәҗәдә дөньяның егермеләп иле катнаша. XXI гасыр күнекмәләре концепциясе нигезенә салынган идеяләр бүгенге көн чынбарлыгында оператив үзгәртеп кору ресурсларына ия мәгариф структураларында гамәлгә дә кертелә инде.

– Проектлы идарә – инструмент ул, аннан файдалану корпоратив һәм җитештерү менеджменты кысаларыннан әкренләп чыга бара. Бүген бу – фикерләү стиле, дип әйтеп була. Аңа ия булган кеше, нинди вазыйфа биләвенә һәм нинди белем алуына карамастан, теләсә кайсы бурычны нәтиҗәле хәл итәргә сәләтле, – ди Казан федераль университеты Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе директоры Игорь Привалов.

Проектлы идарә итү методикасы Россия төбәк дәүләт структураларында бүген аеруча зарур, чөнки аларның җитәкчеләре масштаблы бурычларны кадрлар, вакыт һәм финанс ресурслары минимумы белән хәл итәргә мәҗбүр.

Былтыр октябрьдә мәктәптә ТР Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы хезмәткәрләре өчен үткәрелгән «Оешмадагы проектлар һәм процесслар белән нәтиҗәле идарә итү» программасы кысаларында берьюлы ике бурыч хәл ителгән: дәүләт хезмәткәрләрен проектлы идарә нигезләре белән таныштыру һәм нәтиҗәле команда төзү. Курсны тыңла-

Реклама

учылар әйтүенчә, уку аларны һөнәри аралашуда зирәгрәк һәм уңышлырак булырга, коллектив эчендәге коммуникацияләрне яхшыртырга, үзара хезмәттәшлектә тиз нәтиҗәгә ирешү өчен кире элемтәдән файдаланырга өйрәткән.

– Республика дәүләт структуралары өчен проектлы идарә – эшнең өр-яңа ысулы. Аннан файдаланудан Татарстан масштабында нәтиҗәгә ирешер өчен барлык министрлык һәм ведомстволар да үз эшен шуңа нигезләргә тиеш, – ди Игорь Привалов. – Шулчакта гына без синергия эффектын күрәчәкбез. Башка идарәләр дә ТР Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының уңай тәҗрибәсеннән үрнәк алыр, дип өметләнәбез. Әлеге программаны камилләштерү максатларында ул безнең өчен дә файдалы булды.

КҮБРӘК АРАЛАШЫРГА КИРӘК

Мәктәп республиканың зур эш стажлы чиновниклары өчен оештырыла торган «Нәтиҗәле идарәче» курсы дәресләренең берсендә тыңлаучылар үзләрен бер предприятиедәге бүлек җитәкчеләре итеп күзалларга һәм яңа офистагы кабинетларны үзара бүлешергә тиеш. Шартларның хыялда гына булуын тиз арада онытып, тренингта катнашучылар кайнар бәхәскә һәм ялыктыргыч сөйләшүләргә чума. Үз мәнфәгатьләрен кайгыртуның гомуми нәтиҗәлелекне никадәр киметүенә төшенгәч кенә, төркем бердәм карарга килә.

Аралашучанлык, фикердәшләр табу һәм үз командаңдагы кешеләрнең көчле якларын ачыклау сәләте – киләчәк идарәчесенең төп күнекмәләреннән берсе.

– Бүген дөньяда һөнәрмәндләргә искиткеч югары таләпләр куела. Күз алдына китерегез: АКШта суд дәгъвасын адвокатсыз, интернет мәгълүматларын гына файдаланып, мөстәкыйль алып барырга теләүче кешеләр саны 80 процентка җиткән. Америкадагы тагын бер тренд мондый: якын киләчәктә роботларның җитештерүдәге арзанлы эшче көчләрне алыштыру ихтималы 80 процентны тәшкил итә, кешеләрне роботларга алыштырырга теләмәгән яки алыштыра алмаган компанияләр исә базардан китәргә мәҗбүр булачак. Болар барысы да – санлы дәвер шаукымы. Индустриаль эрада кешегә, көндәшлеккә сәләтле булыр өчен, үз профилендә белем туплау җитә. Хәзер исә бу үзгәрде, – ди Игорь Привалов. – Белгечләр фикеренчә, бүген бизнестагы яки идарәдәге кадрлар өчен төп өстенлекләр – креатив фикерләү, үзара мөнәсәбәтләрне җайлау һәм, боларның барысын да файдаланып, максатка аеруча нәтиҗәле һәм кыска юллар табу осталыгы ул. Хезмәт базарында мондый белгечләр алтын бәясенә тора. Бу – сирәк очрый торган «товар», чөнки бөтен дөньядагы мәгариф системаларында элеккечә үк укучының белем күләмен бәяләү хакимлек итә, ә менә үзләштерелгәнне практикада куллану осталыгы исәпкә алынмый.

Гриффин тәкъдим иткән концепцияне кертү дөньяның төрле илләрендәге мәгариф системасының төрле баскычларында гамәлгә ашырыла. Мәсәлән, Таиланд университеты XXI гасыр күнекмәләрен бизнес факультеты тыңлаучыларына өйрәтү планын эшли. Финляндиядәге Ювяскюля университеты аның буенча укытучыларны укыту программасын әзерли, Мельбурн университетында педагогик белем бирү һәм имтихан нәтиҗәләрен бәяләү критерийлары заманчалаштырыла. Биредә имтихан бирү формасы да үзгәрәчәк: басым белем күләменә түгел, студентның куелган бурычны башка студентлар белән берлектә һәм интернеттан файдаланып хәл итүенә ясалачак. Тест үтүчегә билге аның әлеге бурычны хәл итү процессындагы бөтен гамәлләрен, ягъни аралашу, критик фикерләү күнекмәләрен, иҗади сәләтләрен һ.б. исәпкә алып куелачак.

– Соңгы елларда без программаларыбызны тамырдан үзгәрттек, аларны мөмкин булганча интенсив һәм интерактив ясадык. Материал тренинглар һәм кейслар чишү аша өйрәнелә. Без онлайн-укытудан да актив файдаланабыз, – ди Игорь Привалов. – Татарстан җитәкчелеге кертикән традицияләрне саклап, мәктәп барлык дөньякүләм тенденцияләрдән хәбәрдар булу, аеруча перспектив технологияләрне тиз арада куллану өчен барысын да эшли. Республиканың уңышлары, чит ил партнерларының аның белән кызыксынуы арту биредә «XXI гасыр күнекмәләренә» ия һөнәрмәндләрнең булуы турында сөйли. Әмма алар көннән-көн күбрәк таләп ителә.

PRESSA.RU



Ирек Миңнәхмәтов, «Ел җитәкчесе» номинациясендә җиңүче.



Владимир Ткачев, «Ел спортчысы» номинациясендә җиңүче.



2017 ЕЛ ЛАУРЕАТЛАРЫ

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ВЕРСИЯСЕ

2017 елда безне нинди шәхесләр илһамландырды һәм сокландырды? Нинди компанияләр, вакыйгалар һәм акцияләр сөендерде, гаҗәпләндерде һәм оптимизм тудырды? «Татарстан» журналы, әлеге сорауларга җавап бирүне һәм узган ел лауреатларын ачыклауны сорап, традиция буларак, иң абруйлы һәм принципиаль экспертларга – укучыларыбызга мөрәҗәгать итте.

Искә төшереп узабыз, редакция укучыларга 25 номинациядә лауреатлыкка лаеклылар өчен тавыш бирергә тәкъдим иткән иде (protatarstan сайтында яисә телефоннан). «Татарстан» версиясе буенча номинациядә җиңү һәм, димәк, лауреат булу өчен кандидатларга көндәшләре белән чагыштырганда иң күп тавыш җыярга кирәк иде. Алдан ук әйтеп куябыз: сорашу нәтиҗәләре мәртәбә, янә бер кабат укучыларыбыз фикерләренең ни дәрәҗәдә объектив булуын күрсәтте. Тавыш бирүчеләрнең күпчелеге өстенлек биргән номинантлар арасында бер генә «буш кеше» дә юк. «Татарстан» версиясе буенча 2017 ел лауреатлары – лаеклылардан лаеклылар. Хәер, менә үзегез бәяләгез.

«Ел җитәкчесе» дигән иң мактаулы номинациядә җиңүче – «Татспиртпром» АҖ генераль директоры Ирек Миңнәхмәтов. Укучылар арасындагы сорашуда катнашканнарның 44 проценты аңа тавыш биргән. Бу номинациядәге ел лауреатына – 30 процент тавыш җыйган «Татнефть» ГАҖ генераль директоры Наил Маганов һәм «Алабуга» МИЗ җитәкчесе Тимур Шаһиволиев (26 процент) кебек көндәшләр булуын да искә алсак, бу искиткеч нәтиҗә.

«Татарстан» журналы версиясе буенча «Ел спортчысы» исемен «Ак барс» форварды Владимир Ткачёв алды. Бу популяр номинациядә җиңү өчен көрәш шулай ук кызу хоккей баталияләренә яки хәлиткеч волейбол партияләренә тиңдәш иде. Дөресен әйтик: «барслар» һөҗүмчесенең башта ук үзенең көндәшләре – «Зенит» волейболчысы Максим Михайлов һәм кыска суда йөзү буенча дөнья чемпионы Александр Красных белән чагыштырганда күпмедер өстенлеге сизелә иде. Ни дисәң дә, Татарстанда һәм, гомумән, илдә, спортның башка төрләренә караганда, хоккей җанатарлары күбрәк бит. Хәер, Максим Михайлов белән Александр Красныхның ахыр чиктә лидерның 44 процент тавышын яулап алуга ирешүе шуны белдерә: тагын берничә зур җиңү – һәм аларның көндәшлектә өстенлеккә ирешүе дә ихтимал.

«Ел вузы» номинациясендә җиңүне сорашу нәтиҗәләре буенча зур өстенлек белән КМТТУ-КАИ яулады. Техник университетны үз номинациясендә беренче юлга чыгару өчен 1573 кеше, ягъни сорашуда каташканнарның 69 проценты тавыш бирде. Чагыштыру өчен: КФУны 430 кеше (19 процент), КДЭУны 271 кеше (12 процент) яклады.

«Елның социаль проекты» дип ТУ-144 самолёты интерактив музеен булдыру проекты табылды, шунысын да искә төшерик: аңа КМТТУ-КАИның шулай ук турыдан-туры катнашы бар. Бу номинациядәге җиңүче дә (тавышларның 77 проценты) һичкемдә шик уята алмый – лайнерны булачак тукталышына күчерү буенча уникаль операцияне бөтен республика күзәтте диярлек. Ә вузның ел ахырында интерактив музей булдыру өчен 8,9 миллион сум күләмендә президент грантын отуы – идеянең әһәмиятен исбатлау буенча иң яхшы чара, хәзер аны оператив рәвештә тормышка ашырасы гына кала. Бу номинациядә икенче урында – Аккош күлен яңарту проекты (тавышларның 14 проценты).

«Елның спорт вакыйгасы». Бу номинациядәге җиңүче тавыш бирүнең иң соңгы атнасында гына ачыкланды – аңа кадәр беренче юлны узган җәйдә Казанда булып узган бердәй тантаналы һәм киң күләмле ике вакыйга: футбол буенча Конфедерацияләр кубогы һәм Red Bull Air Race узышлары (авиацион Формула-1) биләде. Сораштыру нәтиҗәләре буенча «Елның спорт вакыйгасы» дип Конфедерацияләр кубогы табылды, аңа сорашуда катнашучыларның 48 проценты тавыш бирде. Red Bull Air Race аз гына кимрәк – 38 процент тавыш җыйды.

«Елның мәдәни вакыйгасы» номинациясендә сораштыруда катнашучыларның күбесе Свияжскидагы Успение соборы һәм монастыреның ЮНЕСКО Исемлегенә кертелүен беренче урынга куйды. Бу әһәмиятле генә түгел, күптән көтелгән вакыйга да иде. Тавыш бирүләрнең нәтиҗәсе дә шуны раслады: катнашучыларның 63 проценты аны «Елның мәдәни вакыйгасы» дип атады. Номинациядәге икенче урын – «Гасыр даһие» күргәзмәсе ачылу (тавышларның 23 проценты).

Җиңүчеләрне котлыйбыз!

2017 ЕЛ ЛАУРЕАТЛАРЫ

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ВЕРСИЯСЕ

ЕЛ ВАКЫЙГАСЫ

1. **Модернизацияләнгән беренче ТУ-160 М2 очкычын төзү (83%)**
2. Бөтендөнья татар конгрессы (8%)
3. Ислам академиясен ачу (8%)

ЕЛНЫҢ СПОРТ ВАКЫЙГАСЫ

1. **Конфедерацияләр кубогы (48%)**
2. Red Bull Air Race узышлары (38%)
3. «Зенит» волейболчыларының Чемпионнар лигасында җиңүе (14%)

ЕЛНЫҢ ЭКОЛОГИК ПРОЕКТЫ

1. **Казан Водоканалының чистарту корылмаларын реконструкцияли башлау (60%)**
2. Чүп яндыру заводы проекты (23%)
3. Түбән Кама Нефтехимның (1нче чираты) биологик чистарту корылмаларын реконструкцияләү (17%)

ЕЛ СОЦИАЛЬ ПРОЕКТЫ

1. **ТУ-144 самолётында интерактив музей ачу проекты (77%)**
2. Аккош күлен яңарту (14%)
3. Кабан күле яр буе проекты (9%)

ЕЛ МӘДӘНИ ВАКЫЙГАСЫ

1. **Свияжскида Успение соборы һәм монастыреның ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелүе (63%)**
2. «Гасыр даһие» күргәзмәсе ачылу (23%)
3. Мөселман киносы фестивале үткәрү (14%)

ЕЛ ҖИТӘКЧЕСЕ

1. **Ирек Миңнәхмәтов (44%)**
2. Наил Маганов (30%)
3. Тимур Шаһивәлиев (26%)

ЕЛ СПОРТЧЫСЫ

1. **Владимир Ткачёв (56%)**
2. Максим Михайлов (28%)
3. Александр Красных (16%)

ЕЛ КОТТЕДЖ БИСТӘСЕ

1. **«Мёшинские усадьбы» (49%)**
2. «Загородный клуб» (33%)
3. «Умырзая» (18%)

ЕЛ БАНКЫ

1. **Саклык банкы (76%)**
2. Ак Барс Банк (18%)
3. Газпромбанк (6%)

ЕЛ ЮВЕЛИР КОМПАНИЯСЕ

1. **«Алмаз-Холдинг» (58%)**
2. «Якут бриллиантлары» (27%)
3. «Эксклюзив» (15%)

ЕЛ РЕСТОРАНЫ

4. **«Трофей» (40%)**
5. «Туган Авылым» (38%)
6. Татар ашлары йорты (22%)

ЕЛ САНАТОРИЕ

1. **«Бәкер» (51%)**
2. «Васильево» (37%)
3. «Азнакай» (12%)

АВИАКОМПАНИЯ ГОДА

4. **«Аэрофлот» (73%)**
5. «Төрек авиалинияләре» (18%)
6. «ЮВТ Аэро» (9%)



2017 ЕЛ ЛАУРЕАТЛАРЫ

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ВЕРСИЯСЕ

ЕЛ МЕДИЦИНА ҮЗӘГЕ

1. «Биомед» (55%)

2. «Нуриевлар клиникасы» (33%)

3. «Медел» (13%)

ЕЛ ТӨЗЕЛЕШ ОЕШМАСЫ

1. «Унистрой» (77%)

2. «Камастройинвест» (13%)

3. «Суварстроит» (11%)

ЕЛ ИПОТЕКАСЫ

1. Саклык банкы (71%)

2. Ак Барс Банк (21%)

3. Урал реконструкция һәм үсеш банкы (8%)

ЕЛ БУТИГЫ

4. «Елена Фурс» (48%)

5. «Вятка мех компаниясе» (33%)

6. «Мехаполис» (20%)

ЕЛНЫҢ ДӘҮЛӘТНЕКЕ БУЛМАГАН ПЕНСИЯ ФОНДЫ

7. Дәүләтнеке булмаган милли пенсия фонды (56%)

8. «Будущее» ДБПФ (31%)

9. Промагрофонд (13%)

ЕЛ ИМИНИЯТ КОМПАНИЯСЕ

10. «НАСКО» (43%)

11. «Ингосстрах» (40%)

12. «Талисман» (17%)

ЕЛ СӘҮДӘ ҮЗӘГЕ

13. «Мега» (58%)

14. «Тандем» (23%)

15. «Южный» (18%)

ЕЛ ФИТНЕС-КЛУБЫ

16. «Планета фитнес» (47%)

17. «Максимус» (43%)

18. «Ак Барс Икс-фит» (12%)

ЕЛ КҮЧЕМСЕЗ МИЛЕК АГЕНТЛЫГЫ

19. «Флэт» (61%)

20. «Этажи» (22%)

21. «Мегалит» (17%)

ЕЛ АВТОСАЛОНЫ

22. «ТрансТехСервис» (71%)

23. «КАН Авто» (26%)

24. «Парус» (4%)

ЕЛ КУНАКХАНӘСЕ

25. «Ривьера» (79%)

26. «Мираж» (11%)

27. «Сөләйман Палас» (10%)

ЕЛ ВУЗЫ

28. КМТТУ-КАИ (69%)

29. КФУ (19%)

30. КДЭУ (12%)

Җиңүчеләрне котлыйбыз!



PRESSA.RU

facebook.com/protatarstan

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

twitter.com/protatarstan

instagram.com/protatarstan

БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ
РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

Реклама 16+

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Бәрәңге тәкәсен **НИЧЕК** пешерергә

Озак яшәү сере **НИДӘ**

Чемпионнар **КАЙДА** яши

PRESSA.RU

ИТЛЕ БӘРӘҢГЕ ТӘКӘСЕ: ТАГЫН БЕР МИЛЛИ РИЗЫК

«Безнең Зәй якларында итле бәрәңге тәкәсе пешерәләр. Казанда аны әзерләмиләр. Татар халык ашы санала ул. Бик тәмле, ә иң мөһиме файдалы ризык. Әйдә, килегез, пешереп күрсәтәм», – дип шалтыратты Ләйлә апа Нуруллина.

Бәрәңге тәкәсен авыз иткән бар иде. Ә менә ит, укроп салганын ашау түгел, ишеткән дә юк. Пешеп чыккач та эше бетми, кисеп, майлыйсы бар икән. Кыскасы, итле бәрәңге тәкәсе дигәннәре бик үзенчәлекле, тәмле ризык булып чыкты.

Автор:
Руфия Фазылова

«БӨТЕН ХИКМӘТ – УКРОП ОРЛЫГЫНДА»

Ләйлә Нуруллина лаеклы ялда. Өч бүлмәле фатирына килеп кергәч тә, мондагы пөхтәлеккә игътибар иттем. Хуҗабикә үзе дә зәвык белән киенгән. «Чүлмәк тышыннан күренә шул», – дип уйлап куйдым.

– Сез килә дип ашыга-ашыга бассейннан кайттым әле, – диде Ләйлә апа.

– Бассейнга йөрисезме? – дим.

– Әйе, пенсиягә чыккач, үземне кайгыртырга булдым. Фитнеска да барам, саунага да керәм. Аннан хәзер дөрес ашауга игътибар итә башладым: тозлы ризыклар, майлы ит, кыздырылган әйберләрдән дә баш тарттым. Алар берсе дә файдалы түгел.

– Ашауга мондый мөнәсәбәт, фәлсәфә кайдан килде?

– Дөрес туклануны алга сөрүче кешеләр белән таныштым, дуслаштым. Китаплар укыйм. Миңа 55 яшь тулды дип, һич кенә дә үзеңә кул селтәргә ярамый. Пенсия ул өйдә телевизор карап утыру өчен бирелми. Үзең өчен яшәргә бер дигән форсат!

Ләйлә апа шулкадәр кызыклы әңгәмәдәш, хәтта бер мәл биргә ни өчен килүемне дә онытып җибәргәнмен.

– Итле бәрәңге тәкәсе сәламәтлек өчен файдалы, шуңа да аны пешерәм, – дип сүзен дәвам итә Ләйлә апа. – Чаллы, Зәй районнарында әлеге ризыкны пешерә белмәүче кеше юктыр. Мин Чаллы районының (хәзерге Тукай районы – авт.) Иштирәк авылында туып-үстем. Әтием, рус теле укытучысы, күп еллар мәктәп директоры булып эшләде, әнием татар теле укытты. Елларда итле бәрәңге тәкәсе пешерү гаиләдә үзенә күрә бер традиция иде.

Ләйлә Нуруллина бүген дә әлеге ризыкны әнисе рецепты буенча ясый икән. Аерма бары шунда гына:

ЛӘЙЛӘ НУРУЛЛИНАДАН ИТЛЕ ТӘКӘ РЕЦЕПТЫ:

Камыр:
1. Йомырка – 1 данә
2. Сыек май – 150 г
3. Сөт – стакан ярым
4. Су – стакан ярым
5. Он – дүрт стакан
6. Тоз – чама белән

Эчлек:
1. Суган – 2 баш
2. Сыер ите (майсыз) – 800 г
3. Бәрәңге – 1 кг
4. Укроп орлыгы – 100 г
5. Борыч – чама белән
6. Тоз – чама белән

Фото: Лилиана Вәлитова

PRESSA.RU

Редакция кухнясы

әнисе майлы сыер ите кулланган, Ләйлә апа майсыздан пешерә.

– Итле бәрәңге тәкәсенең төп файдасы – укроп орлыгында. Аның сәламәтлеккә файдасы турында бик күп сөйләргә була. Китапларда укроп орлыгын заманында фиргавеннәрне дәвалау өчен кулланганнар дип язылган. Укроп – көчле антиоксидант. Составында аскорбин кислотасы һәм кверцетин булганлыктан ул организмнан агулы матдәләрне чыгарырга булыша. Шулай ук ашказаны-эчәк трактының эшчәнлеген яхшырта. Юкка гына яңа туган балаларга эче авырткanда укроп чәен эчерергә киңәш итмиләр. Имезүче хатын-кызларга укроп орлыгын төнәтеп эчәргә кушалар. Тагын укроп кан басымын төшерә. Моны үземдә, якыннарымда әллә ничә кат сынаганым булды. Ул яшьлек үләне булып та санала. Тән тиресен яхшырта, аның төсен матурлата.

«РИЗЫК УЛ – ҖАНЛЫ, БАРЫСЫН ДА ТОЯ»

Ләйлә апа, әңгәмәдән бүленмичә генә, итле бәрәңге тәкәсе өчен эчлек әзерләргә керешә. Башта вак итеп ит, аннан бәрәңгене шакмаклап турады, суганны ваклады.

– Эчлек әзер, – диде әңгәмәдәшем. – Укроп орлыгы, тоз, борыч өстибез дә... Хәзер ризыкка күп тоз салмый башладым, борычны да аз гына кулланам. Әлбәттә, күпләр итле ризыкларны майлы, тозлы-борычлы итеп ашарга ярата. Тик бу бер гадәт кенә, начар гадәт дияр идем. Ни өчен алга киткән илләрдә картлар үз яшьләреннән күпкә яшь күренә? Бөтен сере – дөрес туклануда. Ә без: «Барыбер үләсе», – дибез, яки «Әрәм калмасын инде», – дип теләсә нәрсә ашыйбыз. Соң бу үз-үзеңне аңлы рәвештә чиргә сабыштыру бит! Аннан пенсия яшендә көчкә йөри башлыйбыз.

– Ә сез ничек туклanасыз? – дим.

– Иртән ботка, төшке ашка майсыз шулпа, кичке ашка җиңелчә ризык пешерәм. Һәм күп итеп яшелчә, җиләк-җимеш ашыйм. Һәр ризыкка яшел тәмләткечләр салам, витаминлы булсын, дим.

Ләйлә апа камыр ясарга алынды. Башта йомырканы туглады, аннан аңа сөт белән су кушты. Барысын бергә бутагач, сыек май, тоз өстәде. Шуннан соң он кушып, камыр изә башлады.

– Камырга сода яки чүпрә салмыйсызмы? Каты булмыймы? – дип кызыксынам.

– Юк, кирәкми. Сыек май камырны йомшарта инде.

Эшләгәндә дә Ләйлә апаның йөзеннән елмаю китми, җылы бер нур бөркелә.

– Ризыкны яхшы кәеф белән пешерергә кирәк, – ди Ләйлә апа. – Ризык ул җанлы әйбер кебек, барысын да тоя.

Камырны шактый озак басты хуҗабикә. Аннан пычак белән кисәкләргә бүлеп чыкты.

– Бу ризыкны өчпочмакка охшатам, – дим Ләйлә апага. – Без дә шулай кайчакта төче камырга өчпочмак пешерәбез.

– Юк, алар икесе ике ризык, һич кенә дә бер-берсенә охшамаган, – ди хуҗабикә. – Хәтта ашау ысуллары да төрле.

Ләйлә апа зур булмаган түгәрәкләр җәйде. Һәм алдан әзерләп куйган эчлекне түгәрәкләргә салып чыкты. Аннан тәкәләрне матурлап бөрде.

– Камырга кулыгыз ята икән, еш пешерәсезме әллә? – дим.

– Әйе, пешерәм. Балалар, оныклар киләбез дисәләр, туңдыргычтан тиз генә итне алып куям. Мин егерме бер яшемдә кияүгә чыктым. Аңа чаклы бөтен төр камыр ризыкларын пешерә идем. Безнең якларда туйдан соң «Килен токмачы» дигән аш уздыралар. Менә шунда яшь килен үзенең осталыгын күрсәтә – токмач кисә. Ул вакыйга шулкадәр күңелгә кереп калды ки, һич онытылмый. «Килен токмачына» дип иремнең туганнары да җыелган иде. Белмим, хәзерге киленнәргә токмач кистерәләрме икән. Ә мин унбиш яшемдә бөтен әйберне диярлек әзерли идем. «Кызым, әнисе өйрәтмәгән, дип әйтерләр, барысына да өйрән, дия-дия әни мине гел аш бүлмәсенә дәшә иде. Токмач кисәргә дә, башкасын пешерергә дә әниемнән өйрәндем. Әни исә: «Син мине дә арттырып җибәрдең», – дия иде. Кыз үстергән ата-ананың бурычы – бирнә җыю, баласын ир хатыны булырга өйрәтү иде бит. Рәхмәт эти-әнигә, алар барысын да җиренә җиткереп үтәделәр. Авыр туфраклары җиңел булсын. Безнең өчен дип яшәделәр.

Ярты сәгать дигәндә, Ләйлә апа итле бәрәңге тәкәсен әзерләп, электр миченә куеп та җибәрде. «Күп дигәндә бер сәгатьтән пешә», – диде.

«ӘТИ ДӘ, ӘНИ ДӘ БУЛДЫМ»

Ризык пешергәндә генә түгел, тормышта да Ләйлә апа житез, кыю икән. Ирсез ике бала үстергән. Аларга югары белем, тәрбия биргән, тормышта үз юлларын табарга ярдәм иткән.

– Әтиләре була торып та әтисез үсте балалар, менә шунысы гына

Эчлек

1. Ваклыйбыз!

2. Турыйбыз!

3. Кушабыз!

4. Өстибез!

5. Бутыйбыз!

үкенечле, – дип, тормыш йомгагын сүтте Ләйлә апа. – Мин аларга әни дә булдым, әти дә... Тормышны алып барырга, балаларны үстерешергә үземнең әти-әнием ярдәм итеп торды.

Ләйлә апа балаларын иртән мәктәпкә, дәресләрдән соң түгәрәкләргә илтә, кичен бассейнга алып бара, йөзәргә өйрәтә. Барысын да күреп үссеннәр, дип, бозга, тимераякта йөрергә алып чыга. Бөтен максаты, теләге – улы белән кызы, тулы гаиләдә үскән балалардан ким-хур булмасын.

– Балаларымны белемле дә итәсем килде, – дип сөйли Ләйлә апа. – Өйгә глобус алып куйдым. Алар белән көн саен шундагы берәр илне карап өйрәнә идек. Ә аннан дөнья гизәргә мөмкинлек туды. Ике баламны алып Урта Азия шәһәрләре буйлап та, Европа илләре буйлап та сәяхәт иттек. Улым белән кызыма тагын бер таләбем бар иде – көн саен китап укырга. Әти белән әни миндә кечкенәдән китапка мәхәббәт уяттылар. Аллага шөкер, балаларыма да шуны бирә алдым. Укыган кеше тәрбияле, эчке дөньясы тирән була.

Ләйлә апаның: «Дөнья гизәргә мөмкинлек туды», – дигәне, үз эшен булдыруы. 2000нче елда Зәй шәһәрендә укыту үзәге ача ул. Бөтен оешмаларның да компьютер белән эшләргә күчкән чорына туры килә бу хәл. Күпләр әлеге техниканы ничек кабызасын, сүндерәсен дә белми. Ләйлә апа шушы форсатны кулыннан ычкындырмый!

– Мин шактый еллар Зәй машина төзелеше техникумында административ эшләр буенча директор урынбасары булып эшләдем, – ди Ләйлә Нуруллина. – Оештыру эшләрен яхшы беләм. Үзләренең бизнесы булганнарның тормышлары алга barганын күрәм бит. Минем дә күңелдә шундый хыял бар иде. Парикмахерлар курсы ачыйммы икән әллә, дип тә уйлаган идем. Карыйм: бөтен оешмага компьютерны белгән кешеләр кирәк була башлады. Ә алар юк. Шулай итеп, Зәйдә беренче булып укыту үзәге ачтым. Әлбәттә, барысын да рәсми эшләдем. Казанга барып, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгыннан укытырга рөхсәт бирүче махсус документ – лицензия алдык. Безнең үзәктә берничә төрле һөнәр үзләштереп була иде – ЭВМ операторлары, бухгалтер, сәркатип, парикмахер. Укыту үзәге шәһәрдә тиз арада популярлык казанды, андый уңышны үзем дә көтмәгән идем...

– Шулай булса да, эшегезне ташлап, Казанга килгәнсез икән, – дим.

– Әйе, балаларга якын булыйм, дидем. Әти-әнием вафат, анда бер нәрсә дә тотмый мине хәзер. Ә монда улым, кызым – янымда. Дөрес, аларның үз гаиләләре, аерым яшиләр. Тик безнең күрешмичә калган көнебез юк. Оныкларны үстерергә булышам. Хәзер аларны аякка бастырасы, белем, тәрбия бирәсе бар!

«МАЙЛАП АШАРГА КИРӘК!»

Ләйлә апа үзенең уңыш сере белән уртаклашкан арада, аш бүлмәсенә гаҗәеп тәмле хуш исле таралды.

– Өсте генә киләсе калган, – диде хуҗабикә, ризыкка күз салгач.

Һәм сыер маен утка эретергә куйды. Тәкәләрне электр миченнән алгач та, сыер мае белән майлыйсы була икән.

– Ләйлә апа, ә сезнең иң яраткан ризыгыгыз нинди? – дим.

– Кыстыбый. Әнкәем аны шулкадәр тәмле пешерә иде, искитмәле! Аз гына чирләп китсәм, әни кыстыбый пешереп бирә. Кеше ышанмаслык хәл: шуннан соң терелеп китә идем. Менә шуңа да кыстыбый – балачагымның якты бер хатирәсе, әнкәем белән бәйле бик кадерле истәлек...

Хуҗабикә тагын ит бәлешен дә бик оста пешерә, хәтта аңа кунакка килүчеләр алдан заказ биреп куя икән.

Ләйлә апа, бисмилласын әйтеп, тәкәләрне электр миченнән алды. Аннан кайнар ризыкны табадан тәлинкәгә алып, тастымал белән каплап куйды. Өч-биш минут шулай йомшарып алырга тиеш икән. Тәкәләр азрак суынгач, хуҗабикә аларны пычак белән урталайга бүлде. Шуннан эретелгән кайнар сыер мае белән ике ягын да майлады.

– Майламыйча, өчпочмак кебек кенә ашасаң ярамыймы? – дим Ләйлә апага.

– Юк, бөтен үзенчәлеге шунда. Сыер мае тәкәне йомшарта да, сусылландыра да. Аны фәкать майлап ашарга кирәк. Шулай дип яза күрегез...

Ләйлә апа тәкәләрне кыстыйкыстый ашатты. Уңганлыгы өстенә бик юмарт та ул. Ризыкның тәме ничек соң диярсез? Мин аны хәтта нәрсә белән чагыштырырга да белмим. Укроп орлыгы булгангадыр, ул бөтенләй өчпочмакны хәтерләтми. Гаҗәеп тәмле! Камыры да нәзек кенә. Кыскасы, елларда гаилә, туганнар белән җыелып ашау өчен бик тәмле ризык, дип таптым мин аны. Пешереп карагыз, үкенмәссез. Т

Камыр

1. Салабыз!

2. Сытабыз!

3. Басабыз!

4. Бүләбез!

5. Җәябез!

PRESSA.RU



КЕЧЕ ВАТАН ПАТРИОТЛАРЫ

ТУГАН ЯГЫ – КАРЛЫ БИШЕК

Автор:
Луиза Янсуар

Ул үзенең XX гасыр белән яшьтәш булуына горурлана иде, дип искә ала каләмдәшләре һәм чордашлары. Улы Зөфәр абый исә ни өчен озын гомерле булуының серенә төшенәсебез килсә, ул әйтеп калдырган сүзләрне искә алырга өнди: «Гомерем буена берәүдән дә көнләшмәдем, шуңа озак яшәдем». Юлыбыз Арчага – Гомәр Бәшировның «яшел бишеге»нә. Хәер, бу очракта «карлы бишеге»нә дисәк, дөресрәк булыр.

«БЕЗ СИНЕҢ БЕЛӘН ТУГАННАР – ОНЫТМА...»

Гомәр Бәшировның туган авылы Яңасала безне 30 градуска якын салкыннары белән каршы алды. Агачлар бәсле ябалдашларын көчкә күтәреп утыра, һавадан сыкы ява, кар җем-җем килә, шыгырдап тора. Арча Әдәбият һәм сәнгать музее директоры Шәфигулла Гарипов белән чатнама салкын кышкы һаваны ярып Яңасалага җилдергәндә, тирә-яктагы матурлыкка соклануымны яшерә алмадым. Ә Шәфигулла абый, үз чиратында, табигатьнең кодрәтенә ишарәләде:

– Киләсегезне белгәндәй, чын-чынлап кышкы көн белән каршылый безнең яклар үзегезне! Соңгы елларда кыш бик юаш бит, ә менә Гомәр абый, Гариф ага, Мөхәммәт абзыйлар үскәндә шушындый өтеп ала торган кышлар булган. Әле без үскәндә дә шулай иде...

Яңасала урта мәктәбендә безне тулы бер делегация көтеп тора булып чыкты: җирле үзидарә башлыгы Айрат Сафин, язучыны гомер-гомергә белгән авылдашлары Гөлсәрия Миңнебаева белән Оркыя Мөхәммәтҗанова, клуб мөдире Гөлназ Касыймова, китапханәче Фәридә Борһанова һәм укытучы Венера Сафина. Мәктәпнең Гомәр Бәшировка багышланган музей-бүлмәсенә уздык.

– Үзебезнекеләр генә түгел, ә Татарстанның башка районнарындагы мәктәпләрдән дә киләләр, – дип сөйләп китте Фәридә ханым музей турында. – Монда Гомәр ага үскән чордагы атмосфераны тудырырга тырыштык: йорт җиһазлары, көнкүреш әйберләре шул елларга карый. Аның турындагы чыганакларны, истәлекләрне тупладык, матбугатта басылган һәр язманы берәмтекләп җыябыз. Шәхси әйберләре бар, менә, бюсты тора... Киләчәктә интерактив музей итеп эшлисе килә, билгеле...

– Ә Гомәр Бәшировның кем икәнлеген мәктәп укучылары беләме соң? – дип төпченәм.

Сүзгә Венера ханым кушыла:

– Белмичә! Әлбәттә, беләләр! Якташ язучыларыбыз, дип, аларга кечкенәдән безнең төбәктә туып-үскән әдипләрне өйрәтәбез. Әсәрләрдән

Арча Әдәбият һәм сәнгать музее, Зөфәр Бәширов, Гәүһәр Хәсәнова архивларыннан

1

2

өзекләр ятлыйбыз, инсценировкалар әзерлибез. Гомәр Бәшировның туган як табигатен, үзенең балачагын яктырткан «Туган ягым – яшел бишек» әсәрен яратып укыйлар.

– Ә сезнең хәтердә нинди булып саклана Гомәр Бәширов? – дип кызыксынам.

Сүзгә Гомәр Бәшировның иң өлкән якташы Гөлсәрия Миңнебаева кушыла. 90 яшен тутырып килгән бу мөлаем да, кырыс та әбекәйнең әдәбиятны, шәхесләрне белеп сөйләве, мантыйгы, зиһене хәйран калдыра:

– Хәерниса апа исемле якын туганының йортына кайтып йөрде ул, безгә күрше генә иделәр. Кайтканда безгә дә керми калмый, әлбәттә. Бик тыйнак, гаҗәеп итагатьле,ипле кеше булды Гомәр ага. Шулай ук беркайчан да артыгын әйтми торган сак сүзле кеше булып истә калган. Заманы да шундый иде, профессиясе дә шуңа күнектергәндер – следователь булып эшләде бит. Аларга артыгын сөйләшү ярамаган да, килешмәгән дә. Мин үзем 5 ел китапханәдә эшләдем. Гомәр ага кайткан вакытта китапханәгә сугылмый калмый иде. Туган нигезе ләбаса...

– Гомәр аганың туып-үскән йорты урынында төзелгән иде безнең китапханә, хәзер дә тора, әмма аны яңартасы бар инде, – дип элдереп ала сүзне икенче якташы Оркыя Мөхәммәтҗанова. Ул нигезне узышлый безгә Шәфигулла абый күрсәтеп киткән иде. – Китапханә авыл халкына күп еллар хезмәт итте. Гомәр ага үзе дә анда очрашуларга кайта иде, бик күп китаплар бүләк итте...

– Туган ягын бик яратты Гомәр ага, кайткан чакта басу-кырларны, урманнарны әйләнми калмый иде, – дип янә сүзгә кушылды Гөлсәрия Миңнебаева. – Чүнниккә менә, авылдашлары белән күрешеп гәпләшә, чишмә буйларына төшә. «Без үскән чактагы кебек тора һаман да» дип нәрсәләргәдер сөенә, нәрсәнедер тапмаса, үзгәрешләр барын күрсә, сораша, кайчак моңаебрак та кала... Бидә елгасының бер ягыннан чыгып китә иде тирә-якларны урап кайтыр өчен, икенче ягыннан кайтып керә... Олыгая төшкәч, улы Зөфәр абый белән кайтып йөрде. Зөфәр абый Гомәр аганың үзен дә, авыл табигатен, кешеләрен дә бик күп итеп карточкага төшерде... Бер сәяхәтне һич онытасым юк. Елга буйлап барганда, Гомәр ага, кинәт тукталып: «Гөлсәрия, без бит синең белән бабаң ягыннан туганнар», – диде. Аннан өстәде: «Мин мулла нәселеннән булгач, артык төпкә кереп китеп, бу хакта сөйләп тормыйм, әмма онытма безнең туган икәнне». Аралашуда ягымлы иде Гомәр ага, беркайчан да кемгәдер каты бәрелгәнен хәтерләмим. Балалар белән – балаларча, олылар белән олыларча сөйләшә белде.

3

1. Арча Әдәбият һәм сәнгать музее директоры Шәфигулла Гарипов – музейның Гомәр Бәшировка багышланган почмагында.

2. Сулдан уңга: Гомәр Бәшировның авылдашлары – Гөлсәрия Миңнебаева, Оркыя Мөхәммәтҗанова; клуб мөдире Гөлназ Касыймова, китапханәче Фәридә Борһанова, Яңасала җирле үзидарә башлыгы Айрат Сафин.

3. Гомәр Бәширов Яңасалада әтисенең йорт нигезе урынында. Аның артында төзелеп килүче китапханә бинасы. 16 июнь, 1982 ел.

1

1. Гомәр Бәшировның Яңасала мәктәбе музеенда саклана торган шәхси әйберләре һәм бюсты.

2. Яңасала авылы чишмәсе янында. Уңнан беренче – Гомәр Бәшировның туганы Хәерниса. 30 июнь, 1968 ел.

ӘДӘБИ МИФ, ЯКИ ҖИДЕГӘН ЧИШМӘНЕҢ СЕРЕ

Әңгәмәбез җыр-шигырь белән үрелеп барды. Оркыя Мөхәммәтҗанова Гомәр Бәшировка багышлап язган шигырьләрен укыды, Айрат әфәнде гармунын тартып җибәреп, клуб мөдире Гөлназ ханым «Җидегән чишмә»не сузды, без исә кушылып җырладык. Җыр тәмамланугa, Гөлсәрия апа, җитдиләнеп китеп, әдәби дискуссиягә күчте:

– Сеңлем, син үзең дә яза торган кеше булгач, яхшы аңлыйсыңдыр: Гомәр ага бит ул – гаҗәеп олпат шәхес. Аны кайта-кайта укыйсың, барыбер бөтен катламнарын ачып бетереп булмый.

– Ә хәзерге язучылар алай түгелме? – дип елмаям.

Гөлсәрия апа да елмая, әмма елмаюында моңсу чаткылар чагылып китә:

– Хәзергеләр, балам, никтер ашыга-кабалана, шуңа да сай йөзәләр, өстән каймагын гына сөзеп алмакчы булалар. Эчтәге, тирәндәге агымга төшеп җитә алмыйлар... Ә Гомәрнең, Гарифның, Мәһдиевнең әсәрләрендә безнең тормышның нигезе ята, аларда бөтенесе дә озак еллар күзәтеп, озак вакытлар уйлап йөреп язылган... Без яшәгән тормышның төплелеге, чынлыгы ялтырап өстә түгел, тирән төпкелләрдән чишмә суы кебек яшерен тибеп ята иде...

Шушы урында сүзебез Җидегән чишмәгә әйләнеп кайта.

– Аның өеннән ерак түгел генә чишмә бар, без шул чишмәне мәктәп укучылары белән тазартып, аңа «Җидегән чишмә» исеме бирдек, – ди Оркыя апа. – Авыл халкы аны бик яратты, суы тәмле, сихәтле...

– Туктагыз әле! – дип гаҗәпләнәм. – Җидегән чишмә – Гомәр Бәшировның балачак чишмәсе түгелмени?! Димәк, ул әдәби миф, язучы уйдырмасы булып чыга инде?

– Юк, юк, һич уйдырма түгел! – дип кырт кисә Гөлсәрия апа. – Чынлап та бар ул чишмә!

Бу урында алар, дәррәү кубып, кайсы чишмәнең Җидегән чишмәгә прототип булуы хакында бәхәсләшә башлыйлар: борынгы Кабак тавы чишмәсеме, әллә Ат чишмәсеме? Ахыр чиктә, Яңасаланың иң өлкән вәкилләреннән булган Гөлсәрия апа версиясе җиңеп чыга: Кабак тавы чишмәсе, дигән фикергә килә авылдашлар.

– Ат чишмәсен минем Мостафа бабам төзекләндерде, ул чишмә бөтен фермага берәү иде, – дип сөйләп китте Гөлсәрия апа. – Анда алты улак куйдылар, атлар кинәнеп, ләззәтләнеп су эчә иделәр, бахырлар. Хәзергедәй хәтеремдә: сугыштан исән-имин килеш бердәнбер бахбай кайтты – Буденный. Кайткач та, туган чишмәсе суын эчеп туя алмады малкай... Ә менә Гомәр ага кечкенәдән суын эчеп үскән, әсәрендә сурәтләгән Кабак тавы чишмәсе бүген юк инде ул, балам, аның суы, кибеп, төпкә китте, юнәлешен үзгәртте ул...

– Мондый хәл еш булып тора, – дип сүзгә кушыла җирле үзидарә башлыгы Айрат әфәнде, – әмма төптә алар барысы да бер чыганакка барып тоташалар. Билгеле бер вакыттан соң чишмә яңа урында бәреп чыга.

Шәфигулла абый да куәтли бу сүзне:

– Менә шуңа да Гомәр ага үзенең әдәби чишмәсен «Җидегән» дип символик исем белән атаган да инде. Авылының чишмәләрен бер чишмәгә җыйган...

Шулай итеп, без, «татарстанлылар», Җидегән чишмә серенә дә төшендек, аның суын да татып карадык. Чынлап та бик тәмле! Бу яклардан узарга туры килсә, киңәш итәбез: Яңасалага сугылып, Җидегән чишмә суын татып карагыз.

2

PRESSA.RU



«Кичә «Җидегән чишмә»нең корректурасын, яңадан эшләп, нәшрияткә илтеп бирдем. Беренчесендә изгеләр чишмәсе һәм аның янына җыелучылар хакында, аларны куып җибәрүчеләр хакында сүз кузгатылган, берничә бит шуңа багышланган иде. Аны бирергә котлары очты. Корректураны Министрлар Советы янындагы дини культлар идарәсенәме, каядамы җибәрделәр. Анда исә «изгеләр чишмәсе һәм анда җыелучылар хакында язарга ярамый, алар хакында Үзәк Комитетның махсус карары бар, Бәшировның бу әсәре әнә шул карарга каршы килә», дигән язу җибәрделәр. Димәк, рәсми рәвештә миңа изгеләр чишмәсе дип әйтеп язарга рөхсәт итмәделәр. Ә минем әсәрдә мин ул изгеләр дигән нәрсә юк сүз, ул тирәдә бертөрле изгеләр дә булмаган, бу тирәдә терлек асраучылар яшәгән, халык ул чишмәләргә файдалы булган өчен генә изге дип исем кушкан, дигән фикерне раслый идем, чишмәләрне «изге» исеме тагылган өчен генә харап итәргә ярамый дигән нәтиҗә бирә идем. Рәсми рәвештә тыелганлыктан, башкача итеп үзгәртергә туры килде... Бер кызып киткәч, мин аны бөтенләй яңадан редакцияләп чыктым. «Җидегән чишмә» дигән җыр керттем».

Гомәр Бәшировнең көндәлегеннән, 8 февраль, 1977 ел.

«...Кайчан да булса яхшы әсәр булып танылачагына ышанып яшим. Бу китапта табигатькә мәхәббәт мәсьәләсе шактый киң итеп куелган. Анда табигатьнең хәзерге матурлыгы бирелгән. Бераздан ул табигый матурлык табигатьнең үзендә калмаячак, әсәрдә исә ул саклана. Бу әсәрдәге минем яраткан образларым – Гайнан, Минһаҗ, Җәүһәрия, Шәүрә, Язидә, Сәед – безнең әдәбияттагы бер образны да кабатламыйлар. Димәк, аларның әдәбиятта яшәми хәлләре юк».

Гомәр Бәширов көндәлегеннән, 1 октябрь, 1979 ел.

КЕМ УЛ ГАЙНАН, ЯКИ ӘСӘР КАҺАРМАННАРЫ КАЙДАН АЛЫНА?

Гомәр Бәширов һәрчак үзенең реалист язучы икәнлегенә басым ясый. Язучы, журналист Рафаэль Мостафин Гомәр Бәшировка багышланган хатирәләрендә аның үзен хәтта консерватив реалист дип ассызыклавы турында әйтә. «Консерватив», димәк ки, Галимҗан Ибраһимов, Фатих Әмирхан, рус әдипләреннән Лев Толстой, Иван Тургенев традицияләрен дәвам итүче, дигән сүз. Мостафин искә алганча, Гомәр Бәширов модернизм, постмодернизм кебек төшенчәләргә зур шик белән караган. Ул хәтта язучының мондый сүзләрен дә мисал итеп китерә: «Мине алардагы җилбәзәклек пошаманга сала, һәрчак нәрсәдәндер көлү, вакыты-вакыты белән хәтта мыскыллау, сүгенү. Авторитетларны танымау, ирония, скепсис – болары бөтенләй шаккатыра. Алар өчен изгелек белән хәшәрәтлек арасында аерма юк. Бу миңа үтә чит нәрсәләр...»

«Консерватив реалист» Бәширов романнарында әдәбият галимнәре аның замандашларын да, авылдашларын да таба.

– Ә сез үзегез, – дип кызыксынам җыелган авылдашларыннан, – Гомәр Бәшировның яңа әсәре басылып чыккач, аны укыганда үзегезне таный идегезме?

– Танымыйча, кызым! – дип, дәртләнеп сүзгә кушыла Гөлсәрия апа. – Гомәр ага бит ул геройларын бик оста итеп, җентекләп, детальләп сурәтли иде. Аның бер романында минем Мостафа бабай да бар, ничек инде мин аны танымыйм ди! Койган да куйган бабам инде менә, карточкадагы кебек...

– Кешеләрне романга керткәне өчен аңа ачуланган якташлары булмадымы соң?

– Юк, киресенчә, – дип елмая Оркыя апа, – горурлана идек. Гомәр ага бит ул урынсызга эшләми иде бер эшен дә. Аның әсәрләрендә яманлык, усаллык юк...

– Гомәр ага кешеләрне бик яхшы тоя торган иде, – ди Шәфигулла абый. – Аның белән күп тапкырлар аралашырга насыйп булды. Шулай ук Гариф ага, Мөхәммәт Мәһдиев белән дә... Алар теге чорның затлы кешеләре иделәр. Кызын авылга укытырга җибәрүен генә алыгыз... Хәзерге заманда исеме бөтен Союзга танылган, Сталин премиясен алган кайсы кеше шулай эшли, йә?! Гадилеге дә затлылыктан килә торган сыйфат. Беркайчан да нинди авыр шартларда үскәннәрен, ничек кеше булганнарын онытмадылар алар. Гомәр абыйның язмышын үзегез беләсез: бәләкәй чагында ук тегүче ярдәмчесе булып йорттан-йортка йөргән, авыру әтисе урынына хуҗалыкны җигелеп тарткан кеше бит ул...

Менә шулай кул арасына керә башлаган малай тора-бара, тәвәккәлләп, укытучы булыр өчен сынау тота. Үзлегеннән рус телен өйрәнә. Кызыл Армия сафларына алынып, Врангель, Махно гаскәрләренә каршы сугыша, Кырымны яулауда, Сиваш сазлыгын кичүдә катнаша. Армиядән кайткач, Эчке эшләр халык Комиссариатының Казандагы бер еллык махсус мәктәбендә укып, соңыннан дүрт елдан артык Арча кантоны милиция органнарында эшли, 1929–1932 елларда Балтачта һәм Дөбъязда халык тикшерүчесе, судьясы вазыйфасын башкара. Шуннан соң гына язучылыкка таба юл яра – «Кызыл Татарстан» республика газетасына барып урнаша...

3. Гомәр Бәширов хәрби формада. 1920нче еллар.

4. Халык тикшерүчесе булып эшләгәндә мари авылында төшкән сурәт. 1929 ел.

5. Г.Бәширов белән Ю.Вацик Арчадан ерак түгел Казанка аша салынган күпердә. 15 май, 1927 ел.

1. Гомәр Бәширов җәмәгате Кәримә ханым, улы Зөфәр, кызы Лилия белән. Февраль, 1940 ел.

2. Төрле телләрдә басылып чыккан «Намус» романының тышлыклары.

– Ә «Җидегән чишмә» романының прототибы кем икәнен беләсезме, сеңлем? – дип, мут елмаеп, уйларымны таратып җибәрде ул арада Шәфигулла абый. Мин уйга батып торган арада сүзен дәвам итте. – Аны әллә ничә төзәтеп яза бит Гомәр ага, җиде ел буена эшли… Героеның исемен дә берничә мәртәбә алыштыра. Роман язылган көннәрнең берсендә, авылга кайтканда, колхоз рәисе аны йөртер өчен үз шоферын билгели – Каенсардагы Гайнанны. Йөртә Гайнан Гомәр аганы кырлар, басулар буйлап, көне буе йөриләр. Сөйләшеп китәләр… Бик ошатып кала Гайнанны Гомәр ага. Казанга кайтып, әсәрен кабат редакцияләгәндә, героеның исемен, һич тә икеләнмичә, Гайнанга алыштыра.

«НАМУС» НАМУССЫЗЛАНА», ЯКИ «УҢГАН КИЛЕН НӘФИСӘ»

1943 елның 1 августындагы көндәлек язмасында мондый юллары бар: «Намус» дигән бер хикәя язмакчы булам. Сызмалары бар инде, хикәясе кайчан язылып бетәр, Алла белсен…» Тора-бара ул хикәянең артык җәелеп китүе, зуррак күләмне таләп итүе хакында яза. Теркәп барган тормыш елъязмасының һәрберсендә диярлек «Намус» турында сүз чыкмый калмый. «Намус», намуссызланып, һаман бетми әле…» – дип, хафа белдергән урыннар да бар, күңел күтәренкелеге кичереп, дәртләнеп, планнарын теркәгән җирләре дә. Ничек кенә булмасын, якташы Гөлсерия апаның сүзләре хак: Гомәр Бәширов әсәрен, «өстәге каймакны гына сөзмичә», «тирәндәге агымнарны» актарып язуны кирәк дип саный. Бу аның Бөек Ватан сугышы елларындагы эчке бер көрәшенә, намус эшенә әверелә. Улы Зөфәр абыйның бу елларга кагылышлы бер истәлеге бар. Анда ул, салкын фатирда, телогрейкага төренеп, әтисенең киләчәктә СССР һәм дөнья күләмендә танылачак әсәрен язып утырган чакларын хәтердә яңарта. Нәни песиебез әтинең телогрейкасы эчендә кереп җылына иде, ә әти эшен дәвам итә, дигән урыны хәтергә аеруча уелып калган.

«Бу әсәр – минем иҗатым да, мәктәбем дә. Бер үк вакытта язам һәм үземнең иҗат көчемне арный, ныгыта, үстерә барам кебек. Көрәшсез булмый… Бер генә теләгем бар: авырып аяктан егылмасам иде. Авырып китсәм, миңа чир үзе түгел, әсәремне вакытында бетерә алмавым коточкыч азап булачак… «Намус»ны бетерә алмыйча үлеп китсәм?!.. Күңелемдәге иң изге тойгыларымны, туган илем, халкым турында иң кадерле уйларымны шунда әйтеп бирә алсам иде».

Гомәр Бәширов көндәлегеннән, 31 август, 1944 ел.

1948 елда дөнья күргән «Намус»романын 1949 елдан башлап һәр елны диярлек Сталин премиясенә кандидат итеп куялар, әмма ул узмый. Романның рус теленә тәрҗемәсен тоткарлыйлар, соңыннан аны хурлап язып та чыгалар. Гомәр Бәширов үзе «миңа аның халык тарафыннан яратып укылуы да бик җитә» дия торган була. «Намус»ның язмышын Иосиф Сталинның көтмәгәндә-уйламаганда, төн уртасында, Казанга өлкә комитетына шалтыратуы хәл итә. Монысы инде – билгеле, хәтта ки үзенә күрә бер мифка да әйләнгән тарихи факт.

Яңасалалылар белән хушлашып, юлга кузгалабыз – Шәфигулла абый җитәкчелек иткән Арча Әдәбият

һәм сәнгать музеендагы Гомәр Бәширов почмагын карыйсыбыз, архивларны актарасыбыз бар. Юлда кайтканда, «Намус» романы турында сүз чыга.

– Нәфисәнең прототибы кем дип әйтә аласыз? – дип сорыйм Шәфигулла абыйдан.

– Минемчә, Нәфисә образына Гомәр ага татар хатын-кызларында булган иң асыл сыйфатларны мулдан салган, ул бер генә кешедән күчереп алган каһарман була алмый. Монда аның балачагын ямьләгән әнкәсе дә, туганнан туган апа-әбекәйләре дә бардыр, бай йортлардагы ханымнар да, Кәримә ханым да…

Шәфигулла абый фикеренчә, «Намус» романының тәрҗемәләре без белгәннән дә күбрәк. Музейга кайткач, төрле елларда һәм илләрдә бу китапның чыккан тышлыкларын җәеп-таратып салдык: төрекчә, венгерча, кытайча, полякча һ.б.


ОТЗЫВ

Татарский писатель тов. РАЗИН Гумер Баширович за время своего пребывания на Северо-Западном фронте с 23 августа по 28-е октября 1942 года оказал большую помощь Политуправлению по усилению партийно-политической работы среди бойцов и командиров нерусской национальности.

Тов. РАЗИН на передовых позициях организовывал высококачественные материалы для фронтовой татарской газеты "ВАТАН ОЧЕН", выступал на митингах перед боем, проводил большую политическую работу среди бойцов передовой линии.

Очерки тов. РАЗИНА, помещенные в газете "ВАТАН ОЧЕН" - "Сердце закаленное в боях", "Татарин сегодня", "Комиссар Шайхулла Чанбарисов" и др. получили высокую оценку читателей.

ЗАМ. НАЧАЛЬНИКА ПОЛИТУПРАВЛЕНИЯ
СЕВЕРО-ЗАПАДНОГО ФРОНТА
ПОЛКОВОЙ КОМИССАР
/ ГЛАЗКОВ/

[illegible] октября 1942 г.

«Нәфисә» бик уңган килен булып чыкты. Татар башы белән бөтен дөньяны диярлек әйләнеп чыкты. Аны хәзер Польшада, Чехословакиядә яисә Венгриядә генә түгел, хәтта Австралиядә һәм Һиндстанда да беләләр. Китте Нәфисә килен, үзенең салкын әйрәннәре, колак артыннан бәйләнгән җиңел яулыклары белән генә түгел, совет хатынының бай рухи дөньясы, үз мәхәббәте, үзенең коммунистик морале, чын, саф мәхәббәте белән бөтен дөньяның эшчән кешеләренә безнең коммунистик моральне өйрәтеп йөри. Немец укытучысы, аннан безнең илдә чын мәхәббәткә карашны өйрәнәм, ди. Ул Сиднейда бер эшче гаиләне дулкыландырган, ул Болгариядә кемнәрнедер хезмәткә коммунистик карашның ничек булырга тиешлеге турында уйланырга мәҗбүр иткән».

Гомәр Бәширов көндәлегеннән, 10 февраль, 1953 ел.

– Сталин үзе хуплаган һәм шалтыратып мөнәсәбәт белдергән әсәрләр дә, аның илтифаты тәтегән язучылар да бармак белән генә санарлык бит Союзда, – дип, сүзен дәвам итә Шәфигулла ага. – Гомәр аганың Сталин премиясе лауреаты икәнлеген онытмыйлар иде туган ягында, түрәләр бигрәк тә.

«ТЕРЕ ЛЕГЕНДА ИДЕ УЛ БЕЗНЕҢ ӨЧЕН…»

Артык «кызыл», Совет властена дан җырлаган язучыларны, системага каршы барып, лагерьларда черегән «башка»лары белән чагыштырып, беренчеләренә өстенлек биргән чакларым булды. Әмма тора-бара аңладым: татар язучысы, нинди генә системага карамасын, никадәр генә «кызыл» булмасын һәм империя сәясәтенә ничек кенә яраклашмасын, язганнары белән барыбер милләтенең йөзен билгеләүче, телен саклаучы, кыйбласын күрсәтүче булып кала бирә. Әнә бит «татар башы белән дөнья гиздe» ди Бәширов Нәфисәсе хакында. Ә бит Нәфисә асылда бөтен дөньяга татар көнкүрешенең, рухи кыйммәтләренең нәрсә икәнлеген күрсәтә, коммунистик тышчага төрелеп бирелсә дә, ул үз милләтенең матур бер каһарманына әверелә.

– Ә халык өчен Бәшировның Сталин, Ленин премияләре иясе булуы әһәмиятле булдымы икән соң, – дип, риторик сорау белән үземә мөрәҗәгать итәм.

Шәфигулла абый исә аны да җавапсыз калдырмый:

– Булмыйча, ул чорда бит язучының дәрәҗәсе гаять олы иде, ә монда, гап-гади авылдан чыккан булуына карамастан, Союз күләмендә танылган, Сталин үзе бәяләгән шәхес, уен эшмени?! Гомәр агага тере легендага карагандай карый идек без…

«Кичә фронттан кайтып төштем… Сугышны күрдем, аның кешеләрен күрдем. Авыр яклары да күп булды, түздем. Түземлек дигәндә, ул миндә Аллага шөкер бит, җитәрлек. Инде хәзер күргәннәрне оештырып язып чыгарга кирәк… Поездда кайтканда төрле халыкларның сугышта ничек катнашулары турында сүз чыгып китте дә, бер украин егете болай диде: «Татарларны миңа сугышның иң хәтәр урыннарында очратырга туры килде. Алар – куркусыз халык». Үз халкың турында шундый куанычлы сүзләр ишетү бик күңелле…»

Арчадан кузгалып, юлда кайтканда, Шәфигулла абыйның тагын бер сүзе колагымда яңгырап торды:

– Гомәр ага, чорның нинди икәнлеген аңлаганга, үзен гомере буена крестьян, гади авыл мужигы гаиләсендә туып-үстем, дип сөйләсә дә, асылда кем икәнлеген белә иде. Ул алай беркатлы гына дип уйларга ярамас. Гөлсәрия апа сөйләде бит, әнә… Нәселләре затлы булган аларның. Кешенең шәхесе – туфрактан, нәселдән, токымнан бит ул…

Менә шуңа кайтабыз да без Кече ватанга, дип уйлап, үзалдыма елмаеп уздым Арча белән Казан арасындагы калган чакрымнарны…

PRESSA.RU

Тиздән «Татарстан» журналына 100 яшь тулачак. Әлеге олы юбилейны каршылап, без журналыбыз тарихына караган мәкаләләр урнаштырырга уйладык. Бу язмалар төрле елларда редакциябездә эшләп киткән кешеләрнең истәлекләре яисә журналда кайчандыр басылган, әле бүген дә актуальлеген җуймаган, уйланырга мәҗбүр итә торган мәкаләләр булыр дип ниятлибез. Гыйнвар санында яңа рубриканы истәлекләрдән башлыйбыз.

«БЕЗ ЭШЛӘГӘНДӘ, ЖУРНАЛИСТИКА ДҮРТЕНЧЕ ХАКИМИЯТ ИДЕ»

Кайчандыр редакциябездә эшләгән каләм иясе Госман Гомәр, «Татмедиа»га килгән чакларында безгә сугылмый калмый. Үзе эшләгән еллардагы кызыклы хәлләрне искә алып көлдерә, монда эшләгән шәхесләрне сагына. Бу санда аның истәлекләрен сезгә дә тәкъдим итәргә булдык.

«ТАТАРСТАН»НЫҢ ИНКЫЙЛАБЫ

– Хәтерлисездер, журналның элеккеге исеме «Татарстан коммунисты» иде бит. Җаваплы редактор итеп басмага гел партия өлкә комитетында нык «дагаланган» кызыл коммунистларны билгеләделәр. Мәсәлән, Мусин, Афанасьев, Вәлиев. Мин үзем әдәбиятчы-тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин баш мөхәррир булып эшләгән вакытка туры килдем. Бу заманалар болганган чакка, узган гасырның 90нчы елларына, үзгәртеп кору чорына карый. Ул елларда Төркиядәге кардәшләребез «Заман-Татарстан» дип аталган газета чыгарырга теләк белдерде. Ике телдә: татар һәм төрек телләрендә. Дүрт битнең берсе аларга бирелде. Халык бу басманы яратып өлгерде. Зур тираж җыйдык. Мин анда бүлек мөдиреннән алып мөхәррир урынбасары вазыйфасына кадәр күтәрелдем. Анда берара Тәүфикъ Әйди дигән язучы да эшләп алды. Аннары ул үзгәртелеп чыга башлаган «Татарстан» журналына баш мөхәррир урынбасары булып күчте. Берәр ай уздымы икән, минем янга килеп тә җитте: «Госман дускай (ул һәркемгә дускай дип эндәшә иде), анда синсез булмый, әйдә безгә, – дип, ниндидер бер таләпчәнлек белән мине «Татарстан» журналына әйдәкләде. – Анда эш күп. Барысын да яңабаштан үзгәртергә кирәк. Тышлыктан башларга, мөгаен, бик ямьсез бит... Рафаэль абый белән килештерелгән. Мин сине эшкә алу турындагы боерыкны инде әзерләп куйдым. "Заман"нан китү турында гаризаңны яз», – диеп, сөйләшеп торырга урын калдырмады ул.

Тәүфикъ Әйди «Татарстан»да чыннан да үзенчә инкыйлаб ясап ята икән. Элеккеге ике хезмәткәр фән белән шөгыльләнергә киткән, әмма язышып торырга килешкәннәр.

Миңа сәясәт, икътисад, җәмәгатьчелек белән эшләү бүлекләрен бирде баш мөхәррир урынбасары. Тик, ни аяныч, Тәүфикъ Әйди үзе кинәт кенә эштән китеп барды. Ул табигате белән шундый иде: тиктормас. Себер, Урта Азиядән алып Европа илләренә кадәр сәяхәт кылды. Шуңа күрә бөтен авырлык баш мөхәррир белән безнең җилкәгә төште. Ул арада яңа баш мөхәррир билгеләнде. Рафаэль Мостафин редакциядә өлкән хәбәрче сыйфатында эшләп калды. Без аның белән бер бүлмәдә, бер-беребезне ихтирам итеп, шактый еллар эшләдек. Талантлы мөхәррир, әдәбиятчы, тирән белемле инсан иде Рафаэль Мостафин.

ЗАЧЕТ КЕНӘГӘСЕНДӘГЕ ИМЗА

– Тагын бер тарихи вакыйганы искә аласы килә: татар журналистларын әзерләү буенча читтән торып уку бүлеген оештыру турында. Теге елларда, совет чорында, бик күп тырышулардан соң, ниһаять, Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында журналистика буенча читтән торып уку бүлеге ачылды. И аның мәшәкатьләре! Татарстан журналистлар берлеге идарәсе рәисе Шәмси Хамматов яңа бүлекне ачу мөрәҗәгате белән Мәскәүгә, КПСС Үзәк комитетына аена ике-өч мәртәбә барып кайтса, без фәкыйрегезне, идарә сәркатибе буларак, партия өлкә комитетына йөгертте. Ирештек без бу максатыбызга! Инде укытучылар гына табасы калды.

Шәмси Хамматов башта бүлек җитәкчесен тәгаенләде. Бу вазыйфага педагогия институтыннан Пехтелевны күндердек. Әйбәт кенә эшләп китте ул. Ә укытучылар юк дәрәҗәсендә. Төп фән – «Партия-совет матбугаты теориясе һәм практикасы» курсын алып баручыны эзлибез. Тел, тарих, сәнгать мәсьәләләрендә кыенлык сизелмәде – югары уку йортларында укытучы галимнәребез җитәрлек. Әйтик, КДУда мөгаллимлек иткән Якуб Алишев, Хатип Госман, Диләрә Тумашева, Ибраһим Нуруллин, Гомәр Саттаров, Флёра Сафиуллина һәм башкалар бар. Ул чакта студентларны әнә шундый мәртәбәле, танылган галимнәр укыта иде. Алар университетның таянычы булды. Журналистиканың

Фото: Александр Ефремов, Госман Гомәрнең шәхси архивыннан

Госман Гомәр, журналист һәм язучы, 1933 елның 10 гыйнварында Балык Бистәсе районы Шикнәү Чирмешәне авылында туа. Кечкенәдән укырга-язарга өйрәнә: гарәпчәне, латин, кириллицаны үзләштерә. Урта белем алгач, эшкә керә, читтән торып югары белем ала.

1949 елдан бирле вакытлы матбугатта языша. «Чаян» журналы, «Совет Татарстаны» газетасы битләрендә аның фельетоннары, хәбәрләре басылып тора. 1961 елдан Госман Гомәр «Социалистик Татарстан» газетасында эшли, берүк вакытта Татарстан Журналистлар берлеге идарәсе сәркатибе вазыйфаларын башкара. Соңрак «Татарстан яшьләре» газетасына күчерелә һәм 17 ел әлеге басмада хезмәт куя. 1993–1997 елларда халыкара «Заман» газетасында баш мөхәррир урынбасары булып эшли. 1997–2005 елларда «Татарстан» журналының бүлек мөхәррире вазыйфаларын башкара.

Госман Гомәр Татарстан ССРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1993 ел), журналистларның Х. Ямашев исемендәге премиясе (1983 ел), язучыларның Ф. Хөсни исемендәге премиясе (2016) лауреаты, «Шәрәфле аксакал» медале иясе.

төп фәнен кем укытырга тиеш дигән сорау туды. Шәмси Хамматов тагын «колакны борырга» кереште. «Уйлан, Гумеров, уйлан», – ди бу. Шулчакта мин Рафаэль Мостафинны искә төшердем. Үзем Удмуртия чигендәге Красный Бор районында эшләгәндә чиктәш Сарапул шәһәре газетасындагы хәбәрче Рафаэль Мостафинны белеп калган идем. Аннары ул Мәскәүдә «Литературная газета» басмасының урыннардагы үзхәбәрчесе вазыйфаларын башкарды. Инде журналистика бүлеген оештырып йөргән чорда Татарстан телевидениесендә баш мөхәррирлекне алып бара иде. Аннан да кулай кеше юк, дим Хамматовка. Барып сөйләшергә туры килде. Төп эшеннән аерылмыйча гына укытырга ризалашты ул. Журналистиканың читтән торып уку бүлеге гөрләп эшләп китте. Район, шәһәр газеталарында эшләүче хәбәрчеләр, КПССның Чистай шәһәр комитеты инструкторлары, Башкортостан партия өлкә комитеты һәм Ульяновск өлкә комитеты инструкторлары укыды әлеге бүлектә. Уку-укыту процессы адәм ышанмаслык тизлек һәм төгәллек белән эшләп китте. Рафаэль Мостафин редакциядә хатлар һәм җәмәгатьчелек белән эшләү темасы буенча практик дәресләр алып баруны миңа ышанып тапшырды. Үзем дә шунда укыйм. Курсташларыма билгене дә мин куям. Кем редакциядә эшли – аңа «бишле». Күпләрнең зачет кенәгәләрендә имзам саклангандыр, дип уйлыйм.

ФЕЛЬЕТОН АРАНЫ БОЗМАДЫ

– Ләкин уку – энә белән кое казу дип юкка гына әйтмәгән борынгылар. Бигрәк тә яңа оешып килгән юнәлешне күтәрү, аның чишмә башында тору – шактый катлаулы бурыч. Безнең мөгаллимнәр моны җиренә җиткереп башкарды, горурланмый мөмкин түгел. Укулар гел җиңел генә бармады. Үзем дә бик кыен хәлгә калганымны хәтерлим. Практика буенча «Коммуналь җиһазлар» заводыннан кинохроника эшләп, телевизион тапшыру чыгарырга тиеш идем. Ләкин мине телевидениедә киноаппарат белән тәэмин итә алмадылар. Тапшыруым фоторепортаж рәвешендә генә килеп чыкты. Ачуым кабарды. Үзем эшли торган «Социалистик Татарстан» газетасында «Гайнетдин бабайның хәтере калды» дигән әче итеп язылган күләмле фельетон бастырдым. Менә сиңа мә! Тәнкыйтькә җавапны баш мөхәррир, укытучым Рафаэль Мостафин язган иде. Әдәпле кеше. Каты бәрелмәгән, «автор безнең үзенчәлекне бераз аңлап бетермәгән» дигәнрәк нәтиҗә чыгарган. Шүрләдем, әлбәттә. Ачу саклап, үче булмасмы, диеп... Юк, андый түбән җаннардан түгел иде әдип! Уку-укытуыма гел «бишле»ләр тезде ул. Фельетон мәсьәләсе арабызны бозмады. Әнә бит ничек матур эшләдек аннан соң «Татарстан»да!

PRESSA.RU

БАУЛЫДАГЫ ВАКЫЙГА

– Нефтьчеләрнең Ан-2 очкычында Баулы урманын күрсәткәннәр иде. Исем китте – урталыкта киң полосалы яшькелт билгене күреп! Күр син – фашизм свастикасы!..

Аңлаттылар. Сугыштан соң немец әсирләрен алып килеп нефтьчеләр өчен урман аша юл салуны йөклиләр. Урталыкта гаять киң полосалар хасил була. Нефть вышкалары үсеп чыга. Бар да яхшы. Беркем бернәрсә белми. Эшне бетереп, әсирләр үз илләренә кайтып китәләр.

Соңыннан, самолётта күтәрелгәч, абайлыйлар: урман уртасында фашизм билгесе ярылып ята! Ул яшеллек әле дә күренә, диләр.

«Татарстан» журналы фотохәбәрчесе Солтан Исхаков белән шуларны төшереп алмакчы идек. Атаклы совхоз директоры Геннадий Сәмигуллин самолёт белән ярдәм итәргә теләгән иде, ләкин эш барып чыкмады. Шулай да сәфәребезнең нәтиҗәсе буларак Баулы районының алдынгы совхозы турында очерк туды. Алдынгы тәҗрибә буларак яхшы бәяләнде. Бер уңышсызлыкның биш куанычы була икән, әй!

КИЧӘГЕ ҺӘМ БҮГЕНГЕ «ТАТАРСТАН»

– Мин эшләгән «Татарстан» белән бүгенге журналның уртак яклары да, аермалы яклары да бар. «Татарстан» исемендә журнал башта бары тик татар телендә генә басылды. Рус телендәгесе 2001 елда торгызылды. «Татарстан» журналы темалар, язу стиле белән башка матбугатлардан һәрвакыт аерылып торды. Илдә нинди генә вазгыять булуга карамастан, республиканың төп басмасы булып калуын дәвам итте.

Татарстан мөстәкыйль республика статусы алганнан соң, заманалар үзгәреп китте. Әлбәттә, бу «Татарстан» редакциясе эшчәнлегендә дә сизелде. Беренчедән, журналның дәрәҗәсе үсте. Битләр саны артты, форматы зурайды. Аңа кадәр журналда галим, сәяси аналитиклар эшләгән булса, 1992–1993 елларда редакциягә журналистлар килде. Ә галимнәр штаттан тыш хәбәрче булып калды. Ни өчен журналистлар кирәк булдымы? Баш мөхәрриргә: «Журнал битләрендә Татарстанда алып барылган төзелешләрне, республиканың уңышларын, проблемаларын күрсәткән язмалар кирәк», – диелгән таләп куелды.

«Татарстан» журналы темалар, язу стиле белән башка басмалардан һәрвакыт аерылып торды. 1990нчы елларга кадәр академик басма саналса, 2000нче елларда ул тәнкыйди, тормышка якынрак мәкаләләр бастыра башлады. Бүген журнал мин белгәннән бирле өченче тапкыр үзгәреш кичерә. Бүген ул халыкка якынрак, минемчә, гади кешеләрнең тормышы, яшәеше турында яза. Яратып укыйм журналны. Заман хәлләреннән, яңалыклардан хәбәрдар булырга, тормыштан артта калмаска тырышам.

Менә без шул күрсәтмә буенча эшкә керештек тә. Кая гына бармадык! Һәр шәһәрдә, һәр районда ниндидер зур объектлар төзелә, чын мәгънәсендә милли тормыш гөрли. Язып кына өлгер!

Күңелле яшәдек. Октябрь революциясе, 1 Май, Матбугат көннәрен республиканың төп басмасы буларак зурлап бәйрәм иттек. Һәм күп эшләдек тә. Командировкага чыгып киткәч, әллә ничә көн йөреп кайта идем. Өйдә ике бала да бар, хатынга, мин югында җиңелрәк булсын дип, фатирга хәтта ике студент кызны яшәргә дә керттек. Алар балаларны бакчага, мәктәпкә алып бара, алып кайталар.

ЗАМАННЫҢ БАШКА ЧАГЫ

– Журналистларның дәрәҗәсе бик зур иде без эшләгән чорда. Казаннан килгәч тә, башта туп-туры район җитәкчелегенә керә идек. Бүген генә ул журналистлар берәр түрә янына барасы булса, алдан әллә ничә кат шалтырата, хат яза. Безнең заманда журналистика чынлап та дүртенче хакимият иде. Һәм аның сүзе дә үтте. Берәр җитәкчекне яки аерым хәлне тәнкыйтьләп чыгасың икән, икенче көнне үк чарасы күрелә.

Журналистикага 1952–1953 елларда килдем, «әл-Ислах», «Кояш» газеталарында эшләгән хөрмәтле каләм ияләре белән бергә эшләргә туры килде. Алардан күп нәрсәгә өйрәндем, дип саныйм. Берсендә, җаваплы сәркатип язманы кире бирде: «Хатасын үзең тап!» – ди. Кат-кат укып чыктым, аннан гына күрдем: бер бит текстта ике «булды» сүзе язылган икән. Текстның төзелешенә, җөмләләрнең камил булуына игътибар шулкадәр зур иде. Безгә карата да таләпчән булдылар редакторлар.

P.S. 85 яшемне тутырсам да, Аллага шөкер, үземне яхшы хис итәм. Мәчеткә биш вакыт намазга йөрим. Каләмне дә читкә куймадым, китап нәшер итәргә җыенам, «Мәдәни җомга» газетасына язам. Әле тормышка ашырасы планнарым да байтак.

Әзерләде:
Руфия Фазылова

ПЕНСИЯГӘ ЧЫККАЧ – **ДӨНЬЯ ЧЕМПИОНЫ!**



Редакциябезгә чын мәгънәсендә легендар шәхес – Әхмәт абый Сираҗиев килде. Ветераннар арасында чаңгы буенча – 17, йөгерү буенча 12 тапкыр дөнья чемпионы ул. Тормыш кыйммәтләре, яшәү рәвеше белән дә уникаль кеше!

«Миңа туксан гына бит әле», – ди Әхмәт абый, моның һич гайре табигый нәрсә түгеллегенә ишарә итеп. Аның киләчәккә планнары бихисап... Ул әле һаман да күзлексез укый, гәүдәгесен егетләрчә төз тота, бик яхшы хәтере, зиһене белән чын-чынлап мактана ала.

«СПОРТ ТҮГЕЛ, Ә ЯШӘҮ РӘВЕШЕ!»

– Кая барсам да бер сорауны бирәләр: «Спорт белән кайчан шөгыльләнә башладыгыз?» Хәзерге заман күзлегеннән чыгып караганда, сорау дөрестер, бәхәсләшмим. Әмма без үскәндә спорт белән махсус шөгыльләнү түгел, ул хакта уйлау да юк иде. Гәрчә үземне белгәннән бирле йөгерсәм дә, чаңгыда шусам да. Әмма бу «спорт белән шөгыльләнү» дип аталмады, яшәү рәвешебез, гадәти тормышыбыз иде. Җиде ел сигез чакрым ераклыктагы күрше авылга йөреп укыдык. Кышын чаңгы белән барабыз, яз, көз җәяү элдертәбез. Безнең өчен иртәнге, кичке тренировка булган инде ул.

Тумышым белән Яшел Үзән районының Карашәм авылыннан мин. Туган авылда дүрт класс укыганнан соң, безне күрше Панау авылының башлангыч мәктәбенә җибәрделәр. Анда янә дүртенчедә укыдык –

Фото: Александр Ефремов

PRESSA.RU

Автор:
Руфия Фазылова

рус телендә. Бишенче сыйныфка Рус Әҗиле мәктәбенә барырга кирәк иде. Русча бер авыз сүз белмибез бит... Әти-әниләр, русча өйрәнсеннәр дип, башта Панау мәктәбенә җибәрде. Беренче мәлгә рус малайлары безне кабул итмәде, көлү, мыскыллау, сугышулар, дисеңме... Карашәмнән дүртенчегә алты малай килгән идек, бер айдан соң Бәхтияр Зарипов белән икәү генә калдык. Калганнар мәктәпне ташлады. Без исә бирешмәдек, кирәк чакта каршы тора алдык. Тик мондый мөнәсәбәт озак бармады – кышка кергәнче үк инде, Панау малайлары белән дуслашып, күңелле яши башладык. Әле бер йортта кунып та кала идек. Бер ел дигәндә русча язарга, укырга, яхшымы, начармы – сөйләшергә дә өйрәндек. Рус Әҗиленә килгәч тә Панау башлангыч мәктәбендә бергә укыган шул классташлар безне яклап чыкты. Рус Әҗилендә дә рус малайларының, «татарин» дип, кире кагулары баштагы мәлләрдә булды. Тик соңрак милләтләргә аерулар бетте, әле аларны да татарчага өйрәттек. Мәктәпне тәмамлагач та, аралашып яшәдек.

ИҢ КАДЕРЛЕ БҮЛӘК!

– Дөньякүләм ярышларда җиңү яулагач, ни өчендер күпләр мине бай кеше дип уйлый. Очрашуларның берсендә: «Пенсиягә өстәмә түләү күпме аласыз?» – дип сорадылар миннән. «Бер тиен дә алмыйм», – дигәч, гаҗәпләнде әңгәмәдәшем. Әйе, мәскәүләр чемпион булган ветеран спортчыларына ай саен өстәмә акча түли. Миңа: «Сез Татарстан Республикасыннан, алардан сорагыз», – диделәр. Ә Казанда исә: «Дөнья ареналарында Россия данын яклыйсың, мәскәүләр түләсен», – диделәр. Менә шулай итеп, ярышларда катнашкан өчен бөтен бүләк – дистәләгән медальләр. Аларны барысын бергә җыйсаң, авырлыгы ун килога җыеладыр. Хәер, мин ярышларда акча өчен катнашмыйм. Шулай да күңелдә мондый гаделсезлеккә карата азрак үпкә бар инде, юк түгел...

Җиңүләр күп булды. Ләкин хәтергә мәңгегә уелып калганы бары бер генә, дөресрәге, аның бүләге. Сугыштан соңгы еллар. Без, мәктәп балаларын, Казанга чаңгы ярышына алып килделәр. Биш чакрым еараклыктагы араны җәлт кенә узып килдем. Һәм бүләккә йон кофта бирделәр. Мин башта аңламый тордым: бәлки, ялгышканнардыр? Шундый затлы бүләкне миңа, гади авыл баласына, бирерләрме икән? Алма, помидордан кала, башка бүләкләр дә була дип белмәгән балалар бит без! (Карашәмдә, өлкәннәр, еш кына авыл балаларын ярыштыра иде. Беренче килүчегә бүләккә – өч алма, икенче килгән кешегә – икене, өченче урынга бер алма бирәләр). Мин тиз генә кәгазьгә төрелгән кофтамны куенга кыстырдым да йөгердем тимер юл вокзалына. Кеше-кара күргәнче ярыш булган урыннан таярга кирәк! Йә кире тартып алырлар! Товар поездына утырып, Албаба станциясенә кадәр кайттым. Теге кофтаны чыгармадым. Өйгә кайтканчы ул кадерле бүләк тәнемне кытыклап, җылытып торды. Әйтерсең, әниемнең мичтән чыккан кайнар икмәге (анысы да тансык). Бүләккә бирелгән кофтаны бик озак еллар кидем. Тәнне генә түгел, җанны да җылыта иде ул. Ә, әле тагын шунысы кызык: Казаннан чаңгы ярышыннан кайткач, мине Яшел Үзән районының Хәрби комиссариатына чакырттылар. «Ничәнче урын алдың?» – диләр. Ә мин нәрсә әйтергә дә белмим, чөнки йон кофтаны кулга тоттыргач, урын турында сорарга да онытканмын. Урын кайгысымы ул чакта...

ТЫЛСЫМЛЫ ГАРМУН

– Бөек Ватан сугышы башланганда миңа унөч яшь иде. Әтине, инде олы яшьтә булганлыктан, сугышка алмадылар. Безнең гаиләгә сорау аеруча зур: эш кушып кына торалар. Иртәнге дүрттә торып, колхоз кырына чыгып китәсең, кар яуганчы кайту юк... Ул чорда төп көч үсмер балалар белән хатын-кызлар иде шул.

Көз көне авылда бер гадәт бар: урып-җыю беткәч, өй түбәләренә яңа салам түшиләр. Аннары яз җиткәч, ул саламны алып сыерларга ашаталар. Күтәремгә калган сыерларны ачтан үтермәскә кирәк. Йорттан-йортка шулай салам түшәп йөрибез. Мин өй түбәсенә менәм дә саламны алып торам, зурраклар астан бирә. Шулай салам түшәп йөргәндә күзем зур булмаган гармунга төште. Хуҗабикә Саҗидә апага өстән кычкырам:

– Гармун таптым, гармун!

– Ярар, үзеңә ал. Кәрим абыеңныкы ул. Сугыш кайчан бетә дә, ул кайчан кайта бит әле. Әгәр кайтса... Әнә, Әкрамның үле хәбәре килгән... Гармун кайгысы түгел әле монда!

Миңа шул сүз җитә калды: саламны түшәп бетерүгә, өйгә элдерттем! Зурлар басудан кайтып җиткәнче, уен коралын яшереп куярга кирәк. Әти белән әни күрсә:

«Каян алдың? Бу ни?» – дип аптыратып бетерерләр.

Шуннан башланды: өйдән кеше чыгып киткәнне көтәм дә кулга гармун алам. Уйныйсы килү теләге шулкадәр көчле! Алай басам, болай... Берсендә әни ишеткән:

– Ярар, улым, өйрән. Гел елап кына утырырга димәгән, уйна...

Тик әтигә гармунда уйнавым бер генә дә ошамады:

– Утырма әле монда шыңгыр-мыңгыр, кайчан карасаң да, кулыңда гармун. Тапкан эш! – дип гел тирги торды. – Гармуныңны балта белән чабам, – дип тә куркыткалады.

Тик мин үз дигәнемә барыбер ирештем: аерым татар көйләрен уйнарга өйрәндем. Тора-бара гармун тавышын тыңларга капка төбенә кешеләр җыела башлады. Берсендә әти эштән кайтып килә. Минем янга авылның яшь хатыннары, апалары җыелган:

– И, әле ярый Әхмәт бар. Бөтен кайгыларны оныттырып тора, – диләр.

Әти түзмәде, йомшарды. Үзе дә утырып гармун тавышын тыңлады. Аннан:

– Улым, мин сиңа яңа гармун алып бирәм әле, сугыш кына бетсен. Абыең исән-сау әйләнеп кайтсын, – диде.

Әти сүзендә торды. Сугыш беткәч, яңа гармунлы булдым. Абыем да сугыштан исән әйләнеп кайтты. Әйе, бер кулын өздереп, тик үз аягында, үз акылында. Бүген дә исән, Аллага шөкер, 98 яшендә туган авылыбызда кызы тәрбиясендә яшәп ята. Ә теге Кәрим абыйдан калган гармунда авылның бик күп бала-чагасын уйнарга өйрәттем. Җиңел, тылсымлы гармун булды ул. Кәрим абый сугыштан исән-имин кайтты, уен коралын яңадан сорамады ул. Күрәсең, гармун барча авыл баласының юанычы икәнен аңлагандыр....

ИЛЛЕДӘ ТОРМЫШ БАШЛАНА ГЫНА...

– Профессиональ спортка шактый соң килдем. Дөрес, җәй чыккан саен чаңгыда йөрергә, йөгерергә чыктым.

Язмыш мине дөнья буйлап шактый йөртте. Урта белем алгач, Саратов шәһәрендәге авиамеханиклар мәктәбендә укыдым. Аннан шул юнәлеш буенча училище тәмамладым. Һәм мине Чита шәһәренә Ил-10 самолетында механик булып эшләргә җибәрделәр. Шуннан Краснодар өлкәсенә киттем. Казанга 1974 елда гына әйләнеп кайттым. Инде гаиләм, буй җиткән ике кызым, хатыным бар иде. «Элекон» заводына эшкә урнаштым. Ул вакытта заводта спортның күп төрләре: чаңгы, йөзү, йөгерү бик популяр иде. Мин барысы белән дә шөгыльләндем. Спортны ярату – канга сеңгән, кечкенәдән килә.

Ун ел мәктәптә, аннан Саратовта бергә укыган иң якын дустым, авылдашым Бәхтияр Зарипов Казанда яши иде. Ул да спорт белән җенләнгән, чаңгыда яхшы шуа. Мин классик стильне генә беләм.

– Әйдә, мин сине бер тренер белән таныштырам. Чаңгы спортының бар нечкәлекләренә өйрәнерсең, – диде Бәхтияр миңа шулчакта.

Шулай итеп тренер белән иректе стильне үзләштердем. Һәм чаңгыда йөрү өчен кыш җиткәнен көтеп тора башладым. Ә һәр көн иртән йөгерүне үземә максат итеп куйдым. Спорт белән күбрәк шөгыльләнгән саен, сәламәтлегемнең яхшыра баруын абайлап алдым. Менә шулай илле яшемдә спортчыга әйләндем.

БЕРЕНЧЕ ҖИҢЕЛҮ, ҖИҢҮЛӘР

– Заводта эшләгәндә «спортчы» диган кушамат тактылар. Танышлар, йөгерү, чаңгыда узышу буенча сәләтең зур дип, Европа, аннары дөньякүләм ярышларда катнашырга кыстый башладылар. Ул вакытта Татарстанда, Россия күләмендә үз яшемдәге спортчылар арасында җиңүләрем күп иде. Тәвәккәлләп, 1988 елда җиңел атлетика буенча Европа чемпионатына киттем. Италиянең Чезенатико шәһәрендә узды ул. Шунда 5 км һәм 10 км дистанцияләрендә чемпион булдым. Беренче зур җиңү! Сөендем, әлбәттә. Ә чаңгы ярышына беренче чакыруны 1994 елда алдым. Тик Норвегиядәге старт минем өчен уңышсыз – 15нче урын белән тәмамланды. «84 кеше арасыннан 15нче урын яхшы», – дип, танышлар юаткан булды. Тик мин андый фикер белән килешә алмыйм. Спортчының максаты бары бер генә – җиңү! Булдыра алмыйсың икән, йөрмә! Менә үземә шундый таләп куйдым.

Норвегия тауларында текә борылышларга игътибар иткән идем. 15нче урынга калуым да шул тауларга бәйле. Алымнарны белмәсәң, анда чаңгың да, аягың да сынарга мөмкин. Казанга кайткач, мин дә тауларда шуу алымын шомартырга булдым. Андый урын эзләп ерак барасы түгел – Юдино таулары менә дигән урын. Таныш спортчыларны да ияртттем. Менә шулай бер-ике ел шөгыльләнгәч, Герма-

17 ТАПКЫР ЧАҢГЫ ЯРЫШЛАРЫ БУЕНЧА ДӨНЬЯ ЧЕМПИОНЫ:

2004 ел – Норвегия, Лиллехаммер шәһәре – 10, 15, 20 км дистанцияләрдә;
2005 ел – Россия, Красногорск шәһәре – 10, 15, 20 км дистанцияләрдә;
2009 ел – Франция, Отрон шәһәре – 5, 10 км дистанцияләрдә;
2010 ел – Швеция, Фалун шәһәре – 5, 10 км дистанцияләрдә;
2011 ел – Канада, Ванкувер шәһәре – 5 һәм 15 км дистанцияләрдә;
2011 ел – Австрия, Мариацель шәһәре –15, 20 км дистанцияләрдә;
2014 ел – Австрия, Пиллерзесталь шәһәре – 5, 10, 15 км дистанцияләрдә.

12 ТАПКЫР ҖИҢЕЛ АТЛЕТИКА БУЕНЧА ДӨНЬЯ ЧЕМПИОНЫ::

1999 ел – Бөекбритания, Гейтхед шәһәре – 5000 м, 10000 м, 8 км (кросс) дистанцияләрдә;
2005 ел – Испания, Сан-Себастьян шәһәре – 10000 м, 8 км (кросс) дистанцияләрдә;
2008 ел – Франция, Клермонт шәһәре – 800 м, 1500 м, 3000 м һәм 8 км (кросс) дистанцияләрдә;
2014 ел – Венгрия, Будапешт шәһәре – 1500 м, 3000 м һәм 8 км (кросс) дистанцияләрдә.

ниядә чаңгы буенча Дөнья чемпионатында катнашып, 2нче урынны алып кайттым. Һәм ел саен булган осталыкны арттыру өстендә эшләдем. Спортчы: «Ардым яки мин болай да булдырам», – дип өендә ята икән, бетте. Арбадан төшеп калды, дигән сүз.

ИРЛӘРЧӘ ЯШӘРГӘ КИРӘК!

– «Ничә яшькә кадәр Дөнья чемпионатларында катнашырга уйлыйсың?» – диләр. «Исәнлек булганчы», – дип җавап бирәм. Аллаһы Тәгаләгә мең рәхмәтлемен! Исәнлек, сәләт, ихтыяр көче биргән.

Менә әле җиңел атлетика буенча Франциядә узачак Дөнья чемпионатына әзерләнәм. Миңа гыйнварда 90 яшь тулды, димәк, хәзер 90–95 яшьлекләр арасында көч сынашачакмын. Кызганыч, бу яшьтәге спортчылар күп түгел. Узышырга кеше булса ярый, дип тә борчылам. Хәер, барыбер йөгерергә җибәрәбез, диделәр, дистанцияне күпме вакытта узганны белү өчен. «Әле Гиннесс рекордлар китабына да керергә мөмкинлегең зур», – диделәр. Хәер, анысы мөһим түгел. Шул кәҗәсе дип түгел, мәзәге өчен булса гына.

Чит илләргә баргач, журналистлар еш кына җирле телевидениегә чакыра. «Россиядә сезнең кебек кешеләр күпме?» – дип сорыйлар. «Күп», – дип җавап бирәм. Әлбәттә, күп түгел. Аллаһы Тәгалә бүләк иткән сәләт бер булса, үз өстеңдә эшләү икенче зур әйбер. Тормышта бернәрсә дә җиңел генә, юкка гына бирелми. Мин һәр көнне иртәнге дүрттә торам. Яңгырмы, кармы – иртәнге биштә «Тасма» спорт мәйданына чыгып китәм. Биш чакрым йөгерәм. Җиденче яртыда кайтам да хатыным Саниягә иртәнге аш әзерлим. (Ул өч елга якын урын өстендә ята). Кайвакыт Сания: «Син ир кеше, мине карап арыйсыңдыр», – ди. Чын күңелдән әйтәм – бер генә дә авырсынмыйм. Утыз ел хатыным мине тәрбияләп, ир итеп кадерләп яшәде. Нәрсә, авырый башлагач, ул артыкка әйләнсенме?! Бу бит ирләрчә булмый...

P.S. Әхмәт абый Сираҗиев Казанның Коләхмәтов урамында кечкенә генә бер бүлмәле фатирда яши. Легендар спортчының бердәнбер зур хыялы – иркенрәк фатирга күчү. Югыйсә кысан фатирга бер кешене кунакка да чакыра алмый. «90 яшьлек юбилеема Россиянең төрле шәһәрләрендә яшәүче дусларым килгәч, бик кыенсындым. Ни йоклатырга урын юк. Өстәвенә, хатын да урын өстендә...» – диде. Тыйнак кеше шул Әхмәт абый. Югыйсә дөнья күләмендә шундый зур җиңүләргә ирешкән спортчы әллә кайчан торак шартларын яхшырткан булыр иде. Шулай да әле соң түгел. Үзе әйтмешли: «Аңа 90 яшь кенә әле». Редакциябезгә 100 яше тулгач та килергә вәгъдә бирде. Бирсен Ходай! Тормышка позитив карашлы, сәламәт яшәү рәвеше алып баручы бу шәхес барыбызга да үрнәк. Андыйлар турында: «Рәхәт кеше», – диләр. Әхмәт абыйдан бик җылы бер нур агыла. Ә яңа фатирга килгәндә, бик нык ышанасы килә: киләсе юбилеена кадәр легендар спортчы иркен фатирга күченер...

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Китап киштәсендә **НИЛӘР** бар

«Татарстан» журналы премиясе **КЕМГӘ** тапшырылды

Һуннар короле **КЕМ** ул

Мулла Иле **НИЧЕК** яши

PRESSA.RU

Автор:
Луиза Янсуар

«БЕЗ БАРЫ ДӨНЬЯНЫ ЯХШЫРАК ИТӘРГӘ ТЕЛӘГӘН ИДЕК...»

2017 ел безгә «эһ, әйбәт китапны бозганнар...» дип уфтанырлык түгел, ә «менә, ичмасам, шәп төшергәннәр!» дип сокланырлык экранизацияләр бүләк итте. Уильям Пол Янгның «Хижина», Агата Кристиның «Убийство в Восточном экспрессе», Дафна дю Морьеның «Моя кузина Рейчел», Стивен Кингның «Оно» һәм башка романнар буенча төшерелгән фильмнарны бу исемлеккә шикләнмичә кертергә мөмкин. Әлбәттә, бу – субъектив исемлек. Арадан тагын ике деликатесны сезгә иркенләбрәк тәкъдим итәргә телим.



«НИК УЛ БЕЗНЕ ИШЕТМИ?!..»

**Сюсаку Эндо, «Молчание» романы
Мартин Скорсезе, «Молчание» фильмы**

2017 елда экраннарга чыккан «Молчание» фильмы безнең кайсы чорда нинди идеологиягә нигезләнеп һәм нинди кыйммәтләрне өстен күреп яшәвебез хакында тагын бер кат уйланырга мәҗбүр итте. Скорсезе бу юлы саундтректан тулаем диярлек баш тарткан, табигый тавышларга өстенлек биреп, тыенкы, беркая да ашыктырмый торган темпны сайлаган. Аңлашыла ки, касса җыемнарына йөз тотып эшләнмәгән әлеге фильм. Шуңа аны киң прокатка бик шикләнеп кенә чыгарулары да табигый. Ә бит фильмга кадәр роман бар иде, сүзне романнан башлыйк әле...

Сюсаку Эндо Россиягә 60нчы елларда килеп ирешә һәм, тәнкыйтьчеләр фикеренә ышансак, нәкъ менә «Молчание» белән «Самурай» романнары бездә иң билгеле әсәрләреннән исәпләнә. Ул күпсанлы әдәби премияләр лауреаты, берничә тапкыр Нобель премиясенә дә тәкъдим ителә.

Сюсаку Эндо нигездә дини темаларга язучы христианин-язучы буларак билгеле. Эндо католицизмны Франциянең Лион университетында җентекләп өйрәнә. Ул япон католицизмын балачагында әнисе тарафыннан киертеп куелган, әмма «өстендә начар утыра торган көнбатыш костюмы»на тиңли. «Молчание» романы өчен менә дигән ачкыч аның бу сүзләре. Романның нигезендә XVII гасырга караган реаль вакыйгалар ята. Аның документаль чыганагы – миссионерларның Япониядән Португалиягә юллаган хатлары, әлеге хатлар, әйтүләре буенча, Лиссабонда бүгенге көндә дә саклана. Христианлыкның Япониягә үтеп керүенә теше-тырнагы белән каршы торган япон идарәчеләре хакимлек иткән чорда испан миссионерларының монда «хак дин» китерүләренә багышлана Эндо романы.

Әсәрнең төп геройлары Родригес белән Гаррпе – яшь руханилар. Кайчандыр аларны семинариядә атаклы падре Феррейра укыткан була. Аннары падре Япониягә «христанлык орлыклары чәчәр өчен» китеп бара да, «кыргый» илдәге ситуацияне аңлатып хатлар язып тора. Көннәрдән бер көнне аның турында «хак диннән ваз кичкән» дигән хәбәр килеп ирешә. Моңа ышана алмыйлар, әмма хәбәр таралганнан-тарала, Көнбатыш христиан дөньясының хурлыгы булып әверелеп бара. Родригес һәм Гаррпе, остазларын табып, бу хәлгә ачыклык кертер өчен, Япониягә кузгала.

Килеп төшүгә, иман китергән христианнар арасына килеп эләгәләр. Яралганда ук «ярлы-ябагайлар», «рәнҗетелгәннәр», «кире кагылганнар» дине булган христианлыкның ни өчен ярымачлык-ялангачлык чигендә торган, коточкыч шартларда яшәгән фәкыйрь крестьяннар арасында таралганлыгын ваемлау Родригесны сискәнергә мәҗбүр итә. Әмма ул әле «ал күзлеген» салырга ашыкмый... Шулай да тора-бара үзе алып килгән «хак дин»нең ничек итеп башка мәдәният казанында кайнап эретелүен, ләкин ул көткән, өметләнгән алхимик эффекта китермәвен тоя башлый. Ахыр чиктә, үзенә кадәр бирегә килгән Феррейраның иманыннан ни хакына баш тартуы ачыклана. Кеше хакы өчен: «Ул монда гомерен японнарга багышлар өчен килде, әмма чынлыкта аларны үзе хакына үләргә мәҗбүр итте».

Мең михнәт кичеп, Японияның чатырманнары, таулары аша йөрәгенәрәк үткән саен Родригес ныграк әрни. Кешеләрнең – һәм японлы, һәм Европадан агылган руханиларның – өзлексез җәзага таруын, җәфаланып үлүен, Христос кичкәндәй, үз Голгофасын кичүен күреп-күзәтеп торганнан соң, аларның санын-исәбен җуеп, Алласына мөрәҗәгать итә: «Ник син балаларың шулкадәр газапланганда берни эндәшмисең?!» Әмма җавап алалмый.

Ахыр чиктә Феррейра белән очраштыралар аны. Остазын сатылуда, чын христианин булмауда гаепли Родригес, тик Феррейраны инде бу сүзләр куркытмый: «Мин хурлыкны да, үзем белән көрәшне дә кичтем», – ди кайчандыр кайнарлыгы белән аерылып торган Феррейра, көтмәгәндә тыныч кына көлемсерәп. Аның яңа иманы Родригесның ышанычын айкап ташлый: «Син ваз кичмәгән өчен дистәләгән, йөзләгән кеше терелəй тунала, айлар буе газапланып, үлә алмыйча интегә. Аларның һәр тамчы каны өчен син җавап бирәсең. Тегендә алар Алла каршына барырлар да, бәлки. Ә монда «динем хакына» дип, «алар җәннәткә керәчәк» дип, үзеңне хөкемдар урынына куярга хакың бармы синең?! Мин хакым юк, дигән карарга килдем. Иисус биредә булса, аларны коткарыр өчен, ул да ваз кичәр иде...»

Болары бер хәл, иң куркынычы – ул Родригесның әле һаман да күзләрен каплап торган күзлекне үк салып ташлый:

– Они верили не в христианского Бога, – повторил с уверенностью Феррейра. – У японцев не было, и нет идеи Бога... Японцы не знают Творца, отделенного от человека. Они не способны вообразить себе Сущее вне привычной реальности... Бог у японцев – идеально-прекрасное, наделенное волшебным могуществом существо. Но он – одной природы с людьми. Это не канонический Бог христианства. И потому я считаю бессмысленным труд проповедника... В словах Феррейры была неподдельная горечь.

«Кем без тарих аренасында?» – дигән сорау туа Родригеста. «Кем без Аның каршында», – дими инде ул. Чөнки, ни аклау, ни хурлау ишетмәгән Бөек Көч алдында үзенең намусы белән нишләргә белми ул хәзер. Ә аклаучы яки хәкарәт итүче булмаган очракта барысы да гадәти фарска әверелә, тамашага.

Мартин Скорсезе безгә христианлык темасына моңарчы төшергән бер апокрифы – «Последнее искушение Христа» фильмы аша таныш. Белүебезчә, ул кайчандыр үзе дә рухани булырга ниятләгән була, әмма кинематографка кереп чума. Әйтүенчә, «Молчание»не төшерү идеясен 30 ел дәвамында уйлап йөргән. Фильмны тамашачыга тәкъдим иткәндә, режиссер реклама кампаниясеннән баш тартты һәм аның бүгенге көндә беренче чиратта киноиндустрияне бәяләүчеләрдән бигрәк, гади кешеләргә кирәклегенә басым ясады. Оператор эше өчен «Оскар» алган картина тәнкыйтьчеләр лагерен кыл икегә аерды: кемнәрдер Скорсезены аңламаулары турында гәп сатты, кемнәрдер, киресенчә, режиссерның соңгы еллар иҗатындагы шедевры дип тапты. Артык сүз куертмыйча, әйбәт идея, әйбәт эшләнгән фильм, һәм афәрин, Скорсезе, диясем килә.

«74 яшьтә инде бу темаларга кискен берьяклы түгел, ә барлык мөмкин булган ракурсларны күздән кичереп якын киләсең», – ди маэстро. Әмма яшькә ишарә итеп көлемсери генә, миңа калса. Кайчандыр вакыйга буларак кабул ителгән канлы-шомлы «Банды Нью-Йорка»сында да бар иде инде бу үзенчәлек: мораль императивларга йөз тоту. «Последнее искушение Христа» чыккач та христиан оешмалары зур җәнҗал куптарды. «Молчание» фильмын исә Скорсезе Ватиканда иезуитларга күрсәтте, аннары понтификның үзе белән дә очрашты. Нәрсә сөйләшүләре – безнең өчен сер, шулай булып калсын да. Безгә башкасы кадерле: XX йөзнең культ дәрәҗәсендә саналган режиссерларының берсе, тарихи үткәнне экранда чагылдырып, карaучысы белән тагын бер мәртәбә үз заманы турында диалог корырга омтылыш ясады. Аның карaучылары арасында «кечкенә кешеләр» генә түгел, ә Яңа заман тарихын язучы бүгенге көн «сегун»нары, «инквизитор»лары, «миссионерлары» да бардыр дип ышанасы килә.

«КЕМГӘДЕР БАРЫБЕР НАЧАРРАК БУЛАЧАК...»

Маргарет Этвуд, «Рассказ служанки» романы
Брюс Миллер, Рид Морано, Майк Баркер, «Рассказ служанки» сериалы

10 эпизодтан гыйбарәт пилотны, ягъни 1нче сезонны безгә 2017 елның апрелендә тәкъдим иттеләр. «Рассказ служанки» узган елның иң күп каралган, иң кайнар дискуссияләр уяткан һәм югары рейтингка ия булган сериалы дип табылды. 2017 елның «Эмми» премиясендә берьюлы берничә номинациядә җиңде: иң яхшы драматик сериал, иң яхшы хатын-кыз роле, икенче пландагы иң яхшы хатын-кыз роле, иң яхшы чакырылган актриса. 2018 елда исә ТВдагы иң яхшы хатын-кыз роле һәм иң яхшы драматик сериал номинацияләрендә ике «Алтын глобус» яулады.

Әсәргә килсәк, ул да, алдагы роман кебек үк, узган гасырда, төгәлрәге 1985 елда дөнья күргән һәм 1989 елда Нобель лауреаты, атаклы Британия драматургы Гарольд Пинтер сценарие буенча немец кинорежиссеры Фолькер Шлёндорф тарафыннан экранлаштырылган иде. Әмма бу кадәр шау-шу уятмады моңарчы. Гәрчә, Шлёндорф-Пинтер версиясе дә эшләнеше ягыннан игътибарны җәлеп итәрлек. Күрәсең, вакыты җитмәгән булган...

1939 елда туган Канада язучысы, публицист, әдәби тәнкыйтьче, җәмәгать эшлеклесе Маргарет Этвуд, олы яшьтә булуына карамастан, актив, һәм ул бүгенге дөнья әдәбияты мәйданындагы иң укыла торган авторлардан исәпләнә. Үз заманында Торонто университетын, АКШның Кембриджадагы Рэдклифф колледжын тәмамлый, магистр дәрәҗәсе ала, төрле илләрдә Канада белән АКШның, Европаның мәртәбәле университетларында укыта. Этвудның романнары дистәләгән телгә тәрҗемә ителгән, ул дүрт тапкыр Букерның шорт-битенә кертелә, 2000 елда әлеге премияне «Слепой убийца» романы өчен ала.

«Рассказ служанки» романы басылып чыккач, тәнкыйтьчеләр Этвудны феминизм флагы итеп күтәрә, әсәрне роман-антиутопия дип тамгалап, авторны Олдос Хаксли, Джордж Оруэлл белән янәшә куя. «Рассказ служанки» бүгенге хатын-кызлар маршлары фонында кабат актуальләште, дигән позициядә тора Көнбатыш массакүләм мәгълүмат чаралары. Хәтердә: хатын-кызларның массачыл сәяси-иҗтимагый позиция белдерүче ташкыны Вашингтондагы митингтан талпыныш алган иде, ул митингта Скарлетт Йохансон, Мадонна һ.б. Голливуд йолдызлары, атаклы шәхесләр катнашты. Күпчелек плакатлар Трампның Хиллари Клинтонга карата әйтелгән «кабахәт хатын» (nasty woman) фразасына һәм хатын-кызларга карата белдергән башка күп кенә тәрбиясез гыйбарәләренә нигезләнде. Акциягә Нью-Йоркта 100 мең, Лос-Анджелеста 750 мең кеше чыкты, аның дулкыны Лондон, Париж, Рига кебек шәһәрләрне дә каплап алды. Хатын-кызлар маршының символы буларак pussy-hat дип исемләнгән ал башлык сайланган иде, мондый башлыкларны акциядә катнашучыларның кайберләре үз куллары белән бәйләде, кайберәүләр аны акция узган урында оештыручылардан алды. Вашингтон маршында Мадонна белдергән сүзләр аеруча хәтергә уелып калды:

«Это отказ женщин принять новую эру тирании. Под угрозой не только женщины, но и все забытые обществом люди. Люди, которые отличаются от других, и это может считаться преступлением. Нужно было окунуться в этот мрак, чтобы проснуться».

Ал башлык, дигәннән, Этвуд әсәре оригиналда «Алая служанка» буларак яңгырый. Фильмда да бу атама саклана. Фильмда Этвуд материалы белән гаять сак, нәзберек эш итсәләр дә (ул – сериалның консультанты), сюжет линияләре буенча тармаклану бар. Технологик апгрейд гаять уңышлы килеп чыккан: нәкъ бүгенге көндәге хәлләр, вакыйгалар икәнлеген дә валемлыйсың, шул ук вакытта урта гасырлардагы инквизиция чорына, Американы Көнбатыштан килеп «яулап алган» чорларга кайткандай да хис итәсең үзеңне.

Әсәргә алынган эпиграфта ук идея-проблематикага анык ишарә ителә, ул Библиянең Бытие китабыннан алынган өзек:

«И увидела Рахиль, что она не рождает детей Иакову, и позавидовала Рахиль сестре своей... Она сказала: вот служанка моя Валла; войди к ней; пусть она родит на колени мои, чтобы я имела детей от нее».

Китап бер бүлмәгә дыңгычлап тутырылган хатын-кызларның берсе сурәтләгән укшыткыч-клаустрофобик атмосферадан башлана. Фильм – герионяның баласын күтәреп, эзәрлекләүчеләрдән качып, Канада чигенә йөгерүеннән... Кыскасы, һәр икесе дә хайвани дәрәҗәдәге исән калырга омтылу инстинктыннан, борынгыдан барлык төр җан ияләрен саклап килгән курку тойгысыннан башлана. Һәм бу тойгы әсәрнең дә, фильмның да соңгы битенә, кадрына кадәр җибәрми, нерв җепселләрен киеренкелектә тота.

Биологик катастрофадан соңгы дөнья. Элеккеге Америка территориясендә яңа дәүләт төзелеп килә. Псевдодини теократия хөкем сөргән, хәрби-тоталитар режимга нигезләнгән Киләчәк Республикасы Гилеадка рәхим итегез! Биредә бар да тәртиптә һәм үз урынында: ил белән Командорлар хакимлек итә, җирле полиция «иманны саклаучылар» ролен үти, солдатлар «фәрештәләр» дип йөртелә. Әмма, ни кызганыч, фаҗигадан соңгы дөньяда бала тудырырга сәләтле хатын-кызлар гына бармак белән санардай калган. Шуңа да аларны бик җентекләп саклыйлар. Хатын-кызлар берничә категориягә бүленә: 1) Хатыннар – бала таба алмыйлар, аларның төп вазыйфасы дәрәҗәлемәртәбәле дәүләт эшлеклесе булган ирләренә аркадаш-иптәш булу; 2) Марфалар – түбән категорияле, кастрат хатын-кызлар, алар йорт эшләрен башкара, хуҗалыкны алып бара; 3) Служанкалар – бала тудыру өчен кулланылучы механизмнар, Служанка, «Ходай ярдәме» белән Командорын һәм аның Хатынын бәби алып кайтып куандырса, аны, зур хөрмәт күрсәтеп, икенче Командорга тапшыралар; 4) Теткалар – Служанкаларны алар башкарырга тиешле миссиягә өйрәтүчеләр, күзәтүчеләр, идеология сагында торучылар, инквизиторлар; 5) Яраксызлар – хатын-кыз буларак

бракка чыгарылып, эш лагерьларына юлланган «кабахәт хатыннар», авызлыклап булмаган бунтарьлар, мондыйларны нигездә агулы калдыклар эшкәртер өчен файдаланалар. Служанкалар ишетеп белгәнчә, алар берничә ай эчендә юкка чыга, дип сөйлиләр.

Ничек соң мәйданнарга чыкмаган бу хатын-кызлар, нишләп бу хәлгә риза булган, дигән сорау бимазалыйдыр бу юлларны укучыны хәзер. Күтәрелмәкче була алар... әмма хатын-кызларны яшерен режим урнашкан көннән үк, офисларга, производстволарга килеп, башта эштән азат итәләр. «Сезгә ирек бүләк ителде, сез – изге», – диләр. Чикләр ябыла, сак урнаштырыла. Һәммәсенең кредит карточкалары ил буйлап сафтан чыгарыла. Аларга урамнарда капланмыйча йөрү тыела. Һәм шушы шартларда... асылда яраткан хатыннарын, сеңелләрен, дусларын иң якын ир-егетләр сата. Массачыл рәвештә мигә сеңдерелгән идеология шартларында алар кадерле кешеләрен үз куллары белән, «изге эш хакына» дип, тоталитаризм иттарткычына тапшыралар. Тапшырмаганнарын – мәҗбүр, йә булмаса юк итәләр. «Сез сайлау мөмкинлекләре артык күп булудан җәфалана торган җәмгыятьтә яшисез, без бу авыр мәшәкатьтән сезне арындырабыз, моның белән дәүләт ирләре шөгыльләнәчәк», – диләр.

Менә шушындый перспективалар хөкем сөргән идеаль дәүләт механизмының какшамаслык булуына инде инана башлаган төп героиня – Фредова (Служанкаларның исемнәре аларның Хуҗалары – Командорлар исеменнән оеша, Уорренова, Уэйнова һ.б.) асылда хәлләрнең катлаулырак икәнлегенә төшенә. Ул Служанка ителгәнче тартып алынган баласын табу һәм кайтару хыялы белән яшәгәнгә, артык карышмый, түзә, күзәтә, бәяли... Служанкаларга көнгә бер мәртәбә урамга чыгарга рөхсәт ителә, бу асылда аларга һава сулау мөмкинлеге бирү. Һәм менә Фредованың яңа иптәше аның белән канунда язылган Библия сүзләреннән тыш сөйләшә башлый...

Бу дәүләттә китаплар юк, алар тыелган. Уку турында искә алырга да рөхсәт ителми. Бу дәүләттә моңа кадәр яшәгән тормышның турында хәтта бергә урамнарда йөргән Служанкаң белән дә сөйләшергә ярамый. Әчтән уйларга гына... Һәрбер Командор йортында Служанкаларны күзәтеп торучы шымчы – Око бар. Аның кем булуын берәү дә белми. Биредә һәркем – функция, вазыйфа гына.

«Вы – переходное поколение, говорила Тетка Лидия. Вам труднее всех. Мы знаем, каких жертв от вас ожидают. Тем,кто придет вслед за вами, будет легче. Они с готовностью отдадут свои сердца во имя долга. Она не сказала: Потому что не будут помнить, каково иначе. Она сказала: Потому что не возжелают того, чего не смогут обрести».

Һәм менә көннәрдән бер көнне Фредова аңа кадәрге Служанканың үз-үзенә кул салуы турында белеп ала. Ә бит Служанкаларның бүлмәсендә кисә, тишә торган предметлар калдырмыйлар, җаймәләр дә таслап беркетелгән, кыскасы, алар моның мөмкин эш түгел икәнлеген беләләр. Һәм тагын да сәере: кичләрнең берсендә Командор Фред аны эш бүлмәсенә чакырта. Бу – бөтенләе белән тыелган хәл. Служанкалар бәбиле булыр өчен айга бер мәртәбә башкарыла торган йола вакытында да ни Командорга, ни барысын контрольдә тотучы Хатынына күтәрелеп карамаска тиешләр. Сүз кату турында уй да була алмый...

Фредова Командор бүлмәсенә килеп керүгә, стеллажлар буйлап тезелеп киткән китапларны күреп хәйран кала. Шулчак исенә сәфәрдәше Гленованың «синең Командорың бик тә абруйлы кеше, аның хакында күбрәк мәгълүмат тупларга тырыш, безгә җиткерерсең» дигән сүзләре килеп төшә. Ә Командор Фред, моңсу елмаеп, сүз башлый.

«Мужчинам ничего не осталось... Я хочу сказать, ничего не осталось делать с женщинами... Мужчины даже разочаровались в сексе. И в браке... Я хочу знать, о чем ты думаешь, говорит его голос у меня из-за спины.

Я мало думаю, легко отвечаю я. Он хочет доверия, но этого я ему дать не могу...

Да ладно, говорит он, мне интересно твое мнение. Ты достаточно умна, у тебя наверняка есть мнение.

О чем? спрашиваю я.

О том, что мы сделали, говорит он. О том, как все получилось.

Я совсем-совсем не шевелюсь. Я думаю о небе в безлунную ночь. У меня нет мнения, говорю я.

Лес рубят, щепки летят, говорит он. Мы думали, можно сделать лучше.

Лучше?-тихонько переспрашиваю я. Он что, думает, так – лучше?

Лучше никогда не означает «лучше для всех», отвечает он. Кому-то всегда хуже».

Һәм менә, яшен яктысыдай, укшыткыч-тынчу бу зинданнан чыгу юлы бардыр, дигән уй йөгереп үтә бер мәлгә зиһеннән. Әмма хәлләр болай гади генә булса, Маргарет Этвуд Маргарет Этвуд булмас иде.

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ӘДӘБИ ПРЕМИЯСЕ» ҖИҢҮЧЕЛӘРЕ

«Татарстан» журналының әдәби премиясе

2017 ел башында «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы һәм «Татарстан» журналы Татарстанның яңа заман әдәбиятына үзеннән сизелерлек өлеш кертә алырдай талантлы авторларны барлау максаты белән «Татарстан» журналы әдәби премиясе» бәйгесен игълан итте. Бәйге ике дәүләт телендә дә барды – рус телендә язучы һәм татар телендә язучы авторлар да үз әсәрләрен тәкъдим итә алды. 2017 елда премиягә дәгъва итүчеләрдән кульязмалар роман, повесть, хикәяләр циклы кебек жанрларда кабул ителде. Алар Татарстанның яисә Татарстанда яшәүчеләрнең тормышын яктыртырга һәм моңарчы беркайда да басылмаган булырга тиешләр.

Бәйгенең төп бүләге – китап нәшер итү.

Бәйгедә барлыгы 25 автор катнашты. Аларның өчесе Россиядән читтә яши: Казахстанда, Украинада һәм Белоруссиядә. Рус телендә иҗат итүчеләрдән – 15, татар телендәге авторлардан 10 кульязма кабул ителде.

Финалга рус телендә язган авторлардан – 3, татар телендә язганнардан 4 автор чыкты. «Татарстан» журналы әдәби премиясе» җиңүчеләренең исемнәре 2018 елның 15 гыйнварында «Татмедиа» АҖнең конференц-залында игълан ителде. Икесе дә Татарстанда яшәүчеләр булып чыкты: Гадел Хәеров һәм Айгөл Абдрахманова.

«Җиңүчеләрнең әсәрләре киләсе елда китап итеп нәшер ителәчәк», – дип белдерде «Татарстан» журналы әдәби премиясе» жюри әгъзасы һәм «Татарстан китап нәшрияты»ның генераль директоры Илдар Сәгъдәтшин.

Ә «Татарстан» журналының баш мөхәррире Татьяна Вафина, үз чиратында, финалга чыккан авторларны журнал белән хезмәттәшлеккә чакырды: «Сез язган әсәрләр безнең журнал битләрен бизәп кенә калмаячак, ә үз укучысын да табачак», – диде ул.

Фото: Александр Ефремов

Егор Серов, журналист, шагыйрь, «Книга» радиосының баш мөхәррире, Россия Радио академиясенең академигы, күпсанлы бәйгеләрнең жюри әгъзасы, Россия һәм халыкара бәйгеләр лауреаты. 2013 елдан – «Книга» радиосында, аңарчы башка радиоларда берничә эре һәм үзенчәлекле радиопроектлар авторы.

«Татарстан» журналы әдәби премиясе» бәйгесенең рус телендәгесенең жюри рәисе:

– Бүгенге гаджетлар заманында җитди иҗтимагый-сәяси басмаларда да әдәби әсәрләргә урын табылуы өчен мин бик шатмын. «Татмедиа» Республика агентлыгының мондый бәйгеләр аша республикада яшәүче талантларны барлавы һәм бәяләве – әһәмиятле эш. Шуңа мин «Татарстан» журналы әдәби премиясе»нең жюри рәисе булып чакырылуга сөенеп карадым, бу тәкъдимгә берсүзсез ризалаштым. Мондый бәйгеләрдә җиңүгә ирешү – бу яңа исемнәр һәм яңа авторларны ачу, дигән сүз. Укучыларга яңа төр әдәби дөньялар бүләк итү дә. Гадел Хәеровны мин беренче кат укыганда ук аерып куйдым, ул бик тә талантлы автор. Минем баллар куя торган кәгаземдә аның исеме янында иң югары балл гына түгел, өстәп тагын «+» билгесе һәм өч өндәү дә куелган. Фикеремнең башка жюри әгъзалары белән дә тәңгәл килүе – икеләтә сөенеч.
«Книга» радиосы җиңүчене радиоэфирда үз әсәреннән өзекләр укырга чакыра. Бу яңа авторны һәм аның иҗатын күбрәк кеше белергә тиеш.

Разил Вәлиев, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.

«Татарстан» журналы әдәби премиясе» бәйгесенең татар телендәгесенең жюри рәисе:

– Әдәби бәйгене әдәби журналлар игълан итсә, бу берәүдә дә сораулар тудырмый, гадәти хәл буларак кабул ителә. Ә менә иҗтимагый-сәяси басманың әдәби бәйге игълан итүе – ихтирам уята торган вакыйга. Өстәвенә, бәйгенең җиңүчесенә әзерләнгән бүләк тә искиткеч – «Татарстан китап нәшрияты»нда китап нәшер итү. Мондый хәл көн дә булып тормый. Хәер, бу мәртәбәле бәйгедә катнашу һәм әсәреңне «Татарстан» шикелле саллы басмада бастыру – үзе үк бүләк инде. «Татарстан» журналы авторы булу һәркемгә дә тәтеми. Минем, мәсәлән, шушы яшькә җитеп, бу журналда әле әсәремне бастыра алу бәхетенә ирешкәнем юк.

«Татарстан» журналын даими укып барам, әмма мин аны беренче битләреннән башлап түгел, ә азагыннан укый башлыйм. Миңа кызыклы материаллар, язмалар шунда: кешеләр, аларның мавыгулары, ирешкән уңышлары, әдәбият, тормыш, музыка, сәнгать... Ә сәясәткә килгәндә, ул – минем көндәлек чынбарлыгым.

Журналда бәйге авторларының әсәрләрен бастыра башлагач, «Татарстан» журналын уку тагын да кызыклырак була башлады. Аның битләрендә яңа аһәңнәр пәйда булды, басмага җылылык, кешелеклелек өстәлде. Әдәбият ул шундый көчкә ия – коры фактлар белән саннардан гыйбарәт дөньяга да җан өрә ала. Нәкъ менә кече жанрларга өстенлек бирүләре дә ошады: хикәя белән повестька. Алар «кече» жанр дип аталсалар да, бик кыен жанрлар. Бигрәк тә – хикәя, яхшы хикәяне кайчакта инде олпат каләм иясе дип исәпләнеп йөрүчеләр дә яза алмаска мөмкин.

Финалистларны сайлаганда, без яшь авторларга ставка ясадык. Урта яшьләрдәге һәм өлкәнрәк авторларны борчыган, алар күтәргән темалар, проблемалар миңа яхшы таныш. Алар турында безнең классиклар – Мирсәй Әмир, Ибраһим Гази, Гомәр Бәширов һ.б. лар да күп язды. Минем үземә яшьләрнең ни сулап яшәве кызыклы, аларны нәрсәләр борчуы. Киләчәк бит – яшьләр кулында. Нәкъ менә алар үз заманын әдәби әсәрләрдә чагылдыра ала.

Без бертавыштан Айгөл Абдрахманова кандидатурасына тукталдык. Аның каләме бар, ул жанрны яхшы тоя, сүз белән оста эш итә. Хикәяләре кыска гына, әмма логик яктан төгәл оештырылган, кызыклы. Психологизмга тартылу бар. Айгөл әле юлының башында гына, киләчәктә аның үсәр өчен бөтен мөмкинлекләре бар. Уңышлар телибез!

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ӘДӘБИ ПРЕМИЯСЕ» ФИНАЛИСТЛАРЫ

РУС ТЕЛЕНДӘ

ГАДЕЛ ХӘЕРОВ

ДИЛӘРӘ ШКУРКО

ЯРОСЛАВ ХОТЕЕВ

ТАТАР ТЕЛЕНДӘ

СӘМИГА СӘҮБАНОВА

ГӨЛҮСӘ ЗАКИРОВА

АЙГӨЛ АБДРАХМАНОВА

ЛАНДЫШ ӘБҮДӘРОВА

PRESSA.RU

«ТАЛӘПЧӘН ҺӘМ УСАЛ ХИРУРГ БУЛЫР ИДЕМ»

«Татарстан» журналының әдәбия премиясе» бәйгесенә килгән хикәяләре белән сез инде танышкан идегез. Менә хәзер бәйгенең татар телендә иҗат итүче лауреаты Айгөл Абдрахмнованың үзе белән дә танышырга җай чыкты.

Әңгәмәдәш:
Луиза Янсуар

– Ничек бу бәйгедә катнашырга булдың, Айгөл? Һәм, гомумән, әдәби бәйгеләр язучы өчен кирәкле, файдалы дип уйлыйсыңмы?

– Дөресен генә әйткәндә, бу бәйгедә катнашу үзем өчен дә көтелмәгән бер вакыйга булды. Язмаларымның җибәрелүе турында онытканмын да хәтта. Иҗатка урын калмый башласа, йә язган хикәяләреңне кешегә күрсәтмичә, бер ритмлы көнкүрешкә иялəшеп мүкләнеп ята башласаң, һичшиксез, мондый бәйгедә катнашырга кирәк. Хис-кичерешләр тоныклана башлаганда, иҗади адреналин алу мөһим дип саныйм. Миңа бу бәйге алга тагын бер адым атлар өчен көч бирде.

– Татар әдәбиятына килгән яшь язучыларга үзләрен таныту кыенмы, синеңчә? Моның өчен алар нәрсә эшләргә тиеш?

– Танылу өчен көчле иҗатчы булырга кирәктер, мөгаен. Ә менә үзеңне күрсәтү өчен, миңа калса, бүгенге көндә мәйдан җитәрлек: әдәби түгәрәкләр, остаханәләр, бәйгеләр бик күп. Теләге булган, киңәш һәм тәнкыйть сүзе ишетергә курыкмаган яшь язучыларга мөмкинлекләр бар.

– Бу бәйге сиңа беренче китабыңны нәшер итү мөмкинлеге бирә, ул китапны ничек күзаллыйсың? Китап бастырганнан соң тормышың үзгәрер дип уйлыйсыңмы? Ә үзең?

– Моңарчы китап турында уйлаганым булмады, шуңа күрә әлегә бернинди күзаллавым да юк. Бер генә теләк: иң көчле язмаларым керсен иде ул китапка. Миңа йөкләнгән ышанычны аклыйсы килә, ни дисәң дә. Тормыш... юк, үзгәрмәс ул. Ә миндә үз-үземне «ашау» хисе артырга мөмкин. Китап ул бала кебек, аның өчен җавап бирәсе булачак бит.

– Язучы үз заманының елъязмачысы булырга тиеш, диагноз куючысы, диләр. Килешәсеңме? Бүгенге заманга син нинди диагноз куяр идең?

– Авыру заманда яшибез, дияр идем. Кызганыч, бу көнкүреш мин күрергә теләгән идеаль тормыш таләпләренә, күзаллауларга туры килми. Еш кына берәр кузы эченә яшеренәсе килә башлый. Ә елъязмачы дигән сүзләр белән килешмим. Язучы, иҗатчы (шул исәптән мин дә) әйләнә-тирәдәгегә объектив бәя бирә алмый, дип уйлыйм. Без бит кешеләр генә...

- Синең өчен әдәбият кемнәрдән, нинди авторлар һәм китаплардан башланды? Хәзер кемнәрне укыйсың, күзәтеп барасың? Кемнәр авторитет?

– Әдәбият дөньясының кемнән башлануын хәтерләмим дә инде хәзер. Иң беренчеләрдән булып көчле тәэсир ясаган шәхес Әмирхан Еники иде. Рус әдәбиятыннан Михаил Булгаковны йотлыгып укыдым. Бераздан Анна Гавальда иҗатын үрнәк итә башладым. Хәзерге вакытта әдәбият дөньясындагы яңалыкларны күз уңыннан ычкындырмаска, мөмкин булганча укып барырга тырышам. Тик бөтен язучыларның да иҗатын кабул итә алмыйм. Соңгы арада Марат абый Кәбировның иҗатына тартылам.

– Беренче тапкыр «мин дә яза алам икән бит» дигән уй кайчан килде?

– «Иделем акчарлагы» бәйгесендә Гран-при алганнан соң, мөгаен. Башта бөтен катнашучылар алдында хикәямне сүтеп җыйдылар. Оятымнан җир тишегенә кереп китәрдәй булган идем. Икенче көнне бүләкләделәр. Шок кичердем, бер-ике көннән «бәлки, дөрестән дә, яза аламдыр» дигән өмет, уй барлыкка килде.

– Синең гаиләңдә язу эшенә, иҗатка хөрмәт яшәгәнен беләм. Әтиең белән әниең үзең яза башлауга ничек карады?

– Әниебез – үзе иҗатчы, бик тыйнак, әмма, минем карашка, сәләтле

Фото: Александр Ефремов, Айгөл Абдрахманованың шәхси архивыннан

шагыйрә. Мин бу сүзләрне ул минем әнием булганга гына әйтмим! Әтиебез бөтен барлыгы белән әдәбиятны хөрмәт итә торган кеше. Шуңа күрә әти-әни һәрчак көч биреп, ярдәм итеп тора. Иң беренче язмаларымны да әнигә укыттым. Чиле-пешле, әле хикәя булып оешып та бетмәгән текстларга әни игътибарлы булды, киңәшләрен бирде, Әмирхан Еники китапларын алып укытты. Бүген дә, яңа хикәяләр язылмыйча торса, иң беренче булып әти-әни «селкетә» башлый.

– Иҗатыңның башында сиңа иң төпле киңәшен биргән, үзеңә ышанычны ныгыткан кешеләр кемнәр булды?

– Шулай ук әни һәм әти. Ә үземә ышаныч әле дә ныгымады ул, җанны кытыклап торырлык бераз хис булырга тиеш бит инде.

– Кәгазь-каләм алдындагы курку хисен ничек җиңәсең?

– Хәзерге вакытта да шул хис белән көрәшеп яшим. Бәлки мин яза белмимдер, бәлки элеккеге кебек матур хикәяләр башка булмас, дигән курку бик еш кимерә күңелне. Шуңа күрә ни дә булса язарга утыру бик зур авырлык белән бирелә. Шул халәткә изләшмәс өчен, телефонга хис-кичерешләремне, ниндидер вакыйгаларны язгалыйм, теркім. Куркуны җиңү сере юк, гадәттә, үзеннән-үзе килеп чыга барысы да.

– Кулдан язасыңмы, компьютерда җыясыңмы?

– Хикәяләрне кулдан язам. Кызыл көндәлеккә карандаш белән язарга яратам. Шулай иткәндә, сүзләрнең сихри көче артадыр кебек.

– Китапларны кәгазьдән укыйсыңмы, электрон форматтамы? Язучы укучы да булырга тиешме?

– Язучы укучы булырга тиеш. Башкаларны укыганда һәм бәяләгәндә генә үз иҗатыңа читтән караш барлыкка килә, дип уйлыйм. Әлбәттә, кәгазь китапка өстенлек бирәм. Ләкин электрон форматтагыларыннан да баш тартмыйм.

– Проза язар өчен тормыш тәҗрибәсе кирәк, диләр. Янәсе, яшь килеш чын мәгънәсендә көчле проза әсәре язу – нонсенс. Килешәсеңме?

– Килешәм, чөнки бик күп яшь авторларның иҗаты белән танышырга туры килә. Гадәттә, мәктәп укучылары (югары сыйныфлар) һәм 1нче курс студентлары авылдашлардан, күршеләрдән ишеткән яки үзләре күргән вакыйгаларны әдәби әсәргә күчерергә тырыша. Геройны тегеләй дә, болай да җәфалыйлар. Хикәядә газап, чир, үлем күбрәк булган саен әсәр көчлерәк, дигән ялгыш фикер сизелә. Яшь авторлар үзләренә таныш булмаган хис-кичерешләр белән уйныйлар һәм шуның аркасында күпчелек очракта чынбарлыктан ерак булган, ясалма әсәрләр туа. Менә моны мин тормыш тәҗрибәсе булмаудан күрәм. Ләкин шул ук вакытта яшь язучылар арасында бөтен геройларны тоемлап, һәркайсын үзе аша кичергән авторлар да юк түгел. Тормыш тәҗрибәсен күзәтүчәнлек белән алмаштырып, көчле әсәр язарга мөмкин, дип уйлыйм.

– Язучының башында «тараканнар» күбрәк булган саен ул оригинальрәк, кызыклырак, дигән позиция популяр бүген. «Шаккатыризм» белән әдәбият мәйданын, укучыны яулау гадәти хәлгә әйләнеп бара. Пиарның кайсы төре дә килешә, дигәндәй... Йөз тотарга кирәкме бу тенденцияләргә?

– Үзең әйтмешли, пиарның кайсы төре дә килешә. Мин үзем «ятып калганчы, атып кал» мәкаләнә колак салу яклы. Ләкин башны югалтып, замана шаукымына бирелергә дә ярамый. Әшләп, сынап карарга, үзеңә читтән бәя бирергә һәм, иң мөһиме, шул тенденция кысаларында милли әдәбиятны күтәрергә тырышырга кирәк.

– Син үзең әсәрләреңдәге каһарманнар белән ни дәрәҗәдә тәңгәл? Якыннарың, танышларың язганнарыңда үзләрен таныйлармы?

– Әни хикәяләрдә танышларны «күргәли». Мин геройларның тормыштан алынганлыгын яшермим. Әсәрне мөмкин кадәр тормышчан итү өчен, кешеләр белән сөйләшкән, киңәшләшкән чаклар да була. Үземне геройларга күчергән юк. Дөресен әйтәм, куркам. Гәрчә, «Караш» хикәясендәге каһарманны бөтен кеше мин дип күз алдына китерә икән.

– Синең юридик белемең бар, табиб булам дигән хыялым да бар иде, дип уртаклашканыңны хәтерлим. Сайлау мөмкинлеге булса, башка һөнәр вәкиле булыр, тормышыңны икенче юнәлешкә борыр идеңме? Гомумән, Айгөл булмасаң, кем булыр идең?

– Кайчакта, берничә параллель дөнья бар, һәм шул дөньяларда мин төрле кеше тормышларын яшимдер кебек тоела. Әгәр хәзерге акыл белән мәктәп елларына кире кайтып булса, башка фәннәрдән имтиханнар биреп, медицина факультетына укырга барыр идем. Карап торышка бик таләпчән һәм усал хирург булыр идем, мөгаен. Тик филология өлкәсен сайлавыма үкенгәнем булмады, Аллаһка шөкер.

– Иң аяусыз, кырыс тәнкыйтьчең кем?

– Дөресен генә әйткәндә, кырыс тәнкыйть ишеткәнем булмады моңарчы. Әллә җәллиләр шунда... Гадәттә, киңәш бирәләр.

– Тормыштагы иң зур кыйммәтләр?

– Гаилә, сәламәтлек һәм тугрылык.

– Сине нәрсә илһамландыра һәм көч бирә?

– Музыка, каһвә, сәяхәтләр, үзенчәлекле шәхесләр белән аралашу. Илһам булмаганда, мине әйбәт кенә итеп сүгеп алу да ярап куя.

– Әдәбиятны «массачыл» һәм «җитди» төрләргә бүләсеңме?

– Әйе, бүлеп карыйм. Мондый бүленеш бөтен өлкәләрдә дә чагыла. Хәзер яшьләр арасында «җитди» (классик) әдәбият, музыка, сәнгатькә омтылу мейнстримга әйләнеп бара, әлбәттә. Тик, аңа карап кына, бу күренеш юкка чыгар, дип уйламыйм.

– Сине әдәбиятта иң тетрәндергән герой кем?

– Родион Раскольников.

– Әдәбият тәрбия чарасы булырга тиешме?

– Бүгенге югары технологияләр, Интернет заманында бу, бәлки, көлке яңгырыйдыр. Тик әдәбияттан тәрбия вазыйфасын беркем дә төшерми. Ул булырга тиеш. Әмма бүген әдәби әсәрләрдә тәрбияви моментларны нотык уку рәвешендә түгел, ә вакыйгалар, сюжет аша бирү сорала.

PRESSA.RU

«ТАТАРСТАН» МАХСУС журналы өчен

Айгөл Абдрахманова

ҖИР БЕЛӘН КҮК АРАСЫНДА

Күп катлы йортлар… Күккә ашкан таш пулатлар… Болар барысы да - табигатьтән качып, үз эчләренә бикләнүче кешеләрнең яшеренү урыннары. Дөнья куучы адәм балаларының «Акча!» – дия-дия күзләре тонган. Тышта алтын көз булды ни дә, көмеш кыш булды ни – аларга барыбер. Таш йөрәкле таш пулатлар эчендә яши-яши, кешеләрнең дә йөрәкләре ташка әйләнгәнме икән әллә?! Күңелләрендәге бозның эрүеннән куркыптыр инде, алар хәтта җәйнең җылы кояшыннан да качалар.

Менә бүген дә шәһәр халкы таш биналар эченә кереп югалды. Июльнең эссе көннәрен җилләткечләргә алмаштырды алар. Йөзләренә битарафлык битлеген киеп, компьютер артларына кереп утырдылар һәм …дөньяларын онытып шунда чумдылар Ә мин исә җәйге табигатьнең матурлыгы белән хозурланып, урамнар буйлап йөрим, сирәк кенә исеп куючы йомшак җил белән шаярам, җылы кояш нурларында иркәләнәм. Рәхәт… Кояшка тагын да якынрак буласы килә. Һәм мин, максатыма ирешергә теләп, югарыга үрмәлим. Беренче кат, ике, өч… унөч, ундүрт, унбиш…

Менә мин унбиш катлы йортның түбәсендә. Кешеләрдән өстә. Җир белән Күк арасында. Билгесезлектә. Тирә-якта чиксез зәңгәрлек, мамык болытлар һәм… Һәм аска томырылырга әзерләнеп «канатларын җәйгән бер кош». Карап торышка кызга 18–20 яшьләр тирәсе. Өстендә кыска кара күлмәк, җилкәсенә салган юка соры шарф – барысы да кайгы билгесе. Ләкин боларның берсе дә кызның якты йөзен караңгылатмый. Тәртипсез рәвештә тузгыган җирән чәчләр ара-тирә исеп куючы җилдә селкенешәләр. Җирән чәч бөдрәләре дә, җилкәсендәге шарф та тизрәк очарга телиләр бугай. Ләкин кыз ашыкмый әле.

Мин, аның сискәнүеннән куркып, аска чүгәлим дә түбәгә таба елышам… Һәм таш йөрәкле таш пулатның иңрәү авазын ишетеп тынып калам.

– Синең кебек хәлдә калганнарны күп күрдем инде мин. Кайсы гаиләсеннән уңмаган, кемнеңдер囲 эштә мәшәкатьләр килеп чыккан. Кемдер эчкән баштан сикерә. Ә сине монда нәрсә китерде?!

Кыз берни дәшмәде. Түбә дә җавап таләп итеп азапланмады. Бары үзалдына ыңгырашкан төсле сөйләвен дәвам итте:

– Өч-дүрт көн элек минем янга бер яшь егет менгән иде. Башта бертуктаусыз тәмәке көйрәтте. Бераз тынычлангач, бөтен эч серләрен ачып салды.

Моннан берничә ел элек егет азартлы уеннар белән мавыга башлаган икән. Бер гөнаһсыз булып тоелган бу кызыксыну, аны әкренләп үз чоңгылына алып кереп киткән. Баштагы вакытта гади уен автоматлары булса, соңрак карталар алмашка килгән. Иртән – эш, кич – уен. Шулай ай арты ай, ел арты ел узган. Моңа кадәр гел җиңеп килгән уенчы, карталарга кучкәч, оттыра башлаган. Йөз сумын, меңлекне, аннан бөтен хезмәт хакын. Үз көче белән эшләп алган акча гына җитми башлагач, бурычка кергән. Тагын оттырган. Туганнарына сиздермичә генә, өйдәге әйберләрне ташый башлаган. Барысын да оттырган. Соңгы уеннарның берсендә зур кешеләр белән уйнап, зур проблемаларга тап булган. Шушы сазлыкка гомерлеккә кереп батканлыгын, әҗәтләрен беркайчан да түләп бетерә алмаячагын аңлагач, минем янга килергә булган…

Мин аны бу адымыннан тыеп калырга теләп: «Әтиәниең, туганнарың турында уйла. Терсәк якын булса да, тешләп булмаячак. Синең аска томырылуыңнан аларга җиңелрәк булыр дип уйлыйсыңмы әллә?» – дип ялвардым. «Әйе, – дип җавап кайтарды ул. – Минем аркамда алар болай да күп хәсрәт кичерделәр. Алар, ниһаять, бәхетле булырлар», – дип, ике дә уйлап тормый, аска ташланды…

Үзем таштан булсам да, сез әллә минем йөрәгем дә таш дип беләсезме? Күпме түзәргә була мондый хәлләргә?! Нишләп сез – кешеләр – бер-берегезгә битараф? Нигә сез тормыш авырлыкларыннан чыгуның бүтән юлларын эзләмисез? Нигә мизгел генә булган яшәүнең кадерен белмисез?! Нишләп тирә-ягыгыздагы матурлыкны күрмисез?!.

…Аска ташланырга дип инде түбә читенә килеп җиткән кыз бер адым артка чигенде. Коңгырт-кара күзләрен билгесезлеккә төбәп торды да, моңсу гына: «Ул егет минем абыем иде», – диде…

Кыз җирне сайлады…

…Мин түбәдән төшкәндә, шәһәргә кич аяк баскан иде. Шәһәрдә эңгер-меңгер. Ә күңелдә – шом. Минем эчемә кереп оялаган шул шомны агачлар арасыннан иренеп кенә күз кысучы шәфәкъ нурлары да, кичке җылы җил дә куып тарата алмады. Күңел тынычлыгы җир белән күк арасында, кайдадыр билгесезлектә эленеп калган иде…

«Татарстан» журналы өчен МАХСУС

АТТИЛА: ИҢ МӘШҺҮР ГУН ХАКИМЕ

Тугандаш төрки халыкларның барысы да үзләренең тарихларын борынгы һуннардан башлый, дип язган идек инде. Кытай елъязмаларында һуннар турындагы иң борынгы хәбәрләр б.э. кадәр IV–III гасырларга карый. Нәкъ шул чорда, аксөяк һуннар нәселеннән чыккан Тумань-шаньюйның улы Модэ хакимлек иткән елларда (б.э.к. 209–174), көчле Һун дәүләте оеша һәм тиз арада күрше Кытай империясенең көндәшенә әверелә.

Автор:
Фаяз Хуҗин

ҺУН ДӘҮЛӘТЕНЕҢ ТАРКАЛУЫ

Әмма тәхет өчен туктаусыз барган көрәш нәтиҗәсендә Һун дәүләте көчсезләнә. Хуханье-шаньюй кул астындагы һуннарның бер өлеше б.э.к. 52 елда кытайларга буйсына, Чжичжи-шаньюй җитәкчелегендәге һуннар исә, кытайларга коллыкка төшүдән куркып, көнбатышка таба хәрәкәт итә башлый. Дөрес, б.э.ның I гасыры урталарында Юй-шаньюй Һун дәүләтенең Модэ чорындагы көчен-куәтен һәм бердәмлеген яңадан кайтара, тик озакка түгел. 93 елда кытайлар йогынтысы астында торган көньяк һуннар төньяк һуннарны тар-мар итә, бердәм дәүләт таркала. Бертуктаусыз сугышлардан туйган һуннар гаиләләре белән, тынычлык эзләп, туган ватанын калдырып, көнбатыш тарафларга юл тоталар. Юлда очраган кабиләләрне йә сугышып, йә тыныч сөйләшүләр нәтиҗәсендә үзләренә буйсындырап, алар башта Балхаш күле тирәсенә, Көньяк Себер далаларына, аннан соң Сырдәрья, Арал диңгезе буйларына килеп чыгалар, әкренләп Каспий һәм Көньяк Урал далаларында таралып утырган халыкларны да үзләренең вассаллары итәләр.

Шунысын искәртеп үтәргә кирәктер: әлеге күченеп утыру, кайберәүләр уйлавынча, яшен тизлегендә булмаган, шактый озак, ике-өч гасыр буена дәвам иткән. Бары тик 370нче елларда гына һуннар Идел елгасына килеп чыгалар. Биредә алар башта күчмә сармат кабиләләрен, аннан соң, тагын да көнбатышкарак хәрәкәт итеп, әле II гасырда ук Скандинавия һәм Балтыйк диңгезе буйларыннан Кырымга килеп төпләнгән герман телле готларны тар-мар итәләр.

Аңлашыла булса кирәк, күчеп утырулар барышында һуннар төрле телләрдә сөйләшүче күп кенә халыклар белән аралашканнар, беришләрен хәрбиләр ясап, гаскәрләренә кушканнар, катнаш гаиләләр барлыкка килгән һәм нәтиҗәдә алар үзләренең этник йөзләрен югалтканнар диярлек. Туган илләрендә – Үзәк Азия далаларында яшәгән хуннар белән Көнчыгыш Европага килеп чыккан хуннар арасында зур аерма бар, диләр галимнәр. Һәм бу дөрес тә. Европа хуннарын шуңа күрә тарих фәнендә гуннар дип атау гадәткә кергән. Мәкаләбезнең герое Аттила әнә шул гуннарның иң мәшһүрләреннән инде.

ЕВРОПА ГУННАРЫНЫҢ КОРОЛЕ

Гаҗәп хәл: Аттиланы Европа илләрендә безгә караганда күбрәк беләләр. Аның турында дистәләрчә фәнни һәм популяр китаплар, романнар һәм пьесалар язылган, диссертацияләр якланган. Аттила образын исландлылар «Өлкән Эдда» («Старшая Эдда»), немецлар «Нибелунглар турында җыр» («Песнь о нибелунгах») кебек урта гасырлар чорында иҗат ителгән героик эпосларында, Рафаэль, Делакруа –

Фотолар автордан алынды

картиналарында, Джузеппе Верди, Рихард Вагнер кебек бөек композиторлар исә операларында һәм симфонияләрендә мәңгеләштергән. Аттилага багышлап хәтта медальләр чыгарганнар. Аттила – Венгриядә иң популяр, киң таралган ир-егетләр исеме. Нишләп шулай?

Аттила – Европага күчеп килгән гуннар берләшмәсенең башлыгы (урта гасыр хроникаларында аны король дип йөрткәннәр), атаклы җиһангир, акыллы һәм хәйләкәр дипломат. Ул 400 нче еллар тирәсендә туган дип фаразлана. Аның әтисе Мундзук – Европа гуннарының элеккеге идарәчесе Ругиланың бертуган энесе. 434 елда Ругила вафат булгач, Аттила олы туганы Бледа белән бергә идарә итә. 445 елда, аның әмере буенча Бледа үтерелгәч, тәхеттә үзе генә кала. Европада ул Гун дәүләтенең юлбашчысы буларак танылa. Әлеге дәүләт Аттила идарә иткән чорда бик нык көчәя, көнчыгышта Каспий диңгезеннән башлап, көнбатышта Рейн һәм Дунай елгаларына кадәр булган җирләрне, анда яшәүче халыкларны берләштерә.

Гун дәүләтенең башкаласы – Аттиланың ставкасы – Паннониядә, Дунай буенда, хәзерге Венгрия территориясендә урнашкан була. VI гасырда яшәгән гот тарихчысы Иордан язмаларында бу ставка «авыл» («селение») дип аталган, әмма шунда ук «әлеге авыл искиткеч зур шәһәрне хәтерләтә», дигән сүзләр дә өстәлгән. Әлеге «авыл» яхшы ныгытылган була. Аның уртасында Аттиланың агач бүрәнәләрдән салынган искиткеч матур, ишек-капкалары бизәкләп эшләнгән сарае балкып тора.

Хәзер грек тарихчысы һәм дипломат Приск Панийский язмаларына күз төшереп алыйк. Ул 449 елда Константинополь илчелеге составында Аттила сараена килә. «Без килеп җиткәндә, – ди ул, – бөек король әле сараенда юк иде. Бераздан ул да күренде. Атына атланган килеш кенә горур кыяфәт белән үзен җырлап каршы алучы кызлар төркеме янныннан үтте. Үз өеннән аны каршы алырга дип, кулларына көмеш подноска куелган эчемлек тотып, министр киңәшчесенең хатыны чыкты. Эчемлек тутырылган савытны король галиҗанәпләре иелмичә генә кулына алды, әкрен генә эчеп җибәрде һәм сараена таба атлады». Илчелекне Аттила өч көннән соң гына кабул итә. Илчелек составындагы кешеләрнең һәрберсе ишек төбендә үк хуҗаның исәнлеге өчен эчеп куярга тиеш була. Аттила аларны күрше залда диванга кырын яткан килеш каршы ала. Илчеләрне йомшак кәнәфиләргә утырталар. Сөйләшүләр тәмамланганнан соң, кунакларны тагын, һәрберсен аерым-аерым, хуҗа хөрмәтенә эчеп куярга мәҗбүр итәләр. Аннан соң алар янына бай сыйлар куелган кечкенә өстәлләр чыгарып куялар. Тәмле-тәмле ризыклар, эчемлекләр алтын-көмеш савытларга, касәләргә тутырылган була. Бары тик Аттила өстәленә генә агач савыт-саба һәм гади генә ризыклар куела.

Приск Панийский Аттиланың төсенә-кыяфәтенә дә игътибар итә: кара чәчле, киң күкрәкле, яссы борынлы, гади генә киенгән кыска гәүдәле һәм олы башлы бер кеше була ул. Грек илчесе аны «зирәк акыллы киңәшче, ярдәмгә мохтаҗларга шәфкатьле һәм дусларына тугрылыклы зат» буларак тасвирлый. Шулайдыр. Әмма ничек кенә булмасын, башка җиһангирләр кебек үк, ул да үзенең хәрби гамәлләре белән басып алынган илләргә, кол дәрәҗәсенә төшерелгән халыкларга күпме кайгы-хәсрәт, газап-җәфалар китерүе турында уйлап та карамаган.

АТТИЛАГА КАРШЫ ТОЗАК

Гуннар белән Ругила идарә иткән чорда ук әле Көнчыгыш Рим империясе (Византия) белән тыгыз элемтәләр урнаша. Император Феодосий II, гуннар яу чапмасын өчен, аларга ел саен 350 фунт алтын күләмендә салым түләп тора. Бледа һәм Аттила вакытында император белән яңа килешү төзелә (игътибар итегез: ул килешүгә гуннар атларыннан төшмичә, ягъни римлыларга артык илтифат күрсәтмичә генә имза салалар). Бу килешү буенча

PRESSA.RU

Константинополь салым күләмен ике тапкыр арттырырга ризалык бирә. Алай гына да түгел, император гаскәрләре яу белән Сицилия якларына чыгып киткәч, Бледа һәм Аттила, көчле армия туплап, катапульталар, тараннар һәм башка төрле камау машиналары белән империя территориясенә килеп керә. Берничә крепостьны һәм Наис шәһәрен кулга төшерәләр. Империя халкы куркып кала: бу җиңү төньяк варварларының Константинопольгә дә һөҗүм ясарга сәләтле армияләре барлыгын күрсәтә ич. Феодосий еллык салымны 1000 фунт алтын күләмендә түләп торырга вәгъдә итеп кенә котыла.

Аттила, тәҗрибәле дипломат һәм сәясәтче буларак, Феодосий IIнең йомшак идарәче булуын аңлый, шуңа күрә аның казнасын дипломатик юллар белән талавын дәвам итмәкче була. Константинопольне сугышып ала алмаячагын да белә ул – башкала бик көчле ныгытылган була. Дөрес, 447 елның 27 гыйнварындагы көчле җир тетрәү нәтиҗәсендә аның стеналары җир белән тигезләнә диярлек, әмма аны бик тиз яңадан торгызалар, элеккеге җитезлекләрен җуйган гуннар шәһәргә керергә өлгерми дә калалар. Аттила башка тактикага күчә – империянең Балкан өлешендәге 70кә якын шәһәрен, хәрби ныгытмаларын пыран-заран китереп ташлый. Император Феодосий II Аттиланың таләпләрен канәгатьләндерергә мәҗбүр була: еллык салым 2100 фунт алтын күләмендә билгеләнә, 6000 фунт алтын күләмендә элеккеге бурычлар кайтарыла. Казна бушап кала. Бу хәлдән ничек чыгарга белмәгән византиялеләр гуннар патшасын юк итү планы коралар. Аттиланың ставкасына баручы рәсми делегация составына 50 фунт алтынга Хризафий атлы камергер яллаган катыйльне дә кертәләр. Әмма Аттиланың шымчылары Феодосийның әлеге ниятен белеп алалар. Җәзага тарту урынына, Аттила үзенең сәркәтибен һәм 50 фунт алтын салынган капчыкны муенына асып катыйльне Константинопольгә – император хозурына озата. Гуннар короле Феодосийдан үзенә яңа илчелек җибәрүне һәм делегация составына империянең күренекле сановникларын һәм үлем җәзасына тарту өчен Хризафийны да кертүен таләп итә. Аттила үз теләгенә ирешә, Византия императоры оятка кала.

БЕРЕНЧЕ ЗУР ҖИҢЕЛҮ

451 елда Аттила Көнбатыш Рим империясе территориясен яулап алырга керешә. 500 мең (кайбер чыганакларда – 700 мең) сугышчыдан торган армиясе белән ул Галлия һәм Бургундия җирләренә бәреп керә. Көнбатыш Рим империясе белән аның союздашларының Аэций командалыгындагы берләштерелгән армиясе гуннар белән Орлеан шәһәре янында очраша. Аттила гаскәрләре, көтелмәгән басымга түзмичә, кире чигенә башлыйлар. Ләкин Аэций аларга тыныч кына качарга ирек бирми. 15 июньдә хәзерге Труа шәһәре янындагы Каталаун кырында тарихка «халыклар сугышы» исеме белән кереп калган коточкыч бәрелеш була. Югалтулар, якынча исәп белән дә, 165 мең кешедән артып китә. Бу Аттиланың беренче зур җиңелүе була. Әмма ул төшенкелеккә бирелми: уңышсызлыкка очраса да, армиянең төп көчләрен саклап кала бит әле.

ҖИҢҮЛӘР ҺӘМ ИРЕШҮЛӘР

452 елда Аттила Италиянең төньяк провинцияләренә һөҗүм итә. Бу юлы инде Аэцийның гуннарны туктатырлык көчле коалициясе булмый. Аттила башта Венеция тирәсендәге Аквилея шәһәрен камап ала, яуны уңышсыз дип санап чигенергә торганда гына, шәһәрдән үзенең балаларын алып китүче ләкләкне күреп, туктап кала. Моны ул үзе өчен яхшыга юрый. Аквилея яңадан камап алына һәм ахыр чиктә бирелергә мәҗбүр була. Аннан соң бер-бер артлы Падуя, Мантуя, Верона, Бергамо шәһәрләре яулана. Ниһаять, Миланга чират җитә. Әлеге шәһәрне кулга төшерү аерым бер символикага ия була, чөнки биредә Константин Рим империясен рәсми рәвештә христиан дәүләте дип игълан иткән, һәм ул беркадәр вакыт Көнбатыш Рим империясенең башкаласы ролен үтәгән. Хәзер бу башкала христиан диненнән ерак торган «мәҗүсиләр» кулына күчә.

Берзаман Аттила Миланның бик бай һәм матур бер сараенда Рим императорын алтын тәхеткә утыртып сурәтләгән картинаны күреп ала. Тәхет янында аунап яткан мәетне ул гуннар ыруыннандыр дип кабул иткән, күрәсең, картинаны яңадан «төзәтеп» язарга куша. Алтын тәхеткә рәссамнәр Аттиланың үзен утыртып куялар, аның аяк очында капчыкларыннан алтын акчалар коючы куркак императорлар бил бөгә. Гуннар короленең заказы белән эшләнгән әлеге картина, галимнәр фикеренчә, Аттиланың Рим империясен юк итәргә омтылышын түгел, бәлки буйсындырып кына тоту теләген чагылдыра.

Феодосийдан соң тәхеткә менгән яңа император Валентиниан Аттилага илче җибәрә. Илче әлегә епископ, киләчәктә Рим папасы урынында калачак Лев исемле туры сүзле һәм акыллы бер сәясәтче була. Капитуляция шартлары турында сөйләшү башлангач та, Аттила үзенә хатынлыкка императорның Гонория исемле сеңлесен сорый. Риза булалар. Римга яу чабуның кирәге дә калмый.

АТТИЛАНЫҢ ҮЛЕМЕ

Аттила кире Паннониягә, үзенең резиденциясенә юл тота. Булачак хатыны Гонориянең Римнан килүен көткән арада ул үзенә яңа бер кәләш таба. 953 елда ул Бургундия чибәре Ильдикога өйләнеп куя һәм беренче төндә үк, аңа күз дә төшермичә, ни сәбәпледер, шәраб эчәргә тотына. Күп эчкән, күрәсең, көтмәгәндә борынынннан кан килә башлый һәм кан күп агудан ул җан бирә. Тик шунысы бар: кайбер чыганакларда күрсәтелгәнчә, Аттила беркайчан да исергәнче эчмәгән. Бәлки аны үтергәннәрдер? Шикләнү нигезсез түгел, әмма сорау җавапсыз кала.

Аттиланы олылап җирлиләр: гәүдәсен, Үзәк Азиядәге һун бабаларында кабул ителгән борынгы йола буенча, өч катлы табутка (аларның берсе саф алтыннан) урнаштыралар, баш һәм аяк очларына, мәңгелек йортта кирәк булыр дип, алтын-көмеш савыт-сабалар, сугыш кораллары, ат дирбияләре куялар. Күмүдә катнашкан кешеләрнең барысын да шул ук көнне юк итәләр.

ГУН ДӘҮЛӘТЕНЕҢ ЯЗМЫШЫ

Аттиланың вафатыннан соң үз эченә дистәләгән халыкларны туплаган Гун дәүләте тиз арада таралып та бетә. Күпсанлы уллары арасында аның мирасы өчен көрәш башлана. Гепидлар короле Ардарих баш күтәрә, Недао (Недава) елгасы янындагы сугышта Аттиланың яраткан улы Эллак һәм аның 30 меңгә якын сугышчысы һәлак була. Исән калганнарын Эллакның Денгизих һәм Ирник исемле туганнары Көнчыгыш Европага, Днепрның түбән агымы тирәсендәге җирләргә алып китәләр. Шул гуннардан бер төркем Идел-Кама төбәгенә күтәрелә. Республикабызның Менделеевск районындагы Турай каберлегендә, археолог-галимнәр фикеренчә, Европадан кайткан гун сугышчылары күмелгән.

Гуннар – Көнчыгыш Европа далаларына килеп төпләнгән беренче төркиләр, ә Аттила исә шул гуннарны Көнбатыш Европа халыкларына танытучы җиһангир. Гун сугышчыларының һәм алар белән бергә башка «варварларның» актив көрәше аркасында колбиләүчелек строе хөкем сөргән Рим империясе җиңелә, нәтиҗәдә, яңа прогрессив тәртипләр урнашу өчен киң мөмкинлекләр ачыла. Әйе, Европа гуннарының төп шөгыле – сугыш. Ә кемнәр генә сугышмаган соң ул чорда? Көчлесе җиңгән, көчсезе җиңелгән. Атилла гаскәрләре җиңү шатлыгын да татыганнар, җиңелү хәсрәтен дә кичергәннәр. Ә тормыш дәвам иткән. Гуннар күп кенә халыкларның этнос буларак формалашуында да сизелерлек роль уйнаган.

PRESSA.RU



МУЛЛА ИЛЕ:
777 ЕЛ ЭЛЕК ҺӘМ БҮГЕН

«Мулла Иле авылы булсын да, коммунистлар динле булмасын...» Һади Такташ 1930 елда Яшел Үзән районының Мулла Иле авылына килгәч, шундый юллар яза. Шагыйрь ул вакытта «Чаян» журналында эшли. «Мулла Илендә авыл Советы рәисе белән сәркатибе, партия әгъзалары, мулла белән бер сафта торып гает укыдылар», – дип, редакциягә шикаять килә. Такташ авылга шушы шикаятьне тикшерергә җибәрелгән була.

Автор:
Руфия Фазылова

Мулла Илендә башка әдипләр, танылган татар зыялылары да була. Алар арасында Шиһабетдин Мәрҗани дә бар. Юлы төшкәндә, биредә еш кына төн кунып чыкан ул. Бу исемлекне тагын да тулыландырып булыр иде.

Без дә Такташ, Мәрҗаниләр эзеннән Мулла Иленә сәяхәт кылырга булдык.

КАЮМ НАСЫЙРИ ҖЫЙГАН ТАРИХ

Мулла Иленең тарихын Каюм Насыйри үзе өйрәнгән. Шактый бай мәгълүмат туплап, киләчәк буыннар өчен тарихи фактларны язып калдырган ул. (Каюм Насыйри, «Археология материаллары» («Зөя өязе авыллары буенча»)).

Мулла Иле күренекле галим Гомәр Саттаровның туган авылы да. Әлбәттә, ономастика өлкәсендә зур белгеч булган Гомәр ага кече ватанының тарихын кат-кат өйрәнгән. Һәм «Чал тарихлы авылым» исемле хезмәт язган. Галим: «Мулла Иле авылына Болгардан килгән кешеләр нигез салган. Алар монда, монгол яулары Болгар шәһәрен тар-мар иткәннән соң, 1240 елда качып-күчеп килгәннәр», – дип яза. Шуңа бәйле рәвештә Мулла Илендә яшәүчеләр:«Безнең авылга 777 ел!» – дип горурланып сөйләде безгә.

Мәгърифәтче, тарихчы, тел белгече, әдип Каюм Насыйри исә Мулла Иленә 1873 елда килә. Атаклы галимнәр белән фәнни-археологик тикшерүләр алып бара. Каюм Насыйри Мулла Иле турында болай дип язып калдыра: «Бу Мулла Иленең асылы күптәндер. Монда бер Муллагол дигән кеше Болгардан килеп утырган. Алар әүвәл берничә кеше булган. Барысының да исемнәре мәгълүм түгел. Ияртүчеләрнең берсе – Муллагол дигән кеше. Алар белән Шәехби атлы адәм, үзенең Теләш исемле галим улы белән бергә килгән. Ул Мулла Илендә дәрес өйрәткән, мәдрәсә төзегән...»

Каюм Насыйри Мулла Иленең иске зиратында табылган кабер ташлары турында да яза. Чынлап та, авылның борынгы тарихын өйрәнүдәге иң ышанычлы, кире кагып булмый торган чыганак – заман җилләренә бирешмичә, бүгенгә көнгә кадәр сакланып калган өч кабер ташы. Ташка уеп язылган язуларны да укып була. Кабер ияләренең вафат булган еллары: 1493, 1528, 1788.

Мулла Иле мәктәбендә директор булып эшләгән Равил Сәйфетдинов бүген авыл мәчетендә имам вазыйфасын башкара.

– Димәк, Мулла Илендә Казан ханлыгы чорында дәрәҗәле кешеләр яшәгән, – дип сөйләде авылның аксакалы Равил абый Сәйфетдинов. – Мондый зур һәм нәфис хәрефләр чокып язылган, мәгънәви орнаментлар төшерелгән кыйммәтле ташларны, каяндыр еракларда атлар белән алып кайтып, аерым кешеләргә генә куйганнар. Бу ташлар авылыбызның бер гектар чамасындагы агач үсми торган

Фото: Александр Ефремов





аланлыгында утыра. Ул аланлыкта печән чабалар, әмма анда мәет күммиләр. Күмеп караганнар иде – сөякләр чыга. Ул борынгы зират мәйданы, монысы бәхәссез. Аның зурлыгына карап, Мулла Иленең борынгы, зур авыл икәнен чамалап була. Әмма 1528–1768 еллар эчендә мондый мәһабәт ташлар куелмаган, чөнки чуалышлар Казанны алганчы ук башлана, акрынлап рус гаскәрләре Тау ягын басып ала. Һәм Мулла Иленнән унбиш чакрым ераклыкта гына Зөя тамагында Свияжск ныгытмасы төзелә. Мулла Иле дәһшәтле яуларның үзәгендә кала. Ләкин шул чорда да иманын, нигезен югалтмый ул...»

Кырык елга якын Мулла Иле мәктәбендә директор булып эшләгән Равил Сәйфетдинов, булган чыганакларга таянып, яңа гына туган авылы турында китап язган. Аксакал бүген авыл мәчетендә имам вазыйфасын башкара. Тагын аны Яшел Үзән якларында шагыйрь буларак та беләләр, өч шигырь җыентыгы бар. Тиздән сиксән дистәне тутыручы Равил абыйның әле зиһене дә, сәламәтлеге дә сокланырлык.

– Мин Казан дәүләт университетының татар филологиясе факультетын тәмамладым, – диде Равил абый. – Тел, милләт, әдәбият, тарих дип янып яшәдем. Дин дә бар иде күңелдә, тик анысын коммунистлар заманында яшерергә туры килде. Мулла Иле турындагы китап бик күп авылдашларның теләк-тәкъдиме буенча эшләнде. Матди ярдәмне Равхат Хәмидуллин күрсәтте, бик зур рәхмәт аңа...

«ИКЕ ЯНЫНА ӨЧЕНЧЕСЕ СЫЯР»

Җирле үзидарә рәисе Илдар Сәләхиев безне авылның «картлар йорты»на алып китте. Мондый хәлне күрү түгел, ишеткәнем дә юк иде. Баксаң, 61 яшендәге Фирдәүсә апа Хөсәенова өендә өч авыру әбине карый икән.

– Ялгыз кешеләрне тәрбиягә алучыларга дәүләт өстәмә акча түли башлагач алгандыр, – дим Мулла Иле авыл җирлеге башлыгына.

– Юк, – дип җавап кайтара Илдар Сәләхиев. – Фирдәүсә апа әбиләрне караган өчен дәүләттән бер тиен дә акча алмый. Яңа закон гамәлгә кергәнче үк алган иде үзләрен. Шундый риясыз кеше ул. Менә күрерсез...

Фирдәүсә апаның йорты әллә ни зур түгел икән, дөрес, ике яклы ул. Гел елмаеп кына сөйләшүче бу сөйкемле апаның эчкерсезлеге йөзенә чыккан. Өч ир бала үстергән, алар хәзер читтә яши икән. Тормыш иптәше күптән вафат.

– Тәрбиягә алган беренче әбием Нурания апа Мөхәммәтҗанова булды, – дип сөйләде Фирдәүсә апа. – Без аның белән күп еллар Албаба сөт-май заводында эшләдек, дуслар идек. Кемнәндер Нурания апаны картлар йортына җибәрәләр, дип ишеттем. 2009 ел иде ул. Киттем Норлатка Нурания апа яны-

Мулла Илендә ике мәчет эшли.

Өч әбине тәрбиягә алган Фирдәүсә Хөсәенова.

PRESSA.RU

на. Йөри алмас дәрәҗәгә килгән, аяклары шешкән. Күз яше белән елый: «Картлар йортына барасым килми бит», – ди. Карар кешесе юк, балалар тапмаган ул. Бертуган сеңлесе бар, тик аларның да авыру карчыкны карарга мөмкинлекләре юк икән. «Әйдә, үзебезгә алып кайтам», – дидем. Әбием теләп ризалашты. Ул вакытта Нурания апага 80 яшь кенә иде әле. Монда кайткач, акрынлап йөри башлады. Берничә ел шактый әйбәт булды. Бүген исә урындыкны этеп кенә йөри ала, яше дә бар, 88не тутырды инде.

Фирдәүсә апа әбиләрнең һәркайсына, зур булмаса да, аерым бүлмә ясаткан. «Минем беренче палатада Нурания апа тора, икенчесендә – Надя апа, өченчесендә – Әлфия апа», – ди ул, уенын-чынын бергә кушып. Әбиләр, үзләре дә: «Киттем әле палатама», – дип сөйләшә.

– Ни өчен палата, каян чыккан сүз? – дим Фирдәүсә апага.

– Әлфия апа гомере буе Норлат хастаханәсендә санитарка булып эшләде. Картлык көнендә азрак акылы бутала башлады. Монда яшәүне ул эше дип кабул итә. «Мин икенче палатага барып килэм», – дип сөйләшә. Аңа кушылып, мин дә шулай дип атап йөртә башладым.

Фирдәүсә апа санитарка әбигә «хезмәт хакы» да түли икән. Йөзәр сум акча бирә. Әбигә 84 яшь. Хуҗабикә, Норлат хастаханәсенә табибка күренергә баргач: «Элек санитарка булган Әлфия апаны картлар йортына җибәрергә документлар әзерлиләр», – дигән сүзне ишетеп ала.

– Йөрәгем кысылып куйды, – ди Фирдәүсә апа. – Сөт-май заводында эшләгәндә ике аягым да нык пеште, озак кына хастаханәдә ятым. Шулвакыт Әлфия апа мине үз кызыдай карады. Мин аңа бик рәхмәтле идем.

Кыскасы, Фирдәүсә апа берничә көннән әбине үз өенә алып кайта. Бүген Әлфия апа ул өч әби арасында иң җитезе. Күрше авылда бердәнбер улы да бар икән. Дүрт ел эчендә ул ике тапкыр анасы янына килгән, анда да – акча сорап!

Өченче әби – Надежда Юдина, ул Фирдәүсә апа тәрбиясендә әле ике ел гына яши. Күрше Косякау авылыннан. Әбинең язмышы тагын да фаҗигале: улы кыйналуында яшәгән. Улы шуның өчен өч ел төрмәдә дә утырган. Тик иреккә чыккач та газиз әнисен җәберләүдән туктатмый: кыйнап, кул башына кадәр сындырган.

– Районның социаль яклау идарәсендә эшләүче кызлар шалтыратты, – ди Фирдәүсә апа. – 2015 елның көзе иде ул. «Авыр шартларда яшәүче бер әби бар. Аны да тәрбиягә аласың килмиме? Ике янына өченчесе сыймасмы икән», – диләр. Башта икеләндем, ярый ла болары белгән, якын кешеләр! Аннан ризалык бирдем инде, аяк-кулларым йөргәндә карарга кыенсынмыйм.

– Кеше үз анасын да карамый, сез чит әбиләрне тәрбиялисез. Җитмәсә, сау да түгелләр, – дим Фирдәүсә апага.

– Аллаһы Тәгалә исәнлекне бирсен, әлегә зарланмыйм. Нурания апа белән генә кыенрак. Ул арада иң өлкәне, аны мунчага күтәреп алып барып кайтам, ашатканда кашыклап ашатам. Әлфия апа кызлар кебек йөгереп йөри әле. Ләкин аңа һәрвакыт күз-колак булып торырга кирәк: кайчы-пычакларны яшереп куям, газны ябып йөрим. Акылга җиңелрәк бит. Надя апа исә еш кына үткәннәрен сөйли, тыңлап кына бетер. Ул үз акылында, колагы гына начар ишетә. Ризыкны сайлап, санап кына ашый. Ит ризыклары ярата. Көз көне бер бот ит алган идем, менә тагын алтмыш кило алдым әле…

– Әбиләр белән дә сөйләшеп алдык. Фирдәүсә апага рәхмәт укыйлар: камыр ризыклары да пешереп тора, карый, ашата, атна саен мунча кертә, диләр. Чыннан да өйдә чисталык-пөхтәлек хөкем сөрә. Әбиләр дә чиста-пөхтә киенгән.

– Монда кайчан килсәң дә, шундый чисталык, – ди Мулла иле авылы җирлеге башлыгы да.

Менә шундый гыйбрәтле дә, гаҗәеп тә язмышлар. Фирдәүсә апа яшермәде: кайбер авылдашлары: «Әбиләрне пенсия акчаларын алу өчен генә карыйсың», – дип тә әйткәлиләр икән. Бу турыда бәлки язып тору да кирәкмидер, тик әлеге проблема белән башка кешеләр дә очраша. Тәрбиягә бала алган гаиләләргә дә еш кына: «Акча өчен алган», – диләр. Мондый очракта җавап бер генә: «Сез дә алып карагыз, баерсыз…»

«ДӘҮЛӘТ ПРОГРАММАЛАРЫНА КЕРМӘВЕҢ ХӘЕРЛЕРӘК!»

Әлбәттә, авылларга баргач җир кешеләре, мал асраучылар турында да кызыксынабыз. Авыл кешесенә эш бармы? Яшь гаиләләр төпләнеп каламы? Мәктәп эшлиме? Халыкка ял итү, күңел ачу чаралары оештырыламы? Гадәттә, авыл җирлекләре: «Барысы да әйбәт», – дип җавап кайтара. Мулла Илендә үзгәрәк җавап ишеттек:

«Буш сүз сөйләп тормыйм, барысын да күрерсез, сорашырсыз», – диде авыл җирлеге башлыгы.

Мулла Илендә 580 хуҗалык бар, 800ләп кеше яши. Әмма рәсми рәвештә теркәлгән бер генә фермер да юк икән. Югыйсә йорт саен диярлек мөгезле эре терлек тоталар. Ике, өч сыер асрау – биредә гадәти күренеш.

– Халык нигездә терлек асрап көн күрә, – ди Илдар Сәләхиев.

– Ә ни өчен фермер хуҗалыгын үстерү өчен бирелә торган дәүләт программалары алмыйлар? – дим.

– Куркалар.

– Нәрсәдән?

– Үзләреннән сорарсыз...

Авыл җирлеге башлыгы безне Айрат Шиһапов хуҗалыгына алып китте. Айрат абый ялгыз ир, бер тапкыр да өйләнмәгән. Өч сыер асрый. Әле баш санының күбрәк вакытлары да булган. Сыерларны аппарат белән сава. Узган ел маллар өчен зур гына каралты салган.

– Каралты эшләгәндә Яшел Үзән районының авыл хуҗалыгы идарәсеннән килделәр, – диде Илдар Сәләхиев. – Ун баш сыер өчен каралты салучыларга дәүләт субсидия бирә бит. Әллә шул программага керимме дигән идем. Аннан кире уйладым. Әгәр дәүләттән акча алсаң, малларны карау өчен рәсми рәвештә бер кешене эшкә алырга кирәк икән. Аннан ай саен салымын түләп торасы. Кыскасы, бәласыннан башаяк. Сөтне ел әйләнәсе сатмыйсың, ул вакытта салымны нинди акчадан түлим? Аннан баш санын да арттырырга кирәк, диделәр. Болай ичмаса үземчә яшим, баш авыртмый. Берәү алдында да хисап тотасы юк!

– Сыер асрауның файдасы каламы соң? – дим.

– Хезмәтеңне дә кушсаң, файдасы калмый. Быел сөтнең бәясе дә түбән. Узган кыш ичмаса 19–20 сумга җиткән иде, быел исә яңа гына 17 сумнан түли башладылар...

Авылда яшәүче башка кешеләр белән дә аралаштым. «Дәүләт программаларыннан файдаланмауның төп сәбәбе – салым түләп, хисап тотасы килмәүдән», – диделәр.

Мулла Илендә яшьләр авылда бик калмый, республиканың бик күп салаларындагы проблемалар биредә дә бар.

– Авылны яратабыз, дип сөйли читкә китүчеләр, – ди Илдар Сәләхиев. – Ярату андый булмый, дим. Менә без яратабыз, шуңа күрә туган нигездән китмәдек. Авыл бетмәсен, дип тырышабыз, балалар үстерәбез. Аптырыйм мин шәһәргә китүчеләргә: кеше фатирын арендалап яки фәлән миллион сумлык кредитлар алып шәһәрдә яшиләр. Ә туган нигезләре ятим булып тик тора. Узган саен шул йортларны кызганам...

Мулла Илендә мәдәни тормыш та гөрли. Ел дәвамында урамнар арасында төрле ярышлар, конкурслар уздыралар. Әле без килгәндә дә капка төпләрендә мәгърур булып төрле кар сыннары утыра иде. «Иң матур капка төбе» бәйгесе игълан иткәннәр. Иганәчеләр табып, җиңүчеләрне бүләкләгәннәр.

– Яңа ел көннәрендә авылыбыз урамнары бер дә шәһәр урамнарыннан ким булмады: капка төбе саен диярлек ут балкыды, сыннар тезелешеп утырды, – диде авыл кешеләре.

Хореограф, Мулла Иле кызы Рәзинә Сәйфетдинова, Казан дәүләт мәдәният институтын тәмамлагач, туган авылына кайткан.

Мулла Иле мәдәният йорты фойесында тезелеп киткән балалар аяк киемнәре – чешкилар гаҗәпләндерде. Һәр авылда мондый әйберне очратмыйсың! Мулла Иленең бию түгәрәге турында Казанда да яхшы беләләр икән. Ник дигәндә, алар төрле республика конкурсларында чыгыш ясыйлар, җиңү яулыйлар. 2017 елда «Созвездие-Йолдызлык»та Гран-прига лаек булганнар. Хореограф, Мулла Иле кызы Рәзинә Сәйфетдинова, Казан дәүләт мәдәният институтын тәмамлагач, туган авылына кайткан. Хәзер авылдашларының балаларын үзе кебек сылу гәүдәле, матур булырга өйрәтә.

Мулла Иле нинди тәэсирләр калдырды? Күңелне иң сөендергәне – чагыштырмача яшь, үз юнәлеше буенча укыган белгечләр эшли биредә. Ә бу нәтиҗәле эш өчен бик күркәм фалдыр. T

PRESSA.RU

ТАТАРСТАНДА УКЫЙСЫҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ТАТАРСТАНДА ҖИҢӘСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЭШЛИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

WWW.PROTATARSTAN.RU

Реклама 16+

ЧИРМЕШӘН РАЙОНЫ



PRESSA.RU

ЧИРМЕШӘН РАЙОНЫ: УҢАЙЛЫ ЯШӘҮ УРЫНЫ

XVIII гасырда биредән Россия дәүләте чикләре узган. Чирмешән нығытмасы нәкъ менә хәзерге Чирмешән районы үзәге урнашкан урында торган.

Фердинат Дәүләтшин, Чирмешән муниципаль районы башлыгы – Чирмешән муниципаль район Советы рәисе

Борынгы оборона нығытмасы калдыклары бүгенгә кадәр исән әле. Ашыкмыйча, ыгы-зыгы килмичә генә артка, үткәннәргә борылып карарга теләгән һәр кеше монда килә ала.

УҢАЙЛЫЛЫК БУЛДЫРУ ӨЧЕН ЭШЛӘҮ

– Россия буенча мондый нығытмалар шактый җыела, диләр. Ләкин Чирмешән кешеләре өчен бу урын үзенчәлекле – ул авыл һәм район символы булып тора. Мөгаен, район халкы йөз еллар дәвамында бу саклану нығытмасы аша рухи ныклыкка һәм эштә тырышлыкка, үҗәтлеккә дә ирешкәндер. Чирмешән кешеләрен нәкъ шул сыйфатлар аерып тора бит.

Әлбәттә, район икътисадының драйверлары булып сәнәгать предприятиеләре хезмәт итә. Районда 9 нефть компаниясе, икмәк кабул итү предприятиесе, май-сыр заводы, икмәк комбинаты эшли. Район территориясендә барысы 358 хуҗалык итү субъекты теркәлгән. Халыкның мәшгульлеге һәм тормыш дәрәҗәсе, бюджетның керем өлеше үтәлү, районны үстерү программаларын тормышка ашыру нефть табу компанияләре эшчәнлеге белән сизелерлек дәрәҗәдә бәйле. Нефть тармагында 400 гә якын кеше эшли. Район территориясендә шулай ук икмәк-күмәч, макарон һәм казылык ризыклары, ком-таш, агач материаллары да җитештерелә. Бүгенге көндә без районга инвестицияләр җәлеп итүдәге өметләребезне «Көньяк» муниципаль сәнәгать мәйданчыгын, агросәнәгать паркын үстерү белән бәйлибез. Район икътисады авыл хуҗалыгы җитештерүе белән тыгыз бәйләнгән. Район халкының шактый өлеше авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә, крестьян-фермер хуҗалыкларында эшли, шәхси ярдәмче хуҗалыклар алып бара.

Без барлык республика программаларында актив катнашабыз. Районда барлык күпфатирлы йортларны индивидуаль җылытуга күчерү программасы уңышлы үтәлде. Индивидуаль казаннар кешеләргә җылылыкны һәм акчаны янга калдырырга мөмкинлек бирә.

Район үзәгендә һәм район җирлекләрендә яшәү елдан-ел уңайлырак була бара. Чирмешәнлеләр өчен искиткеч мәктәпләр, балалар бакчалары, хастаханә, бассейнлы физкультура-сәламәтләндерү комплексы, «Юбилейный» боз сарае, балалар сәнгать мәктәбе эшли. Озакламый район Мәдәният йорты ремонтланып бетәчәк. Чирмешән халкының барлык объектлардан теләп файдалануы сөендерә, алардагы бәяләр символик күләмдә генә. Димәк, юкка гына эшләмибез – райондагы тормыш яхшыра бара.

ҖЫРЛЫ-МОҢЛЫ ТОРМЫШ

– Биредә, менә шушы сәхнәдә без инде 35 ел дәвамында җыелабыз, – дип сөйли башлады безгә Вера Захарова, репетицияне җырның иң кызыклы урынында өзеп. Ул – Иске Әлмәле авылының Мәдәният йорты директоры һәм җирле «Ивушка» музыкаль коллективының җитәкчесе дә. **1** – Кайчакта төнгә кадәр монда булабыз. Түзгән өчен ирләребезгә рәхмәт инде. Безнең коллективта педагоглар да, җылылык үзәге операторы да, китапханәче дә, йорт хуҗабикәләре дә бар. Безнең районда фольклор

коллективлары бик күп. Район башлыгы үзешчән коллективларга һәрвакыт ярдәм итеп тора, бездә бик еш фестивальләр үткәрелә, аларда рус, чуваш, татар, мордва башкаручылары үзләренең иң яхшы җыр һәм бию традицияләре белән таныштыра.

– Ә монысы – безнең зур булмаган тарихи-туган як музее, – дип сөйли Вера Николаевна Мәдәният йорты буйлап экскурсия ясаганда. 2 Монда кызыклы экспонатлар байтак.

– Бусы – яшьләребезнең яраткан урыны, – ди директордан эстафетаны үз кулына алган Марина Колесникова, безне иң аскы катка чакырып. Ул – спорт буенча методист, Иске Әлмәле мәктәбенең физкультура укытучысы. Монда тренажёр залы да, бильярд та, өстәл теннисы да бар. – Безнең зал бер көн дә буш тормый – балалар да, зурлар да йөри, гаиләләре белән бергә килеп шөгыльләнәләр, күреп торасыз. Кешеләр актив бездә.

Чирмешән районында бүгенге көндә 47 мәгариф учреждениесе эшли. Район җитәкчелеге нефть компанияләре ярдәме белән мәктәпләр һәм балалар бакчаларының матди базасын ныгыту өчен күп эш башкара. Узган елда гына да республика нефтьчеләре тарафыннан бу максатларда 46 миллион сум акча бүлеп бирелде.

Республика программасы буенча «Ромашка», «Миләшкәй», Карамыш балалар бакчаларын ремонтлауга 52 миллион сумга якын акча юнәлтелде.

ЭШТӘН СОҢ – КҮҢЕЛ АЧАРГА

Бу фикернең хаклыгына Аккирей авылына килгәч тә инанабыз. Лидия Квакова җитәкчелегендәге «Родник» фольклор коллективы якташлары өчен тамаша әзерли. Чуваш такмаклары, җырлары, биюләре арасында сәхнәдә күз ачып йомганчы бер өй үсеп чыкты!

– Авылда кешеләр борын-борыннан бер-беренә ярдәмләшеп яши, – дип аңлата сәхнәдәге күренешне Лилия Дмитриевна. – Безнең халык шул бер-беренә ярдәмләшү һәм хезмәт сөючәнлеге белән көчле дә. Ә эштән соң күңел ачып алу гаеп түгел. Безнең мәдәният йортында бию ансамбле дә, ирләр вокал ансамбле дә бар. Без бик рәхәтләнеп республиканың да, Россиянең дә коллективлары белән очрашып, иҗатыбыз белән уртаклашабыз. Үз казаныбызда гына кайнамыйбыз, кунаклар да кабул итәбез, үзебез дә гастрольләргә чыгабыз.

ӘМИРДӘГЕЧӘ «АНА КАПИТАЛЫ»

Әмир авылы. Мәдәният йорты директоры Фәрхәт Нуретдинов үз «биләмәләре» белән таныштыра. Барысы да яңа, чиста, балкып тора. Сокландыра! Монда капиталь ремонт 2017 елның язында

1

2

PRESSA.RU

Николай Фролов – Чирмешән мемориаль үзәгенә нигез салучы һәм аңа материаллар җыючы. Ул төзегән үзәкнең нигезендә тарихка конкрет кешеләр язмышы аша карау ята.

гына – республика программасы кысаларында үткәрелгән.

– Сезнең авылда ниндидер гайре табигый меценатлар да бар, дип сөйлиләр, – дибез.

– Ә нигә гайре табигый? Чып-чын алар. Бары тик сез аларны хәзер күрә алмаячаксыз. Алар Сургутта, Әмиргә, туган авылларына, җәй көне генә кайталар. Миндар белән Фазыл Әгъләмовлар алар. Россиядә икенче, өченче балалары туган әниләр «ана капиталы» ала. Ә бездә һәр яңа туган балага алар 100 мең сум премия бирә. Быел аны сигез кеше алды. Әгъләмовлар юбилярларны да, яңа өйләнешүчеләрне дә, мәктәпне тәмамлаучыларны да котлый, үз акчаларына Сабантуй үткәрә. Килегез сез дә Сабантуйга, шат булырбыз.

Күңелебездән Әмиргә җәй көне дә килергә карар итеп, Чирмешәнгә – авыл һәм район тарихына сәяхәткә кузгалабыз.

ПУРСЕЙ БОРЫНЫНДА ЧИРМЕШӘН ЭЗЕ

Әйе, әйе. Братск шәһәрендәге Пурсей борынында (географик атама) бүген дә Чирмешән гидротөзүчеләренә куелган һәйкәл тора. Ул турыда Чирмешән мемориаль үзәге экспозицияләрендә дә сөйләнелә. 1958 елның августында Чирмешән районы мәктәбенең тулы бер чыгарылышы класс җитәкчесе Ефим Клебанов белән бергә Братск ГЭС төзелешенә киткән. Яшь чирмешәнлеләр Братск тарихының үзенчәлекле символына әверелгән. Сакланып калган фотоларда аларның беренче уңышлары – беренче бетон, беренче кат турбиналарны сафка бастыру һәм ял минутлары. Фотоларга караганда, алар бик бәхетле булган.

Алсу Васильева, Чирмешән тарихи-туган як музее фондларының баш саклаучысы:
– Тугыз метр биеклектәге туфрак уры, тимердән коелган капкалары, өсте табигый ташлар белән түшәлгән бруствер булган Чирмешән ныгытмасын ике пехота һәм атлылар полкы саклаган… Җирле тарихи-туган як музеенда шундый картина бар: анда 1774 елның бер гыйнвар көнендә ныгытма коменданты секунд-майор Токарев чабаталы, ертык толыплы һәм иске генә бүрекле гади крестьян малае кулыннан ныгытманы Емельян Пугачев гаскәрләренә тапшыруны таләп иткән хатны ала. Баш күтәрүчеләрнең таләбе кабул ителми, ә ныгытманы саклаучылар, аның чигеннән чыгып, Салейкино авылы янында сугышка чыгалар, җиңеләләр һәм кулга алыналар. Кызганыч, Чирмешән ныгытмасы сакланырга тиешле тарихи һәйкәлләр исемлегеннән чыгарылган. Аның каравы, бүген теләгән һәр кеше ныгытма янына тоткарлыксыз уза ала. Боз сараеннан ул якка сукмак салынган.

Иске Әлмәле мәктәбе укучыларының фойега куелган бүләкләре аларның җиңел атлетика, волейбол, баскетбол, ату, чаңгы узышы буенча күпсанлы ярышларда ирешкән уңышлары турында ачык сөйләп тора. Мәктәп директоры Владимир Мануйлов сөйләвенә караганда, укучыларның уңышка ирешү серләре – әллә ни сер дә түгел. Иң мөһиме – көрәш дәрте, энергия һәм физик культура отличнигы Мария Колесникова кебек эш өчен җанын бирергә әзер педагоглар. Иске Әлмәледә балалар күп туа, шуңа күрә ата-аналар мәктәп белән бер бинада урнашкан балалар бакчасына чират тора. Педагоглар да, балалар да, ата-аналар да түземсезлек белән Иске Әлмәледә яңа балалар бакчасы төзелүне көтә.



Әлегә, Чирмешән районы Мәдәният йортында ремонт барган чакта, «Ядкарь» ветераннар хоры һәм Валентина Кандрова исемендәге «Ветеран» ансамбле үзләренең репетицияләрен балалар сәнгать мәктәбе бинасына күчереп торганнар. Җырчылар үзләрен шаяртып «зажигалочкалар» дип атый, чыннан да аларның күтәренке күңелләренә, энергиясенә һәм тормыш сөючәнлекләренә яшьләр кызыгырлык. Ветераннарның тыгыз репетицияләр, фестивальләр һәм гастрольләр графигы айлар буена алдан язып куелган.

«Юбилейный» боз сарае 2018 елның августында үзенең беренче юбилеен – 10 яшьлеген билгеләп үтә. «Татнефть» ГАҖнең Татарстан Республикасының көньяк-көнчыгышында балалар һәм яшүсмерләр хоккеен үстерүгә юнәлтелгән комплекслы программасы кысаларында төзелгән бу боз сарае заманча физкультура-сәламәтләндерү комплексын тәшкил итә. Монда Чирмешәннең биш балалар бакчасына йөри торган нәниләрне тимераякта шуарга өйрәтәләр, хоккей командалары, фигуристлар шөгыльләнә, бозда массакүләм шуулар оештырыла.

Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә бокс, җиңел атлетика, хоккей, көрәш, футбол, волейбол, баскетбол, чаңгы секцияләре эшли. Иске Әлмәле, Ульяновка, Иске Кади, Ивашкино һәм Бәркәтә мәктәпләре базасында спорт мәктәбенең (БЯСМ) филиаллары эшли. Бөтен секцияләр дә бушлай. Чирмешән балалары төрле дәрәҗәдәге ярышларда зурларча диярлек спорт уңышлары белән горурлана ала.

PRESSA.RU

МУЛ УҢЫШ КИТЕРГӘН СЫНАУ

Быел барлык игенчеләр үз тормышларында күңелсез капма-каршылыкка юлыктылар, игенчелек белән танылган Чирмешән районы авыл хуҗалыгы предприятиеләре дә искәрмә була алмады.

ЭРЕ ТЕРЛЕКСЕЗ ЯШӘП БУЛМЫЙ

«Күтәмә агрофирмасы» ҖЧҖ директоры **Фәнүзә Гобәйдуллина** фикеренчә, үсемлекчелек белән генә яисә терлекчелек белән генә шөгыльләнү бүген ышанычлы түгел, ике юнәлешне дә үстерергә кирәк: берсендә уңмасаң, икенчесе коткарыр, ди.

Дүрт ел элек хуҗалыкта 3,5 мең дуңгыз асралган. Авыл юлларын гына да 33 миллион сумга төзегәннәр. Мохтаҗлыкта яшәмәгәннәр. Әмма Африка чумасы аркасында төзелеш миллионнарча сумга төшкән: бордюрлар, өсте каплаулы машина юу урыннары... Тикшерүчеләр барыбер зур штрафлар белән дуңгызларны пычак астына җибәрергә мәҗбүр иткән.

3240 га сөрү җирләрендә 45 эшче (сезон вакытында – 60лап) бүгенге көндә көзге һәм сабан арышы, арпа үстерәләр. 2012–2015нче уңышсыз елларда хуҗалык табышка эшләгән. Уңыш гектарыннан 20–25 центнердан да ким булмаган. Кредитлар алмаганнар. Ә узган ел кредит та алганнар, 5 меңләп тонна ашлык складларда ятып калган.

2016 елда көзгә 540 гектарда ашлык чәчкәннәр. Ашламаларны гына да 6 миллион сумга сатып алганнар, аны гектарына 150 кг исәбеннән керткәннәр. Сабаклары кеше буе үскән, соңыннан яңгырларда авып беткәннәр, әмма ике киптергеч ярдәмендә ашлыкны үз вакытында эшкәртеп, складларга тутырганнар. Техника күп, өстәвенә, вакытка сыешыр өчен, 2017 елда читтән дә комбайн яллаганнар. Бөртеклеләр уртача һәр гектардан 45 центнердан артыграк чыккан.

– Бүген дуңгыз итенең тере авырлыгы килосына 120 сум тора. Һичьюгы 100 баш булса икән алар, – дип зарлана директор, – миллион сумнан артык керем алыр идем. Ә бүген чыгымнар кире кайтмый. Электр энергиясенә түләү һәм хезмәт хакларын бирү өчен җилемсәсе 29 процент булган ашлыкның тоннасын 6 мең сумга саттык! Элек фураж да 10 мең сумга сатыла иде.

Ике ел элек директор шәхсән үзе Киров өлкәсеннән бер партия сыерлар алып кайткан. Хәзер алар 90 га җиткән. Баш санын арттыра баралар, үгез бозауларны гына саталар. Бу елда 17 тана өстәлгән, ә савым сыерлары озакламый 50 баш булачак.

– Әгәр гаилә фермаларына ярдәм программасына эләгеп, акча ала алсам, шунда ук Балтачтан голштин таналары сатып алачакмын, – ди Фәнүзә Рәсимовна. – Һәрхәлдә, мөгезле эре терлекне арттырачакмын!

ТЕХНОЛОГИЯ ҺӘМ ТЫРЫШЛЫК

Илшат Гозәеров «ЧИРМЕШӘН-АГРО» ҖЧҖнә 2014 елның март аенда җитәкчелек итә башлаган. Хуҗалыкның 6029 гектар сөрү җирләре һәм мең гектарга якын чәчүлекләре бар. Биредә көзге һәм сабан бодае, арпа, солы, карабодай, шикәр чөгендере һәм көнбагыш үстерелә. Бу җирләр «Красный Октябрь» колхозыныкы булган чакта, анда 350 кеше эшләгән. Хәзер техника ярдәмендә аена уртача 21 мең хезмәт хакына 30 кеше дә эшләп өлгерә (сезон вакытында – 70кә кадәр).

Төп мәйданда идарә, остаханәләр, складлар, заправка һәм символик бәягә (хисап өчен) төшке аш әзерләүче ашханә урнашкан. Җәмгыятьнең әле тагын үз карьеры, тегермәне, туфракны известьләүче техникасы, аның белән ул үз районында һәм өч күрше районда акча эшли. Хуҗалыкның икенче мәйданда урнашкан фермасында 200 баш мөгезле эре терлек асрала, шуларның 50се – савым сыер. Кыш көне бер сыердан тәүлегенә 16 литрга кадәр сөт савыла. Өченче мәйданда яңа киптергечләре булган ашлык тогы һәм сыйдырышлы ашлык складлары.

2017 елда бөртеклеләрнең уңышы гектарыннан 49,6 центнер тәшкил иткән, ә тулай уңыш – 10 мең тонна. Аның алтысы инде сатылган, шул исәптән, республикадан читтә дә. Арпаны тоннасына 5 мең сум чакта сата башлаганнар. Бәя 4 мең сумнан да түбән төшкәч, сатмый башлаганнар. Складлар җитәрлек. 2017 елда җәмгыятьнең табышы 91,5 миллион сум тәшкил иткән. Җитештерүгә 20 миллионнан артыгын керткәннәр, тагын 6,5 миллионны бюджеттан алганнар. Сәгатенә 20 тонна бөртек киптерүгә көйләнгән ашлык киптерү комплексын куйганнар, ашлык тогы мәйданына асфальт җәйгәннәр, түбә тарттырганнар. Трактор һәм көнбагыш үргыч сатып алганнар, «Холмер» комбайнына һәм үзебездә җитештерелгән техника двигательләренә капиталь ремонт ясалган.

Сәүдә итүдә уңганлыклары һәм осталыклары бар. 900 гектардан артык җирдә көнбагышны урганнар, ел буена аның бәясе 6 мең сумга арзанаюына да карамастан, октябрьдә көнбагышны май сыгу заводына тапшырып, табыш алганнар. Ә башка бик күпләрдә көнбагыш гомумән урылмаган килеш калган. 450 гектарда үстерелгән шикәр чөгендеренең һәр гектарыннан 350 центнер уңыш алып, аны Зәй шикәр заводына үзләре өчен табышлы итеп тапшырганнар. Югыйсә, узган елдан соң чөгендернең тоннасы 800 сумга арзанайган да булган.

Реклама

Реклама

«СӨТ, АШЛЫК ҺӘМ ИТ БЕЛӘН ТУКЛАНАБЫЗ»

Кайчандыр Иске Әлмәледә – «Большевик», ә Яңасында Ильич исемендәге колхоз булган. Үзгәртеп кору, кушылу, банкротлыкка чыгу баскычларын үтеп, алар 2008 елда «Сөлчә» ҖЧҖгә берләшкән һәм аңа Хәмзә Хамматов җитәкчелек итә.

Монда 826 баш мөгезле эре терлек асрыйлар, аның 250 се – Яңа Әлмәле фермасындагы савым сыерлар. Иске Әлмәледә симертелә торган терлекләр һәм халыкка сатыласы таналар тотыла.

3215 га сөрүлек җирләренең 1600 гектары терлек азыгы өчен каралган, бөртеклеләр чәчү өчен – 1615 га. Көзге арыш һәм бодай, кукуруз, арпа, солы, берьеллык үләннәр чәчелә. Җәмгыятьтә 49 кеше эшли, сезонда – 80 гә кадәр, барысы да җирле халык. Уртача хезмәт хакы – 16,5 мең сум.

Бөтен техника үзләренеке, чәчү һәм уңышны тиешле вакытта җыеп алу өчен җитә.

«Сөлчә» ҖЧҖнең узган елгы кереме – 35 миллион 949 мең сумны, ә саф табыш 5 миллион 229 мең сумны тәшкил иткән.

Бөртеклеләрнең уртача уңышы гектарыннан 30,7 центнер булып, гомуми уңыш 45590 центнерны тәшкил иткән. Печән, салам, сенаж һәм силос артыгы белән әзерләнгән. Сусыл һәм тупас азыклар шартлы баш исәбенә 46,6 центнер азык берәмлеге күләмендә әзерләнгән.

Башка хуҗалыклардагы кебек үк, дәүләтнең ярдәме сизелерлек. Республика программасы буенча терлекчелек фермасын капиталь ремонтлау бара. Үсемлекчелеккә ярдәм йөзеннән бирелгән субсидияләр 3 миллион 114 мең 112 сум тәшкил иткән. Алар барысы да минераль ашламалар сатып алуга тотылган. «Менә ашламалар өчен түләүне акча белән түгел, ашлык белән алсалар иде», – дип хыяллана директор.

Складларда 703 тонна солы, арпа һәм сабан бодае кала. Хәтта килосын 5 сумнан сату да бармый. Сөт сатып алу бәясе дә 20 сумга кадәр төшкән. Пайчылар белән исәп-хисап тулысынча ашлыклата түләнгән. Ноябрь хезмәт хакын һәм салымнар түләүне таналарны сату хисабына каплаганнар. Шуңа да карамастан, техника инде язгы эшләргә әзер, орлык белән үзләрен тулысынча тәэмин иткәннәр.

Реклама

АКЧА АКЧАГА ТАРТЫЛА

Югары Кәминкәдә «Илхан» ҖЧҖ йөзендәге инвестордан уңганнар. Нижневартовск эшкуары Ильяс Хәнәфиев туган авылында 1000 баш савым сыерына исәпләнгән заманча ферма төзелешенә акча кертергә булган. Проект егәрлеге тәүлегенә 22 тонна сөт җитештерүне тәшкил итсен өчен – өченче абзарны төзеп бетерергә һәм әлегә җитешмәгән санны тутыру өчен терлекләр сатып алырга кирәк.

2016 елның декабрендә комплекс куллануга тапшырылган. Игълан ителгән 500 миллион сум инвестицияләр күләменнән 2015 елның апреленнән башлап 350 миллионы үзләштерелгән. Хөкүмәт комплексқа электр, су үткәрү һәм авылдан бетон юл сузу өчен түләгән. Максатчан программа кысаларында сыер абзарларын һәм алты силос траншеясен төзүгә федераль бюджеттан акча килгән. Җиһазлар һәм техника сатып алуны өлешчә республика финанслаган. Шәхси һәм бюджет акчаларына кара-чуар нәселле таналар сатып алганда, инвестор аларны үзе Балтач, Алабуга һәм Питрәчтә, Түбән Новгородта һәм Саратовта сайлаган.

Авыл кешеләреннән арендага алынган 5 га сөрүлек җирләрендә сабан һәм уҗым бодаен, арпа, солы, кукуруз үстерәләр. Сенаж, силос һәм бөртекле фураж артыгы белән җитә.

500 баш сыерга абзар, бозаулату бүлеге һәм 40 урынга исәпләнгән «ДеЛаваль» карусельле саву залы төзелгән. Фермада 25 кеше – савымчылар, терлекчеләр, механизаторлар һәм белгечләр эшли. Уртача хезмәт хакы – 20 мең сум. Саву, тирес чыгару, азык тарату тулысынча механикалаштырылган. Комбайннар, фронталь телескопик төягечләр, азык тараткыч эшли. Бер кагылуга эшләп китә торган маятниклы щётка-тарагычларны сыерлар аеруча ярата.

Көтүдәге терлекләрнең баш саны 500 дән артып киткән, аларның 225е – савым сыерлар. Чисталыкны саклау сәбәпле, ветврачлар әйтүенчә, авырулар тояклар авырту белән генә бәйле. Маститлар һәм эпизоотия турында күптән онытканнар.

Бер сыердан тәүлегенә уртача 25 литр сөт савыла. Үгез бозауларны халыкка саталар, таналар көтүдә кала. Сөтне литрын 25 сумнан «Данон» ҖЧҖ сатып ала.

Инвестор карамагында «Илхан» Югары Кәминкә товарлыклы-сөтчелек комплексы белгечләре өчен ТР Дәүләт торак фонды аренда торaклары – 15 кирпеч коттедж төзи: мәйдан әзер, инженерлык челтәрләре үткәрелгән, фундаментлар салына башлаган инде.

Реклама

PRESSA.RU

СЫЙФАТЛЫ, ВАКЫТЫНДА, **КҮҢЕЛ БИРЕП**

«Арстрой» ЖЧЖ социаль инфраструктура объектларын төзүдә һәм капиталь ремонтлауда махсуслаша. Эшчәнлек төрләрен киңәйтеп һәм эшнең сыйфатын яхшыртып, компания заказчы мәнфәгатьләренең һичшиксез үтәлүен кайгырта.

Һәр объектка көч, тәҗрибә һәм осталык кына түгел, күңел җылысы да салына. Моны аңлар өчен «Арстрой» ЖЧЖ төзегән Чирмешән авылындагы Яшьләр мәдәният-ял итү үзәгенең тышкы һәм эчке эшләнешенә күз салу да җитә. Аның ачылышында Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашкан иде. Компания төзекләндергән сквер да авылның архитектура бизәгенә һәм чирмешәннеләрнең яраткан ял итү урынына әйләнгән. «Арстрой» ЖЧЖ капиталь ремонтлаганнан соң җете буяулары белән күңелне сөендерүче 1 нче «Ромашка» балалар бакчасындагы матурлык, уңайлылык һәм рәхәтлек хәзер биредәге сабыйларны да, өлкәннәрне дә сөендерә.

Компания гомумтөзелеш эшләре, биналарны реконструкцияләү, капиталь ремонт, инвестицион проектларны гамәлгә ашыру белән шөгыльләнә.

Күптән түгел оешуына карамастан, ул башкарган эшләр исемлеге шактый зур инде. Шул ук Чирмешән районында гына да, әйтелгәннәрдән тыш, тагын дистәләгән объект төзелгән һәм капиталь ремонтланган. Казансу авылында мәктәп бинасы, Чирмешәннең 1 нче мәктәбендә спорт залы салынган, Кара Чишмә мәктәбе территориясе һәм «Ак каен» балалар бакчасы бинасы төзекләндерелгән. «Әмир» авыл клубы һәм Иске Котыш төп гомуми белем бирү мәктәбе, район Мәдәният йорты, Чирмешән лицее һәм Советлар Союзы Герое И.Конев исемендәге Чирмешән кадетлар интернат-мәктәбе биналары капиталь ремонттан соң заманча кыяфәткә кергән.

Башкарылган эшләр исемлегендә әле тагын Әлки районы Базарлы Матак авылындагы сигез объект һәм Казандагы 3 нче шәһәр дәваханәсен капиталь ремонтлау да бар.

Компаниянең төзелеш эшләре алып бару өчен кирәкле барлык документлары һәм 2015 елның 3 июнендә бирелгән Үзҗайлаулы оешма таныклыгы бар.

Матди-техник база компаниянең уңышлы эшчәнлеген тәэмин итә. Компания җитәкчелеге һәм директоры Давит Шадиновчи Киракосян шәхсән үзе матди-техник базаны үстерүгә һәм камилләштерүгә зур игътибар бирә. «Арстрой» ЖЧЖнең үзенең төп җиһазлары бар: биш йөк машинасы, блок-модульле вагон, бетон болгаткыч һәм штукатурлау машиналары, эретеп ябыштыру аппараты һәм полиэтилен эретеп ябыштыру җайланмасы.

Әмма компаниянең төп капиталы – эштә сыналган, белемле һәм заманнан калышмаучы белгечләр. Кадрлар мәсьәләсенә биредә тиешле игътибар бирелә, чөнки компания алдына куелган бурычларны квалификацияле белгечләрнең бердәм командасы гына гамәлгә ашырырга сәләтле. Табигый ки, җитәкченең һөнәрмәндлеге дә зур әһәмияткә ия.

Партнерлары белән мөнәсәбәтләрендә компания өчен иң мөһиме – үзара хөрмәт һәм ышаныч.

«Арстрой» ЖЧЖ инвесторлары һәм заказчылары тыныч була ала: төзү-монтаж һәм махсус эшләрнең күләме никадәр булса да, компаниянең техник һәм кадрлар потенциалы аны билгеләнгән вакыт эчендә һәм югары сыйфатлы итеп башкаруны гарантияләргә мөмкинлек бирә.

Реклама. Фотографияләр «Арстрой» ЖЧЖнән алынды

КЕЧКЕНӘ КОМПАНИЯНЕҢ ЗУР ТОРМЫШЫ

Соңгы 20 ел эчендә Чирмешән районының берничә авылында тормыш тамырдан үзгәргән. Үзгәрешләр районга «ГРИЦ» АҖ кече нефть компаниясе килгәч башлана. Баштарак аның базасы янында бер генә машина – ул да каравылчыныкы гына – торган булса, хәзер ишек төбендә буш парковка урыннары да юк...

Нефтьчеләрнең Чирмешән районын сайлавының сәбәбе: геология разведкасы мондагы җир катламнарында кара алтынның күп төрләре запасы – ике километрга кадәр тирәнлектә битум ятмаларыннан башлап, девон ятмаларына кадәр булуын ачыклаган. Запаслар шулкадәр киң җәелгән ки, хәтта бүгенгә кадәр аларга разведка да ясалып бетмәгән.

– Җитештерү базасын без торак пунктлардан якын торган урыннарда төзедек. Мондый чара җирле халыкны – югары түләнә торган эш, ә предприятиене кадрлар белән тәэмин итте, – дип сөйли «ГРИЦ» АҖ директорының гомуми эшләр буенча урынбасары Виктор Головко. – Моннан тыш, объектларны компактлы урнаштыру исәбенә предприятие эксплуатация чыгымнарын киметә, димәк, көндәшлеккә сәләтле булып кала алды.

Урындагы авыл җирлекләре җитәкчеләренең барысы да үзгәрешләргә шатланмады, билгеле. Компания скважиналар бораулау, юллар салу, электр линияләре үткәрү өчен авыл хуҗалыгы җирләрен алды бит. Югары хезмәт хакына кызыгып, эшкә сәләтле яшьләр башка предприятиеләрдән китеп барды. Тора-бара, Татарстан Хөкүмәтенең, район җитәкчелегенең ярдәме белән һәм нефтьчеләрнең беренче көннән үк район өчен күп эшләр эшли башлавы сәбәпле, мөнәсәбәтләр яхшырды. Ә инде авыллардан компаниягә беренче булып килгән кешеләр, укытылган-өйрәтелгәннән соң, нефть скважиналарына хезмәт күрсәтүче белгечләрнең үзәген тәшкил итте.

– Районга һәрьяклап ярдәм күрсәтү безнең өчен күптән инде традициягә әверелде. Мәсәлән, Иске Кади, Иске Котыш, Якты Тау авылының беренче класска баручы балаларын мәктәпкә әзерләү: предприятие акчасына аларга форма һәм зур мәктәп тормышына кереп китү өчен бөтен кирәк-яраклар сатып алына, – дип дәвам итә Виктор Юрьевич. – Компания Сабантуй, авыл хуҗалыгы алдынгылары слёты кебек чаралар уздырылганда финанс ярдәме күрсәтә, пенсионерларга, сугышта катнашканнарга, инвалидларга ярдәм итә. Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәйкәлләр, культ объектларын төзү һәм аларны яхшырту, шулай ук мәктәпләргә һәм фермер хуҗалыкларына булышу өчен «ГРИЦ» АҖ даими рәвештә үзенең махсус техникасын биреп тора.

«ГРИЦ» АҖнең соңгы биш елда районга күрсәткән хәйриячелек ярдәменең күләме 12,5 миллион сумга җиткән.

Әмма компаниянең төп ярдәме шунда, чынлыкта ул берничә торак пунктны тотрыклы, лаеклы тормыш белән тәэмин итә. «ГРИЦ» АҖдә нефть табу белән бәйле белгечлек алган хезмәткәрләрнең 60%ы үз йортлары белән янәшәдә эшләп яши. Аларның намуслы хезмәте предприятиенең, район һәм республика администрацияләренең грамоталары белән бәяләнә. Ә узган ел нефть табу операторы Рәшит Кәлимуллин Татарстан Республикасының атказанган нефтьчесе исеменә ия булган.

Районның нефть компанияләре күптән аның аерылгысыз өлешенә әверелгән. Алар, үз хезмәткәрләренең хезмәт хакларын даими арттыра барган хәлдә, төрле дәрәҗәдәге бюджетларга сизелерлек салым кертемнәрен тәэмин итәләр. «ГРИЦ» АҖдә уртача хезмәт хакы 49 мең сум, якын арада ул тагын 15% ка артачак. Компания үзенең барлык 105 белгеченә дә лаеклы тормыш тәэмин итә. Аларның профессиональлеге һәм сыйфатлы хезмәте – предприятиенең нәтиҗәлелегенә, димәк, аның районның һәм республиканың чәчәк атуы өчен киләчәк эшчәнлегенә этәргеч булып тора.

Реклама

PRESSA.RU



СӘЛАМӘТЛЕКНЕ ҺӘМ КАДРЛАРНЫ **КАЙГЫРТЫП**

«Чирмешән үзәк район хастаханәсе (ҮРХ)» ССДАУ – Чирмешән һәм күрше районнарда яшәүчеләргә планлы һәм ашыгыч ярдәм күрсәтүче заманча җиһазландырылган дәвалау-диагностика һәм консультация үзәге.

Хастаханә карамагында 69 койкага исәпләнгән стационар һәм сменага 371 кеше кабул итә торган дәваханә, шулай ук Иске Котыш, Чишмә, Түбән Кәминкә авылларында өч табиблык амбулаториясе һәм 34 ФАП бар. Пациентларга стационар ярдәмне ҮРХнең төп өч бүлеге: терапия, хирургия, балалар һәм 2016 елда көмәнлеләр патологиясе бүлеге белән берләштерелгән гинекология бүлекләре күрсәтә. Үз регистратурасы, персоналы һәм җиһазлары булган түләүле хезмәтләр бүлеге авыруларны коммерция нигезендә кабул итә. Стационар каршында шулай ук ашыгыч ярдәм бүлеге дә булган кабул-итү диагностика бүлеге эшли. ҮРХ территориясендә патология-анатомия бүлеге урнашкан, Республика судмедэкспертиза бюросы филиалы да ачылган.

Дәваханә штаты тар белгечлекле табиблар белән тулысынча комплектлаштырылган. Даими рәвештә фән-техниканың яңа казанышлары, профилактика методикалары кертелә. Эштә табибка интернет аша электрон язылу киң кулланыла. Учреждение базасында төрле медицина, оештыру-методик һәм консультатив ярдәмнәр күрсәтү өчен белгеч-табибларның урыннарга чыгу бригадалары оештырылган.

Ел дәвамында Профилактик прививкаларның милли календаре кысаларында 140 балага – полиомиелиттан, 58енә – гемофилия инфекциясеннән, 199ына В гепатитыннан прививка ясалган. ВИЧ-инфекцияне ачыклау буенча 2573 кешегә, В һәм С гепатитларына 2459 кешегә профилактик тикшерү уздырылган. ВИЧ-инфекцияле 7 кеше дәвалана.

Хатын-кызларга көмәнлелек, бала табу һәм бала тапканнан соңгы чорда ярдәм иткән, һәм шулай ук бер яшькә кадәрге сабыйларны диспансерлык күзәтүендә тоткан өчен «Социаль иминият фонды» Төбәк бүлеге Дәүләт учреждениесе тарафыннан 124 бала тудыру сертификаты талонына 744 мең сум акча түләнгән. 126 авырлы хатын-кызга пренаталь диагностика үткәрелгән. 70 пациентка югары технологияле медицина ярдәме күрсәтелгән.

Шул ук вакытта борчу уята торган демографик тенденция дә бар. 2014 елдан 2017 елга кадәр 1000 кеше исәбеннән бала табу саны ике тапкыр диярлек кимегән, үлем-китемнәр саны да шундый дәрәҗәдә диярлек. Халыкның табигый кимүе күзәтелә.

Ихтимал, район системасында табибларның «тулы комплект» түгеллеге дә үзен сиздерәдер, табибларның штат расписаниесендә каралган 45 урынына 35 кеше генә эшли, халыкның 10 мең кеше исәбеннән табиблар белән тәэмин ителеше – ТР районнары буенча уртача саннан түбәнрәк. Өлкән кешеләргә амбулатор-дәваханә ярдәме күрсәтү өчен гомуми практика табиблары һәм терапевтларга 10 участок буенча һәркайсына 1500 дән 1700 гә кадәр кеше беркетелгән – һәм бу норма кысаларына сыя. Ә өч педиатрлык участогында табибларга 1200 әр бала беркетелгән, бу нормативтан югары.

2016 елның җәеннән ҮРХнең баш табибы вазыйфасына перспективалы белгеч билгеләнгән.

Рөстәм Мирзин 2007 елда – «медицина-профилактика эше» буенча КДМУны, ә 2012 елда «анестезиология-реаниматология» белгечлеге буенча интернатураны тәмамлаган, Казандагы шәхси клиникаларның берсендә баш табиб булып эшләгән.

Яңа җитәкчелек кадрлар проблемасын яшьләрне җәлеп итү исәбенә хәл итәргә уйлый. Илнең медицина вузларында Чирмешән мәктәпләрен тәмамлаган 19 егет һәм кыз укый, аларның алтысы максатчан юнәлештә һәм эшкә районга кайтырга тиешләр. Аларны җәлеп итү өчен 1 миллион су акча түләүне күздә тоткан «Земский доктор» федераль программасы эшли. Шушы программа буенча 2016–2017 елларда 11 табиб эшкә урнаштырылган инде.

Яшь белгечләр өчен бер тапкыр пособие, хезмәт хакына өстәмәләр, шәхси торак йорт төзүгә субсидияләр каралган, аларга социаль найм буенча фатир алганда ярдәм күрсәтелә.

ҮРХнең матди базасы ныгытыла. 2017 елда дәваханә түбәсенә капиталь ремонт ясалган, ике модульле ФАП төзелгән, тагын икесенә капиталь төзекләндерү ясалган. Беренче звено медицина-санитар ярдәме учреждениеләрен модернизацияләүгә юнәлтелгән президент программасы буенча поликлиникада киләсе елга 67,5 миллион сумга капиталь ремонт үткәрү күздә тотыла.

Фотолар Чирмешән үзәк район хастаханәсеннән алынды

Реклама.

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТОВ

ҖИДЕ ЯРДӘМЧЕҢ **БУЛСА…**

Советлар Союзы Герое Иван Никитич Конев исемендәге Чирмешән кадет интернат-мәктәбендә кызлар һәм егетләр тулы урта белем һәм хәрби әзерлекнең башлангыч нигезләрен генә алып калмый, бөек якташлары үрнәгендә зур патриотлык дәресен дә үзләштерә.

Мәктәп 2008 елда ачылган. Ә узган ел, үзенең элекке укучысы, Рязань югары хәрби һава-десант училищесы курсанты Нәриман Сваровский инициативасы белән ясалган капиталь ремонттан соң, ул икенче тормышка ия була. Могҗизалар ел ярым элек башланып китә. Ул чакта, Чирмешәндә мәдәни үзәк бинасы ачылу тантанасында, Рөстәм Миңнеханов десант формасы кигән зифа буйлы егеткә игътибар итеп, аны янына чакырып ала һәм үзе белән таныштыруны сорый.

ТР Президенты белән әңгәмәсеннән зирәк егет бик оста файдалана: ул аннан үзе укыган интернат-мәктәпне ремонтлау һәм яхшырту өчен ярдәм сорый. Озакламый аңа Президент Аппаратыннан шалтыраталар һәм… эш кайный башлый. Ремонт барышында исә бер-бер артлы яңа спонсорлар да пәйда була. Ә Рязань югары хәрби һава-десант училищесы командованиесе Нариман үтенече буенча интернат-мәктәпкә 40 мең сумлык хәрби милек, спорт инвентаре һәм уку-укыту әсбаплары бүлеп бирә. Аның үтенечен КАМАЗ да җавапсыз калдырмый, быел интернат-мәктәпкә балаларны йөртү өчен автобус бүләк итәргә вәгъдә бирә.

Интернат-мәктәптә хәзер идеаль шартлар: матди-техник база яңартылган, яңа йокы һәм уку корпуслары төзелгән. Бөтен классларда да – интерактив такталар. Уку корпусы кабинетларына озакламый өстәмә җиһазлар һәм мебель китерәчәкләр, алар өчен ТР Мәгариф министрлыгы 8 миллион сум акча бүлеп биргән. Интернат-мәктәпнең капиталь ремонт ясалган тулай торагына китерелгән шкафлар, өстәлләр, урындыклар һәм тумбочкалар Яшел Үзән суднолар төзү заводы бүләк иткән 3,6 миллион сумга сатып алынган. Җиһазларны спонсорлар үзләре китергән һәм җыеп та биргән. Яңа Актлар залы җылы, якты һәм чиста.

– Яңа елда кадетларның яңа ашханәсе һәм спорт залы булачак, – ди Чирмешән районы мәгариф бүлеге башлыгы Светлана Әхтәмова. – Әлегә болар беренче мәктәп белән уртак, тик моның өчен республика бюджетыннан 73 миллион сум акча бүлеп бирелә инде. Бүген интернат-мәктәпнең 5–11 классларында 130 кадет укый. Аларның 95е интернатта яши, чөнки Чирмешән балаларыннан тыш, биредә Татарстанның 8 районыннан һәм Самара өлкәсенең ике – Шентала һәм Челнывершинский районнарыннан килгән балалар да бар. Нигездә биредә аз керемле һәм күп балалы гаиләләрдә тәрбияләнүчеләр, һәм шулай ук авыр тормыш хәлендә калган балалар укый.

– Кадет мәктәбе гомуми белем биреп кенә калмый, егетләрне гомуми хәрби юнәлеш буенча кораллы көчләрдә хезмәт итүгә дә әзерли, – ди директор Рафаэль Сөләйманов. – Физик, строй һәм сугышчан әзерлеккә күп игътибар бирелә. Мәктәпне тәмамлагач, күпләр Рязань, Казан, Пермь хәрби училищеларына укырга керә.

БЕЛЕШМӘ:

Иван Никитич Конев 1899 елның 5 гыйнварында Шешминка авылында (хәзер Чирмешән районына керә) крестьян гаиләсендә туган. Беренче Бөтендөнья һәм Гражданнар сугышларында катнашкан. 36 нчы мотоукчылар дивизиясе штабы башлыгы вазыйфасында Халгин-Голдагы сугышларда катнашкан. Бөек Ватан сугышын 3 нче («Уманская») һава-десант дивизиясе командующие вазыйфасында тәмамлаган. 1944 елның сентябрендә Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган, Җиңү Парадында катнашкан.

Фотолар Советлар Союзы Герое И.Н. Конев исемендәге Чирмешән кадет интернат-мәктәбеннән алынды

Реклама

1

2

ТҮБӘН КӘМИНКӘ: СУГАНЛЫ АВЫЛ



Кайсыбыз гына бoҗралап, яисә ярымбoҗралап, яисә вак-вак итеп суган тураганда күз яшьләрен түкми икән? Андыйлар юктыр, мөгаен. «Татарстан» яңа ел бәйрәмнәренә әзерләнгәндә бигрәк тә интекте – анысы өчен тура, монысы өчен вакла... Кешенең күзләреннән көлү бу, билләһи! Һәм менә суган белән сыналу тәмамлангач, сөенә-сөенә эшкә ашыктык. Ә эш, үз чиратында, безне командировкага – Чирмешән районының Түбән Кәминкә авылына юллады: үзебезне күрсәтергә, саф һава суларга. Тик шулай гына булсачы икән...

Автор:
Алсу Троицкая

1. – Безнең эштә иң мөһиме, аграр телдә әйткәндә, яхшы утырту материалы, – дип саный Равилә апа.

2. Хәлимә апа Гайнуллина, суган үстерү турында сөйләгәндә, шигъри сөйләмнең әле ямб, әле хорей ысулына күчә.

СУГАН ПАТШАЛЫГЫ

Түбән Кәминкә безне аңкып торган суган исе, алтынсу төстәге суган муллыгы белән белән каршы алды. Эреле-ваклы башлы суганнар, теге, без белгән Чиполинонның кардәшләре буларак, тоташ боҗрага уратып алдылар. Әле җитмәсә, һәрбер өйдә капчыклардан, әрҗәләрдән, тартмалардан, үрелгән һәм оекка тутырылган бәйләмнәреннән, үртәгәндәй, күз кысалар.

Нәкъ менә шунда, Түбән Кәминкәдә, тагын бер кабат медикларның суганнан елауның файдасы хакында сөйләүләре турында ишеттек, суганлы яшьләребезне сөртә-сөртә, суган әчесеннән елауның хурлыгы юклыгына инандык.

Без әле тагын Чирмешән суганының даны совет заманыннан бирле килгәнен дә белдек. Районның күп авылларында – Югары Кәминкәдә, Лашманда, Кәркәледә, Бәркәтәдә – аны үстерү технологиясен һәр хуҗалыкта бик яхшы беләләр. Тарихка данлыклы суган җитештерүче буларак кына түгел, Пугачёв явының патша гаскәрләре белән бәрелешү урыны буларак та кереп калган Түбән Кәминкәдә дә, әлбәттә, бу турыда яхшы беләләр. Ул бөек күтәрелешкә кагылышы белән Түбән Кәминкә халкы горурлана, билгеле, ләкин тыныч хезмәт белән шөгыльләнүне өстенрәк саный – һәркемне көнләштерердәй һәм үзләрен дә сөендерердәй данлыклы Чирмешән суганын үстерә.

СУГАН ФӘНЕ

– Кар әле яңа гына эреп беткән, туфрак гомумән салкын – шулай да суган утыртырга бик аз вакыт калып бара. Бөтен гаиләбез белән бакчага чыгабыз һәм – алга! Авызыңны ачып калып, суганны кояш җылыткан туфракка утыртсаң – бетте дигән сүз! Көпшәгә китәчәк! – Хәлимә апа Гайнуллина, суган үстерү турында сөйләгәндә, шигъри сөйләмнең әле ямб, әле хорей ысулына күчә. – Яратам шуны утыртырга. Суган безнең өчен – барысы да! Тәпи йөри башлагач ук, әти-әниемә булышып, утырта башладым үзен. Бу эш миңа бик ошый иде. Хәзер дә яратып эшлим. Элек без авылыбыз белән башлы суган үстерә идек, хәзер, үзегез беләсез, моның файдасы юк – бөтен җирдә гел җылы яклардан китерелгәнне саталар. Югыйсә, безнеке кебек яхшы түгел инде ул. Базарда сатучылардан: «Кем суганы?» – дип сорасаң, «Чирмешәннеке» – диләр. Алдашалар. Без соң үз суганыбызны үзбәкнеке ннән аермыйбызмы? Безнеке – тыгызрак, «киеме» дә калынрак. Читтән килгәннеке папирос кабыгы кебек юка. Шуңа да Чирмешән суганы озаграк саклана, ул ачылыгы буенча да куәтлерәк, сусылрак та.

Хәлимә апа әйтүенчә, бер ел икенчесенә охшамый – кайчак суган бик эре була, кайчак ваграк: «Без бит аңа, утыртканнан соң, бер дә су сипмибез, барысы да һава торышыннан тора. Яңгыр булса – яхшы. Башлы суганның берсе ярты кило, алай ук тартмаса да, 300 г була да була инде. Быел бик тәмле булып чыкты. Чирмешән суганы белән пешкән авыл тавыгыннан да тәмле әйбер юк диләр».

Фото: Алсу Троицкая

СУГАН ТРАДИЦИЯЛӘРЕ

Суган белеме дәресеннән соң, Хәлимә апа истәлекләргә күчә:

– Авылыбыздан башлы суганны КАМАЗларга төяп җибәргән чакларыбыз бар иде, һәр хуҗалыктан 6–7шәр тонна…. Без инде аласы уңыштан план корып тора идек: үстердек, саттык, телевизор алдык, суыткыч яки хуҗалык өчен башка кирәк-яраклар. Мин 20 ел колхоз идарәсендә эшләдем, аннары, пенсиягә кадәр, кибеттә сатучы булып, тик суган үстерү белән һәрчак шөгыльләндем. Бу бит өстәмә керем генә түгел, мавыгу, традиция дә! Балаларны да шуңа өйрәттек. Башта бөтен гаиләгә җитәрлек итеп утыртабыз, аннары балалар үзләре өчен аерым түтәлгә утырта. Аны тәрбияләп үстерәләр, чөнки аз булса да үз акчалары булачагын беләләр.

СУГАННЫ ПЛАНЛАШТЫРУ

Соңгы вакытта без күбесенчә кара орлыктан чемчи (утырту суганы) үстерәбез. Илһамландыра торган эш. Орлыкны көл белән бутыйм (бу ашлама да, ориентлашу билгесе дә), рәтләр җеп шикелле тигез сузыла. Җиңел генә өч кило чамасы утыртам. Үстергән чемчине шәһәрләрдә яшәүче туганнарым һәм танышларым сатып алып бетерә. Безнең авылда һәркемнең шундый үз «клиентурасы» бар. Менә шундый планлаштыру…

КИЛЕННӘР ӨЧЕН СУГАН МӘКТӘБЕ

Суган темасын безне өстәл янына утыртып һәм мичтә пешкән коймаклары белән сыйлый-сыйлый, рәхәтләнеп Равилә Юнысова дәвам итә.

– 40 ел элек, училище тәмамлап, шушында фармацевт булып килгәч, мин шаккаттым! – дип сөйли ул. – Үзем дә авыл кызы, Азнакай районыннан мин. Бездә дә суган утырталар, әлбәттә, ләкин моның кадәр?! Талдан үрү, чигү, агачтан әйберләр ясау белән танылган авыллар бар. Ә менә Түбән Кәминкә кешеләре яраткан эшләрен үз һөнәренә әверелдергән. Хәтеремдә, мин август аенда килдем. Һәр бакчада суган таулары өелеп тора иде. Минем өчен – шаккаткыч хәл, ә авыл кешеләренә – гадәти эш. Ул елларда кызлар, бакчада никадәр эшләргә туры киләчәген уйлап, Түбән Кәминкәгә килен булып төшәргә курка иде. «Ә мин бит монда аптекада эшләргә генә килдем», – дип, үз-үземне тынычландырган булам. Бигрәк беркатлы булганмын. Ике елдан шушы йортка килен булып төштем.

Мине бик тә эшсөяр гаиләгә кабул иттеләр. Очкыннар чәчрәтеп эшлиләр иде! Кайнатам белән кайнанам барысына да өйрәтте – суганны ничек утыртырга, ничек тәрбияләргә, ничек толымлап үрергә һәм сакларга. Менә хәзер алар да, ирем дә юк инде, балаларым үсеп таралды, ә мин суган үстерүне дәвам итәм.

СУГАН БРЕНДЫ

– Безнең эштә иң мөһиме, аграр телдә әйткәндә, яхшы утырту материалы, үсемлекнең табигый үсеш процессына мөмкин кадәр азрак катнашу һәм аны дөрес итеп саклау, – дип саный Равилә апа. Нинди дә булса химия яисә ашламалар куллану турында сүз дә булуы мөмкин түгел, ди.

– Традицион мишәр йортында, ә безнең авылда күбесенчә мишәрләр яши, суган «толымнарын» саклау өчен аерым урыннар – сәндерә, киштәләр бар. Һәм ул, һичшиксез, тотрыклы температуралы җылы, коры урын булырга тиеш. Әйдәгез, күрсәтәм, – Равилә апа безне суган «толымнары» саклаган чоланга алып керә, чыннан да, болар бит – флористика могҗизасы!

– Менә ул Чирмешән суганы! – ди ул горурлык белән. – Ул безгә бик булыша. Пенсия бетсә, сатасың, яхшы була. Ул бездә шулай суган акчасы дип йөртелә дә инде. Гомумән, безнең авыл өчен суган – Түбән Кәминкәнең чып-чын бренды, аңлыйсызмы? «Суган суы сыкма!» – дигәнне ишеткәнегез бардыр инде, ә безнең очракта «Суган бәхете» дию дөресрәк булыр мөгаен.

НИЧЕК БАРЫРГА:

Казаннан Түбән Кәминкәгә кадәр 172 км Яңа Чишмәне узып киткәч, игътибар белән юл күрсәткечләрен карап барыгыз. Чирмешәнгә җитәргә 16 км кала, зур юл чатында Красный Яр ягына сулга борыласы, аннары күрсәткечләргә карап ориентлашырга кирәк.

НИЧЕК ТАНЫРГА:

Намуссыз кешеләр сезгә уйламыйча да чит ил суганын Чирмешәннеке дип сатарга мөмкин. Ялган суганны чыныннан бер караш белән профессионал-бакчачыларның да аера алмавы ихтимал. Фальсификатны таныр өчен, суганны кисеп, аның катламнарына карарга кирәк – чын Чирмешән суганы сутлы, катламнары калын, «күлмәге» дә калын, берничә катлы була.

ТӨНЬЯКНЫ НИЧЕК ТАБАРГА:

Түбән Кәминкәнең тәҗрибәле бакчачылары, утыртыр өчен суган җитмәсә, чемчи суганны, һич шикләнмичә, икегә ярырга һәм яртышар суганнарның киселгән өлешен төньякка каратып утыртырга киңәш итә. Бу «төньяк» утыртылышы сезне яхшы уңыш белән тәэмин итәчәк, дип ышандыралар.

PRESSA.RU

«Туган җирем Кайбыч районы Кошман авылында Утташ чаты, Уңар үзәнлеге, Гәрәй талы басуы, Шәрәп борыны, Сәет бабай үзәне, Изге кыз каберлеге, Керәшен зиратына бәйле кызыклы риваятьләр, телдән-телгә сөйләнеп, буыннан-буынга күчеп, бүгенгәчә яшәп килә», – дип язды безгә күптәнге авторыбыз Хәмидә Гарипова. Бүген шуларның берсе белән сезне дә таныштырып үтәбез.

ТАТАРСТАН РИВАЯТЬЛӘРЕ: Утташ чаты галәмәтләре

XVI гасырда Явыз Иванның көчләп чукындыруыннан качып, Түбән Кошманның Аяс Баба ыруы, нарасыйларын күтәреп, карт-корыны уфалла арбасына утыртып, янәшәдәге калын урманга таба юл ала. Афәттән җәяүләп качып китүчеләрне сизеп алып, ат өстендә куа чыгалар. Эзәрлекләү куе урман ешлыгында дәвам итә. Төбе сазлыклы тирән чокыр буенда дошманнар качакларны куып җитә. Аяусыз үтереш башлана. Гомерләренең соңгы минуты килеп җиткәнлеген аңлаган мөселманнар, сәҗдәгә китеп, ихластан Аллага ялварырга, кара урманны яңгыратып бергәләп тәкъбир әйтергә керешә. Шул мәлдә чалт аяз җәйге көндә көчле җил-давыл куба, калын имәннәр, төбе-тамыры белән кубарылып, залимнәр өстенә ава башлый, күк күкрәп, чиләкләп яңгыр коярга, боз яварга керешә, атлыларны яшен камчысы көйдерә. Гаскәриләрнең бер өлешен Табигать-ана утта һәлак итә, калганнары кара ташка әверелә. Шул көннән соң бәрелеш булган урын Утташ чаты дип аталып йөртелә башлый. Бүгенгәчә бирегә аяк басучылар белән төрле сәер хәлләр булып тора.Утташ чаты гөмбәчеләрне, аучыларны адаштыра, колакларына сызланып ыңгырашкан, әче итеп сызгырган, кычкырып сүгенгән, ат кешнәгән тавышлар ишетелә. Бергәләп җиләккә, утынга, печән чабарга килүчеләрнең олыраклары тиктомалдан ачуланыша, ә бала-чагалары янәшәдә басып торган әти-әниләрен күздән җуйганга күрә, илереп елый башлый, имеш…

Редакция сезнең туган якларыгыз, авылларыгыз риваятьләрен «бүләккә» рәхәтләнеп кабул итә. Аларны безгә юллагыз – һәм бөтен ил сезнең туган ягыгыз турында белер.

Фото: Александр Ефремов

АЙ КӘЕФЕ:
БИЕКЛЕКНЕ БУЙСЫНДЫРУ

ВЕРТИКАЛЬ БОЗНЫ ШТУРМЛАУ

Татарстанлылар да гыйнвар аенда бозлы биеклекләрне яуладылар. Спортчылар Кама Тамагында, җирлекнең табигый рельефын кулланып, Кама тамагы янәшәсендә Иделнең боз каткан текә ярын штурмладылар. Һәм бозлы яр аларга буйсынды. Буйсынырга тиешле һәрнәрсә буйсына! Спортчыларның кәефе нәкъ шундый – күтәренке!



PRESSA.RU

ОБЪЕКТИВ АША – МӘҢГЕЛЕККӘ...

Фото: Михаил Козловский

#фотоэпохи #лучшиефотографы #михаилкозловский #светлаяпамять